Безнен МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

02

февраль 2017

ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

«АШКАЗАР»

Мостай Кәрим

112 нче бит

МИРАС
№-02 / 2017

ФӘҺЕМЛЕ ДӘРЕСЛӘР



مختصر
غنية المتملى
شرح
منية المصلى
المعروف بيننا بـ
حلبى صغير

مؤلف منية المصلى سديد الدين الكاشغرى.
والشارح: الشيخ ابراهيم بن محمد بن ابراهيم الحلبى المتوفى سنة ٩٥٦ ست وخمسين وتسعمائة الّف اوّلا شرحا جامعا كبيرا فى مجلد سماه غنية المتملى فاقبل عليه الناس ثم اختصره تسهيلا للطالبين وهو هذا الكتاب المعروف بيننا «بحلبى صغير» والشرح الكبير معروف ايضا بحلبى كبير.

ناشرلرى: برادران كريمفلر

برادران كريموفلرڭ مطبعه‌سى قزانده
١٩١٠

КАЗАНЬ.
Электро-Лито-типографія Т. Д. „Бр. Каримовы".
1910.

23 гыйнварда Казанның Галиев мәчетендә «Хәләби сәгыйр» китабы буларак билгеле «Мохтәсар гөнйәт әл-мүтамәлли шәрех мүнйәт әл-мүсалли» буенча дәресләр уздырыла башлады. Укулар Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашында башланып китте.

Дәресләрне Иордания университеты профессоры шәех Габдерраззак әс-Сәгъди гарәп телендә алып бара. Укулар һәр дүшәмбедә ястү намазыннан соң гарәп телен белүче имамнар өчен уздырыла.

Әлеге китап хәнәфи хокук мәктәбенең намаз кылуга кагылышлы мөһим бер хезмәтләреннән санала. Китап авторы шәех Ибраһим ибне Мөхәммәд ибне Ибраһим әл-Хәләби әл-Кашгарыйның «Мүниятү әл-мүсәлли» китабын киңәйтеп шәрехләгән. Бу хезмәт Идел буе мөселманнарында да киң таралыш алган.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +
2 (278)
февраль 2017

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АЖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

42

28 ЖЕФЕТ КАЛАГА СӘФӘР
Солтан Шәмси

80 САРА САДЫЙКОВА
Рәфкать Кәрами

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Акмулла

ТАРИХИ МИРАС

4 Болгар. Елга вокзалы
6 Илчеләр. *Ә.Мөхәммәдиев*
10 «Сезгә миннән ак теләк...» *М.Фәйзи*
18 Ислам галәменең казык йолдызы. *Х.Вәлиәхмәтов*
23 Ташъязмаларда — газиз тарихыбыз! *Р.Мәрданов, И.Һадиев*
28 Жефет калага сәфәр. *С.Шәмси*

34 МИЛЛӘТ ХӘБӘРЛӘРЕ

ТАТАР ГАМЕ

36 Шәйхелислам. *Х.Миңнегулов*

ТӨРКИ ДӨНЬЯ

42 Атым — пар канатым! *А.Галимҗанов*

ДИНИ МИРАС

46 Ислам дөньясы. *Г.Ибраһимов*
51 2017 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр
52 Ак әби. *Ж.Фазлыев*
54 Зәкиулла Минһаҗев: «Аналарыбыз яшәү көчен каян алган?!»

ӘДӘБИ МИРАС

58 Кутадгу билик. (Котайткыч белем). *Й.Баласагуни*
62 Чыңгызханның ак болыты. *Ч.Айтматов*
66 Гыйбрәтле хикәятләр
70 Әмирхан Еники: «Бу инде Мәһдинең талантын инкарь итү белән бер булачак...» Р.Мөхәммәтша

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

72 Дәрдемәнд

ХӘТЕР САНДЫГЫ

74 Дөреслек — иң бөек көч. *Ф.Садриев*
76 Утлы кисәү. *Л.Гыйльфанов*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Марат Закиров
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары – ТР фән һәм мәгариф министры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-91)

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

СӘНГАТИ МИРАС

80 **Сара Садыйкова.** *Р.Кәрами*
83 **Табигатьнең сәхнәгә бүләге.** *Ә.Минһаҗева*
89 **Талант, иҗтиһад һәм фидакярлек үрнәге.** *Р.Сәгъди*
94 **Илче күчтәнәче.** *Р.Вәли*
98 **Ике яклы гөслә.** *Э.Каюмова*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

100 **Миллият сүзлеге.** А.*Тимергалин*
102 **Җир йөзендә исеме бар, халык өчен җисеме бар!** *Г.Хаҗиева*

ХӘТЕР САГЫНДА

106 **Кылыч**
108 **Казан губерна башкарма комитетының вәкаләтләрен ТАССР вакытлы Революцион комитетына тапшыру турында акт.**
110 **Ябынчы – Мәрҗани туган авыл**

ТАТАР ҖЫРЫ

112 **«Ашказар».** *М.Кәрим*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

114 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1917 елның февраль ае.** *Л.Гобәйдуллин*

ШАЯН МИРАС

116 **Вак-вак лətыйфәләр һәм хикәя кисәкләре.** *Р.Шәрәфиева*

118 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Февраль*
119 **Мирасворд**

Заказ №А-138. Тираж – 1700 данә. Формат 70 Х 108 1/16
Басарга кул куелды: 24.01.2017
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә
Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең
Татарстан Республикасы буенча идарәсендә
ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән
туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61
телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Ш.Абдюшев төшергән, авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – «Куннакка бару». 1964 ел. Киндер, майлы буяу.
И.Рәфыйков рәсеме

АКМУЛЛА
(1831-1895)

Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт берлән...

***

Адәмнән эрелек калмас, күрмәй мохтаҗлык,
Фәкыйрьләр белән утырдашлыкка якын булмай...

***

Кешелексезгә сүзең зая, ялынсаң да,
Әшәке кешегә – үзең тузан, ягылсаң да...

***

Юкәне майлау берлән каеш булмас.

***

Яманны түрә кылсаң – йортың бозар,
Гакылсызны үстерсәң – ботын сузар...

***

Алманы карамадан карамайлар.

***

Йорты Болгар улса улсын, йортны болгар улмасын...

***

Галим булса, милләт өчен зарлы булсын,
Кирәк, ул – бай, кирәк, ярлы булсын!

***

Тургайның тозагына лачын төшмәй.

***

Саф алтынны нәҗескә буяу илән
Нәҗес китәр, алтынның заты китмәс!..

***

Батырны, «батыр», диләр – көчен күргәч,
Останы, «оста», диләр – эшен күргәч.

***

Еланның тышы йомшак, эче зәһәр.

***

Яхшының сүзе татлы-баллы майдан,
Китерер сүз мәгънәсен әллә кайдан;
Кукрәк киерү учак янында киңәш имәс, –
Билгесе ир-егетнең булсын мәйдан!

Текстны **Ләбиб Лерон** әзерләде. ■

Болгар. Елга вокзалы

Сәхифәне Нурсөя Шәйдуллина алып бара.

Музей комплексы белән кушылган Елга вокзалы Болгар шәһәрлегенә чиктәш территориядә, Идел ярында урнашкан.

Комплексның төп вазифасы – елга транспорты белән килүче туристларны кабул итү. Аның эчке структурасы вокзал бинасын һәм Болгарның тарихына һәм мәдәниятенә багышланган музей экспозицияләренең берничә катын үз эченә ала. Бинаның архитектура образы традицион болгар мәдәниятенең мотивларын чагылдыра. Елга вокзалының өч манарасы Болгар дәүләтенең өч зур шәһәре – Болгар, Сувар һәм Биләр образларының символы булып тора. Сувар һәм Биләр манараларында Идел буе Болгар дәүләте удел кенәзлекләре үзәкләренең тарихы буенча мәгълүмат һәм материаллар куелган күргәзмә павильоннары урнашкан.

Болгар музей-тыюлыгының, Татарстан һәм Россия музей җыелмаларының аерым әһәмияткә ия коллекцияләренә нигезләнгән Болгар цивилизациясе музее борынгы Болгарның, болгар цивилизациясенең тулаем дөнья культурасы үсешендәге тарихи ролен ачып бирә. Экспозиция дүрт бүлектән тора.

«Борынгы Болгарны ачу» бүлегендә Болгар турында көнчыгыш, борынгы рус һәм урта гасыр Европа әсәрләрендәге мәгълүмат, шулай ук XIX-XX гасыр башында, совет чорында һәм хәзерге заманда Болгарның мәдәни мирасын өйрәнү һәм саклау тарихы турында мәгълүмат тупланган.

«Болгар цивилизациясенең башлангычы һәм үсеше» бүлеге Идел буе болгарларының килеп чыгышы, аларның Кытайдан алып Көнбатыш Европага кадәр географик киңлектә тоткан урыны һәм роле турында сөйли.

«Борынгы Болгар» бүлеге Болгарны урта гасыр ислам шәһәр культурасы үрнәге буларак тәкъдим итә: аның ныгытмаларын, архитектурасын, төзеклеген, һөнәрчелеген, сәүдә итү рәвешен, халыкара элемтәләрен, шулай ук халкының антропологиясен күрсәтә.

«Болгарның табигате» бүлеге Болгар шәһәре тирәсендәге табигать шартлары турындагы мәгълүматтан тора. ■

ИЛЧЕЛӘР*

Әзһәр Мөхәммәдиев

Р.Заһидуллин рәсеме

...Берничә көннән соң юлчылар Машаек шәһәренә җиттеләр һәм анда озаклап та тормыйча, шул ук көнне Саксин шәһәренә якынлаштылар[1]. Камышлыдан[2] башлап диярлек юл авырайды, коры далалар гына түгел, ә ямнарның сирәгәюе дә сәбәпче иде моңа. Самар, Укәк, Камышлы һәм дә Саксинда болгар патшасы билгеләгән кешеләр идарә итсәләр дә, Болгардан ерагайган саен, аларда оештырылу шартлары төрлечә булып, остаз Баян куйган катгый таләпләр йә килеп җитми яки үтәлеп бетми иде әле, күрәсең. Һәрхәлдә, арыган чапкыннарны яңаларына алыштыру авырлашканнан-авырлашты.

Саксинга барып җиткәч, елга аркылы күренеп торган һәм шаулап агып яткан ике агынты-елга уртасындагы утрауда урнашкан шәһәрне күргәч, атларын яр буенда урнашкан кәрвансарайда калдырдылар. Көймәче аларны шактый зур көймәгә утыртып, бер ярдан икенчесенә сузылган арканга ябышып тарта-тарта, шәһәр ягына чыгарды. Ярга җиткәч, басмаларга сикереп төштеләр һәм шәһәр идарәсе урнашкан йортны эзләп киттеләр.

Утрауда гына урнашса да, шәһәр шактый зур булып чыкты. Йөри-йөри кала идарәсе

*Дәвамы. «Илчеләр» – «Чыңгызхан хәйләсе» әсәренең чираттагы бүлеге

[1] Машаек (хәзерге Әстерхан, IX гасырда төзелгән), Саксин аннан 25 чакрым чамасы Идел буйлап түбәндәрәк урнашкан булган. Археологик казулардан күренгәнчә, ул IX гасырдан алып соңгы чорларга кадәр яшәгән...

[2] Бу шәһәрне әле XIX гасырда да руслар татарчарак итеп – «Камышлов» дип йөрткәннәр.

йортын табарга өметләрен югалткан юлчылар, ниһаять, сораша-сораша, шәһәр уртасында биек итеп салынган әмир Басман сараена барып җиттеләр. Сарай артык зур булмаса да, яхшы итеп яндырылган һәм дүрт кыры да бер озынлыктагы дүртпочмаклы кызыл кирпечләрне әле бер якка, әле икенче якка аударып тезеп, тукылган келәм кебек итеп кирпечләрдән бизәкләр ясап салынган иде. Бибарс белән Тәкин, эзләп табуларына куанып, ихатага уздылар. Ихата эчендә матур гөлбакча уртасында урнашкан мәрмәрдән ясалган бассейн һәм салкын суы бәреп торган фонтан күренде. Юлчылар фонтанга якынрак килеп, тирләгән битләрен су тамчыларына куеп тордылар. Салкынча тамчылар йөзгә рәхәтлек бирә иде. Ул арада сарайның биек итеп эшләнгән ишегеннән, ашыгып, каравыш килеп чыкты.

– Сезгә әмир кирәк идеме, әфәнделәр? – дип сорады ул, юлчыларның арыган йөзләренә, тузанлы өс-башына карап һәм аларның еректан килгәнлекләрен абайлап.

– Нәкъ үзе. Әмир Басман кирәк иде безгә...

– Ул өйдә юк иде шул...

– Без болгар солтанының кичектерелмәс йомышы белән килдек!

– Сүз көрәштерә алмыйм, әфәнделәр, заманасы болгавыр, һич тә болай гына йөрмисездер, әмма әмир чынлап та өйдә юк. Ул мангуллар белән сугышта катнашкан кыпчак бәкләре белән күрешеп сөйләшергә дип киткән иде...

– Анысы нинди сугыш тагын?

– Сез ишетмәгәнсездер әле...

– Юк. Без өч көннән дә артыграк юлда булдык!

– Бик тиз килеп җиткәнсез, әфәнделәр!

– Йомышыбыз шундый.

– Нәкъ менә өченче көн Тимер Капуг[3] янында Сүбәдәй тарафыннан тар-мар ителгән күчмә кыпчак кабиләләре, кичә генә атлары бик арыган-талчыккан булса да, Саксин янында туктап та тормадылар. Артларыннан җен куа диярсең, көнчыгышка – далага таба ычкындылар...

– Шуннан?

– Шуннан шул: Ярый әле качып котыла алганнар, ә без борчуда, чөнки Саксин халкы туган-үскән шәһәрен ташлап китә алмый бит инде! Әмир Басман, үзенең берничә уланын ияртеп, шуларның бәкләре белән сөйләшергә дип артларыннан киткән иде, һаман кайтып җитә алмый...

– Исемегезне сорамадым, абзый кеше, мин үзем – Бибарс, ә юлдашым Тәкин исемле.

– Исемем – Миргали. Сөйләшүең дә, исемең дә безнең якка охшаган. Үзең дә бу яктанмы әллә?

– Шулайрак. Мин – Бөрҗаннан. Ага, бу йортта безгә тамак ялгап алырга мөмкин булмасмы? Без бит юл кешеләре.

– Анысы булыр, әфәндем. Узыгыз аш өенә.

Озак та тормый, ишегалдындагы саман кирпеченнән салынган җәйге аш өennән тәмле исләр тарала башлады һәм бераздан каравыш кунакларны өстәлгә чакырды. Юлчылар, ябшь бүреләр кебек, яңа пешкән тәмле сарык итенә тешләрен батырдылар. Ләкин Бибарсны үзенә тапшырылган вазифа һәрдаим борчып торды, тынгылык бирмәде.

– Әмир Басман бүген кайтырмы? – дип сорады ул каравыштан, сарыкның калак сөяген кимерүен дәвам итеп. Каравышның, ни дип тә әйтергә белмичәме яки дөресен әйтергәме-юкмы, дипме икеләнеп торуын күреп, ачуы чыкса да, ул аны сиздермәскә тырышты.

– Син, Миргали ага, безгә дөресен әйт, – диде ул каравышка исеме белән. – Без

[3] Дербен кирмәне.

бит йомыш кешеләре, эш белән йөрибез. Вакытыбыз да бик тар, санаулы. Әмирнең кайтуы икеле булса, безгә аны көтеп торуда хаер юк.

– Дөресен әйтим алай булса, әфәнделәр. Шул арыган-талчыккан атлы, кайберләре яраланган кыпчак җайдакларын ар якка, дала ягына чыгып үзем дә күрдем һәм сөйләшеп өлгердем. Каф тавы итәгендәге сугышта мангуллар алан кабиләләрен тар-мар иткәч, котырган эт өередәй сарычин җәйләүләренә ябырылып, хатын-кыз, бала-чага өстенә ташланганнар. Ә сарычиннәр – кыпчакның бер кабиләсе, аларның бәге Кайгышбидән үтенеп ярдәм сорап атчабар килгәч, әмир Басман кул астындагы җайдаклары белән Кайгышбигә ярдәмгә ашыкты. Шул көннән бирле без борчылуда һәм башка бернинди дә хәбәр алганыбыз юк... Башта ук сезгә әйтмәгәнем өчен гафу итегез. Чөнки әмир Басман үзе дә, Кайгышбигә ярдәм итәм дип барып кысылсам, солтан Буяннан алда мангулларга каршы сугыш башлап җибәрү булмасмы икән, дип борчылган иде...

«Хәлнең никадәр куркыныч икәнлеген аңлыйлар микән болар?» – дигәндәй, Бибарс бер Тәкингә, бер каравышка карап алды, ләкин бер сүз дә дәшмәде.

Хәл исә чынлап та куркыныч һәм шомлы булып, Басман әмирнең үз белдеге белән дошманга каршы күтәрелүе Болгар иле белән Чыңгызхан арасында сугыш башлануы дигән сүз иде.

– Миргали ага, Саксиннан соң юлларда ямнар бөтенләй булмас инде, чөнки Болгар иленнән бөтенләй дала-кырларга чыгып китәбез. Шуңа күрә, безгә куш атлар[4] кирәк булыр, – диде Бибарс, өстәл яныннан кузгалып. – Без нәкъ менә шул – Каф тавы итәгенә юл тотабыз да.

Каравыш, борчулы күзләрен юлчыларга текәп:

– Болгар патшасы йомышчыларына яхшы куш атлары табарбыз, – диде. – Тик менә бик афәтле юлга чыккансыз, энем. Бик яшь күренәсез үзегез. Мангул нөкәрләрен, миһербанның ни икәнлеген дә белмәгән бәндәләр, дип сөйлиләр...

– «Тегермәндә туып үскән тычкан күк күкрәвеннән курыкмас», – диләр, Миргали ага. Без – чаушлар, – диде битараф тавыш белән Тәкин.

– Каф тавына кай якка таба карап юл тоту уңайлырак булыр икән? – дип сорады Бибарс.

– Иделнең сул ягы ярыннан диңгезгә таба төшсәгез, атларыгыз да, үзегез дә тук булыр идегез, ләкин Иделнең түбән агышында аның күп санлы тармакларын кичеп үтү кирәк. Ә инде тизрәк барырга ниятләсәгез, Иделнең уң ягына чыгып, көйгән далалар аша юл тотарга кирәк булыр.

– Әлбәттә, – диде Бибарс, – Иделнең сул яры буйлап билдән куе үләнле яшел үзәннәр аша бару яхшырак булыр иде. Ләкин вакытыбыз бик тар, юлны кыскарту йөзеннән, далалар аша турыга гына бару безгә яхшырак булыр.

Шул ук кичне төнге җиләздә юл алып калыйк, дип, алар куш атларын тезгеннәреннән ияргә тагып, атланып юлга чыктылар. Башта Миргали каравыш киңәшен тотып, Саксин чиген тәшкил иткән агынты аша салынган күпердән үтеп, көнбатышка таба юл тоттылар. Иге-чиге булмаган камышлыклар һәм чокыр-чакырлар, челәннәре сыңар аякта тезелеп утырган агынты буйларыннан аларны, адашып йөрмәсеннәр өчен, яшь тайга атланган Бүзнәк исемле егет Иделнең Тимеркән исемле соңгы агынтысына кадәр озата барды.

Камыш белән капланган сулыкларны, төрле зурлыктагы күлләрне, сазлыкларны урап үткәнгәме, юл озакка сузылды һәм көн кичкә дә авыша башлады.

Шактый киң һәм тирән булып күренгән Идел суының соңгы агынтысы ярларына килеп җиткәч, юлчылар югалыбрак калгандай булдылар.Чөнки Идел тамагындагы бу елга, Болгар шәһәренә терәлеп аккан мәшһүр Болга елгасы кебек үк диярлек, киң һәм мул сулы булып күренде.

---

[4] Куш ат - запас ат.

– Төнгә кадәр мондый киң елганы кичеп чыгарга өлгерербезме соң?– дип сорады Бибарс, тыныч кына агып яткан елганы күзәткән Бүзнәккә карап.

– Минемчә, куш ат таккан килеш, мондый кайнап агып яткан зур елганы, гомумән, кичеп чыгу мөмкин түгел! – дип өстәде Тәкин борчулы тавыш белән.

– Бу безнең шәһәребезне көнбатыш тарафтан, мангуллардан да дим, саклый торган Иделнең бердәнбер мул агымлы Бәхтимер исемле елгасы инде.

– Шулаен ул шулайдыр да, тик ничек итеп безгә ар якка чыгарга соң?

– Күз алдыңа китер, – диде Бүзнәк, – зур көймә, яки башка җайланма яр буенда чайкалып торса, нәрсә булыр иде соң?

– Нәрсә булсын, аргы якка чыгарга уңайлы булыр иде!

– Ә теге якка мангул җайдаклары килеп, зур көймәне күрсәләр, куанырлар идеме? Ә аннары Тимеркәнне кичеп, безнең шәһәр халкын суеп бетерер иделәрме?

– Ярар, Бүзнәк, күп сөйләшүдән файда юк. Безгә ашыгырга кирәк! Куш атларны калдырып китәрбез, булмаса.

– Мин бит, булмас, дип әйтмәдем! Зур көймә бар, ләкин ул дошманнар күзеннән яшереп, камыш белән капланган, әнә теге кибеп бетә язган язгы агынтыга кертеп куелган, дип кенә әйтмәкче булам.

– Бик яхшы! – диде Бибарс, сөенүен яшермичә.

– Көймә зур, атлар да сыярлык. Тик теге якка чыкканнан соң аны яр буйлап югарыга бер-ике йөз адым тартып менгерер өчен, миңа ярдәм итәрсез. Бу якка исә, агым уңаена, үзем дә алып чыга алам мин аны.

Караңгы төшәкәндәрәк, алар Иделнең текә ярыннан яшел үләне әле көеп бетмәгән бер үзәнгә җитеп, төнгә урнаштылар.

Ашыкмый гына атларын тышаулаганнан соң, Бибарс комлы яр буенда куак төбендә чоңгылланып аккан суга карап торган Тәкин янына килде. Чоңгыл өстендә эре-эре балыклар чиртколәгәнен күреп, ул:

– Һай, кармак та булса, балык тотар идек! – диде.

– Анысы булыр, – диде Тәкин, кесәсеннән кулъяулыкка төрелгән берничә бакыр болгар пулы һәм ат кылы уралган кармак йомгагы чыгарып.

– Сак, хәстәрле кеше икәнсең, Тәкин! – диде Бибарс, сөенеп.

Шактый тиз арада зур гына итчән, берничә опты һәм җимне алыштырып, балыклар патшасы саналган акбалык та тотып өлгерделәр. Бу тирәләрдә Иделнең балыкка бай булуын Бибарс ишетеп тә белә иде. Ул аскы ягындагы ботагы кармак кебек итеп калдырылган тал чыбыгына саңакларыннан тезелгән балыкларны алып китмәкче булган иде дә, артыннан Тәкиннең иярмәвен сизенеп, туктап калды. Тәкин исә, ашыкмый гына кесәсеннән кармак төрә торган коры кулъяулыгын чыгарып, аны селекте дә, буйдан-буена кармак кылын сөрткәләде, ә кармагын юеш җимнән чистартып, җентекләп корытты. Аннары гына кармак кылын калкавычка тигез итеп урады да, кармагына җиткәч, аны махсус коры камыш кисәгенә кадап куйды. Бары шул эшләрне башкарганнан соң гына ул урыныннан кузгалды. Болгарларның шулай һәр эшне җиренә җиткереп, төгәл итеп башкарырга яратканлыкларын белсә дә, Бибарс моңа янә бер кат гаҗәпләнде.

Бераздан юлчылар Миргали биргән кечкенә юл таганын чокырга көйләп, астына учак ягып җибәрделәр. Тиздән күк тулы йолдыз җемелдәгән дөм караңгы төн урнашты. Учак янына утырып, тәмле балык шулпасы ашадылар. Якында учак яктысында утлап йөргән атлар күренә, ә кичке һавада яр буендагы үлән арасыннан күпсанлы кыр чикерткәләре авазы бөтен галәмне яңгыратып, бертуктаусыз скрипка уйнагандай, колакларга һәм күңелгә ләззәт биреп тора иде.

Дәвамы бар ■

Безнең мирас №2 февраль 2017

СЕЗГӘ МИННӘН АК ТЕЛӘК...*

Мирхәйдәр Фәйзи

ИЛЛЕ БЕР КӨНЛЕК СӘЯХӘТЕМ ЯХУД МАЛМЫЖ СӘФӘРЕ ХАТИРӘСЕ 1916 ЕЛ

ШОДА

Шода дигән су буена утырган 235 өйле, 1333 халыклы, ике мәсҗедле зур гына авыл. Үзендә кантор, ягъни волостной правление, ике су тегермәне, ике ирләр мәдрәсәсе, бер кызлар мәдрәсәсе, пожар әсбапларыннан ике насос, сигез пичкә[1] вә башкалар бар. Һәм һәр ел имана башына 4 агач микән кисеп, арттан үстерә барган бетмәс хәзинә – 500 дисәтинә урманы бар. Сәедгәрәй абзыйларда укулар ирләр һәм кызларда яхшы, вә имкяне[2] табылган кадәр тәртип белән булып, аръяк мәхәлләдә искечә икән. Ике мулла арасы һәм төзек булмыйча, Шакир мулла Сәедгәрәй абзый өстеннән донос ясап берничә тентү дә ясаткан. Бу якта уку-укытуның яхшы юлга салынуына Ишми зур манигъ[3] булып тора икән.

Шода суына тагы бер Шурма дигән су килеп кушылып, авыл өч кыйсем булып тора вә Шода очы, Үре очы, Яре очы дип ата-

[1] Пичкә – бочка.

[2] Имкян – мөмкинлек.

[3] Манигъ – киртә, тыючы.



Малмыжда Камал жизни Мозаффаров йортының планы. Асты – фатир, өсте мәсҗед булган бер йорты урын тарлыктан сыймады. Бакчаның иңе һәм киңрәк кирәк иде

*Дәвамы. Башы 1 нче санда

Мирхәйдәр Фәйзинең туганы Сәгыйть Сәедгәрәй улы (уртада). Рәсемдәге бинада хәзер музей урнашкан. Балтач районы, Шода авылы. 1972 ел

ла. Тегермәннәреннән берсе авылның үзенеке булып, бер урыска арендага бирелгән. Нәрсә тарттырганда сугышка кадәр бер тиен бирәләр икән. Хәзер кыйбатланып тиен ярымга менгән. Сәедгәрәй абзыйларның йорт-җирләре вә тормышлары бик шәп. Зур ишегалды эчендә зур алма бакчасы белән башка каралтылары бар да йитеш. Сөйләп бирү мөмкин булмаганга, алда планын ясап куячакмын. Минем үземә бер бик матур бүлмә – намазлыгы белән тәсбихына кадәр йитеш. Мин торган бүлмәнең асты малай өе, өсте чардак булып, авыл җирендә 3 кабатлы өй күрү безнең өчен бик ят вакыйга. Ләкин монда алай түгел. Һәр авылда, хосусан муллалар өе шулай. Асты таш, яхуд ике каты да таштан булган гаҗәп формалы өйләрнең бер авылда берничәсендә очрала. Агачтан гына салынган өйләр дә, бу якка гына хас бер формада бик матур итеп салынганнар. Тәрәзәләр капкачсыз булып, читләре ярты аршин киңлегендә бик матур челтәрләп эшләнгәннәре бар ки, бу зиннәт безнең яктагы өйләрнең төшенә дә кермәгән әле. Дәхи кыек өстенә ясалган бертөрле чардак та минем дикъкатемне җәлеп итте. Сәедгәрәй абзыйларның өйләре бик уңайлы формада салынып, уңайлы худлар[4], һәйбәт пичләр, җиһазлар-фәләннәр бар да шәһәрдәгечә. Безнең яктагы авыл муллалары белән мондагылар арасында тиңләштерү мөмкин булмаган бер аерма.

ТҮНТӘР

22сендә Сәедгәрәй абзый белән, 23енә дип дәгъвәт ителгән Балтачның Сабирҗан мулла мәҗлесенә баруга җыенып, Түнтәргә барып кундык. Бөтен Русиягә мәшһүр булган бу авылның ил дошманы булган кешесенә үк барып төшеп кунак булу ничектер мәкруһ[5] күренгәндәй булды.

Түнтәр – ике мәсҗедле, Шодадан кечерәк бер авыл. Һәйбәт өйләр

[4] Худлар – юллар.

[5] Мәкруһ – начар күрелгән, ямьсез.

байтак булса да, Ишминең өйләре арада бер дворец кебек тора. Ике катлы булмак үзрә, асты таш, өсте агач. Урамга 15 тәрәзәләр караган бу өйне авыл җирендә дворец дип атау мөбаләгаләр[6] булмаса кирәк. Ишегалдына да әллә никадәр сузылып малай өйләреннән башка 20дән артык бүлмә санадым. Җиһазлар бар да мөкәммәл, бер тарикате әһлиянең йорты дип атарлык түгел. Безне Ишминең олуг угылы Нәкыйп белән кече угылы Нурлыгаян каршы алдылар. Габделхәйгә без вәгъдәсезлек эшләү сәбәпле, ул кайтып йитмәгән иде әле. Өченчеләре булган Нурислам Пермьдә бухгалтерлыкка укый икән. Балалары гаять һәйбәт вә яшь фикерле кешеләр булып, аталарының эшләреннән чын-чыннан җирәнәләр.

Кичке чәйне эчкәч, Ишминең безне кабул итәчәген белдерделәр. Миңа министр хозурына кабул ителгән кебек тоелып китте. Аның каршысында тезләнеп кенә утыру тиешлеген вә башка адәпләрен миңа алдан белдереп куйдылар. Күп бүлмәләрне үтеп, простой гына җыелган Ишми бүлмәсенә барып кердек. Яшел чапан, бохарча ураган чалма киеп идәнгә утырып куйган. Сәлам биреп, җиргә [идәнгә] тезләнеп күрештек. Каршысына тезләнеп утырдык. Авырудан терелеп килгән чагы икән. Башын түбән иеп кенә утыра. Мине кода дип, бик хөрмәт итеп, кадерләп кенә сөйләшә. Сөйләшүе бик йомшак. Сугыш хәлләрен дә сорашкалап ала. Бәгъзән көлке сүзләр дә әйтеп куя. Сәедгәрәй абзый сүзләрен хуплап: «Дөрест, тәкъсыйр[8], шулай, тәкъсыйр», – диеп кенә утыра. Мин сораганына гына җавап бирәм. Янында ярты сәгатьтәй утырдык. Бу мөддәт минем аякларны тәмам изде. Алдымда ишан барлыкны онытыр хәлгә килдем. Ләкин аның алдыннан үзең рөхсәт сорап чыгу хөрмәтсезлек вә аның «рөхсәт инде»сен көтү адәптән икән. Ходай иманын юлдаш иткере: «Ярый, рөхсәт инде», – дип кул күтәрмәсенме. Сәедгәрәй абзыйга бернәрсә түгел, мин аксый-аксый чыгып киттем. Нәкыйп безне: «Министерстводан» бушандыгызмы?» – дип каршы алды.

Иртәгәсен 23ендә бөтен дөньяны болыт каплап яңгыр коя гына. Без Балтачка барудан ваз кичтек. Иртә чәйне без кунган бүлмәдән ике бүлмә аша бер бүлмәгә идәнгә әзерләгәннәр иде. Моның сәбәбе – Ишминең безнең янга чәйгә чыкмакчы булуы икән. Тагы аякка бәла. Ләкин бер генә чынаяк эчеп чыгып китте. Бу безне илтифаты[10] белән мөшәррәф[11] итүе икән. «Мәҗлескә өлгермәсәгез дә кичкәрәк барыгыз, Хәйдәр андагы кодаларны да күрсен», – дип китте. Чәйдән соң кодагый кереп күрешеп чыкты. Алар шундук Балтачка киттеләр. Төш вакытында яңгыр туктады. Аштан соң бакчаларга бардык. Кура җиләгенең кызылы, агы, кара вә кызыл карлыганнар, крыжовник, чия вә алмалар кып-кызыл булып пешеп утыралар. Туйганчы ашадык. Җиләкләрнең бу кадәр күп булуына мин гаҗәпләндем. Ул варенье кайнатулар, как коюлар, киптерүләр хисапсыз. Бер чәй янына 4-5 төрле варенье китереп тезәләр. Аш арты урынына җиләк кенә хезмәт итә. Кура җиләгенең агы, кызылы, карасы да була икән. Кура җиләгенең кадагы 8 тиен.

[6] Мөбаләгә – арттыру, күпертү.

[7] Тарикате әһлия – дини кеше.

[8] Тәкъсыйр – руханиларны олылап эндәшү.

[9] Мөддәт – ара, вакыт.

[10] Илтифат – олылау, яхшы кабул итү.



Шодада Сәедгәрәй абзыйлар йортының планы

САСНА – БАЛТАЧ – САСНА

Сәгать 4ләрдә без Балтачка киттек. Юлда Сасна авылында Нәкыйпнең бабасы Сөләйман мулла Даудов капкасына туктап, угылы Фатыйхны күреп киттек. Бу миңа электән беркадәр мөнасәбәтле иде. Гаскәрилектән калу өчен, тимер юлда приказчиклык хезмәтендә тора икән. Бик күңелле егет күренде: «Кайтышлый керегез», – дип, бик чакырып калды. Сасна – 5 мәсҗедле зур авыл. Балтач Саснадан ике чакрым гына ары булдыгы хәлдә, Казан өязенә караган ике мәсҗедле, базарлы, ярминкәле, байлары күп бик төзек бер авыл икән. Малмыждан Казанга киткән олы юл өстендә булып, урамнан ун чыбыклы телеграм баганалары үтә дә авылга зур ямь булып тора. Бу яктагы олы юллар, ягъни Малмыждан Казанга, Малмыждан Вяткага, Малмыждан Пермьгә киткән юлларга тигез итеп таш түшәлеп, ике читенә тирәкләр тезелгәнгә, ифрат күңелле ул юллардан йөрү. Читтән караганда юл буенча тезелеп киткән агачлар матур күренеш ясап торалар. Бигрәк тә Казан юлы шәп. Малмыждан Казанга йиткәнче юлдагы таулар киселеп һичбер үр менәргә, чокыр төшәргә туры килми, ди. Ләкин вак юллар бик казылмалы бу якта.

Шодадан Балтачка кадәр шушы авылларның эченнән үттек: Тау Өсте, Луб, Урбар, Түнтәр, Карлыган, Сасна күренеп кала; Пабанюр, Кутәш, Биктәш, Янгыл Иле, Көшкәтбашы, Көшкәт Пучинкәсе, Ижа. Ягъни 37 чакрымдагы Балтачка барып йиткәнче күз 15 авылны күреп өлгерә. Балтачта без барган Сабирҗан мулла Сәгъдетдинов – бер мәсҗеднең мулласы вә Ишминең баҗасы, бай бер мулла. Капканың ике ягында икешәр катлы ике зур өй, шәп бер алма, җиләк бакчасы, пима[12] бастыра торган йортлары бар. Сәүдәсе пималар белән булып, Мәкәрҗә, Мәскәүләргә барып эш итә икән. Финляндиядә бер выставкада зур алтын медаль бирелгән. Бик күп пималар эшләп куйганнар. Казанга байтак эшләгәннәр. Үзе бик шәп

[11] Мөшәррәф итү – кадерләү, хөрмәтләү.

[12] Пима – киез итек.

Мирхәйдәр Фәйзинең абыйсы Сәетгәрәй Фәйзуллин хатыны Фатыйма һәм балалары һашим, Икрам, Сәгыйть белән

кеше булган кебек, бик һәйбәт угыллары бар. Өлкәне вә хатынын йортка төшереп бу мәҗлеснең ясалуына сәбәп булганы – Шәриф, үзе янында мулла. Элек ак якаларда гына йөргән бу егет, 1914 нче ел ничек чалма-чапанлыга түренгәнен сизми дә калган. Кодеснең Бохара бизгәге белән авыру көннәре иде. Призыв эше белән шундый хәлләргә дучар булган ахры. Казанда «Мөхәммәдия»дә укый икән. Бик күп белә. Бик күңелле егет. Тагы Мирзасалих дигән кечкенәләре бар.

Без капкадан барып кергәндә ишегалды тулы мулла иде. Кайсы комган күтәреп каядыр бара, кайсы җуынып утыра, кайсы арбага төялеп ята, кайсыберсе өелеп-өелеп тик торалар. Күрешә-күрешә җөдәп беттем. Берәүгә кунакка барырга торалар иде. Никадәр кыстасалар да мин мәҗлескә йөрмәдем. Малик белән карап йөрдек. Без Балтачта кундык. Муллалардан да унаулабы кунарга калды. Алар шушылар: Гариф бине Әхмәт Таузари, Зыяэддин Миначов Иске Смәилнең, Борнакның Салих бине Мөхәммәтҗан, Урның Зариф вә Фәйзерахман Фозуровлар, кайсы авылныңдыр Гариф бине әлләкем әл-Хәсән шәйхе, Мәтәскәнең Фатыйх бине Шәкүр Яхин вә башкалар. Һәркайсы җәдид вә күңелле яшьләр вә муллалар. Мәҗлесләре бик кызык булды. Арадан төскә дә матур вә җагымлы, картрак Фатыйх мулла гына, безнең Мәгазибез дип тәкъдим иттеләр. Ләкин Мәгази шикелле тиле вә фахиш[13] түгел, дип

[13] Фахиш – начар, бозык.

ялгадылар. Мәгази шушы тирәдәге Мәчкәрәдә укыганлыктан, аның хакында мәгълүматлары бар. Муллаларның арасында Зыя исемле бер көлдергечләре дә бар. Мин бу якта бөтенләй шагыйрь, мөхәррир булдым да киттем. Муллалар арасында да пачут шәп. Җирендә ноль дәрәҗәсендә булсаң да, читкә яңгырабрак ишетелә ахры. Шул шагыйрьлек җәһәтеннән һәркайсы ихтирам күрсәтеп маташалар ки, соңга таба вөҗданым күтәрә алмый башлады.

Иртә чәйгә Ишми дә чыгып, барыбызның да аякларыбызны «Себергә» йибәрде. Миңа бик илтифат күрсәтте. Бер-ике мулладан түргә утыртты. Ләкин мин алда[н] чыгып киттем, түзә алмадым. Балтачтан Саснага, Фатыйхларга килдек. Анда аш ашап, чәй эчтек. Аталы-уллы икесе дә бик һәйбәт кешеләр [дип] таптым. Мулла байтак мәгълүмат чәчә. Татарча гына түгел, төркичәнең дә бик күп тарих вә гыйльми, әхлакый рисаләләрен, романнарын укыган. Минем дә язганнарым хакында мәгълүматы бар. [...] Мулланың миңа булган хөсне заны[14] бөтен көенчә аерылып киттек. Бакчалары бик зур, чиксез һәйбәт иде. Түнтәргә керми, сугылып кына китеп, икенче юлдан Чипья, Корамьял, Күнәрләрнең эченнән үтеп, Чиркас, Яңгучи, Урчиял исемле авылларны сырттан күреп китеп, Шодага кайттык.

ШОДА

«Аң»да[15] шигырьләре була торган Рокыя Ибраһимия[16] дигән хатын Балтачта булдыгы хәлдә, моннан хәбәрсез калганга үкендем. Соңынтын аның да: «Күрешкән булыр идем, белмәдем», – дип үкенгәне ишетелде. Шул тирәдәге «Көшкәтбашы» авылының бер яшь мулла хатыны икән.

Шодада көннәр бик-бик күңелле уза. Авыл минем күңелемнең Кәгъбәсе булганга, Шоданың авыллыгы мөкәммәл булып, күптән көттегем бәхетемә юлыкканга бик шат идем һәм алданмадым. Берничә көннән үк иске фикеремне тагы ныграк беркеттем. Дөньяда авыл мужигыннан бәхетле кеше юктыр. Ләкин бу бәхеткә ирешү безнең өчен университет бетерүдән дә авыр. Мужиклык кулдан килми.

Иң матур, иң изге күренеш күңелемә:
Авылым ул – җаннар яме, ямьнәр яме!
Чын матурлыклар белән нурлап, бизәп,
Ул минем күңелемне гөлләп ямьләде.
Анда чын сафлык вә иркен, көр күңел,
Анда тик ачкан колачлап ямь йөзен;
Үз күрәм көнкүрмеш халкын, барын:
Картларын һәм яшьләрен, егетен, кызын.
Бик сөям киң җабырылып йөргән малын:
Атларын, сыерын, сарык, кош-корт – барын,
Җомылып аккан җылгасын һәм талларын,
Тауларын, ындырларын, киң кырларын.
Юк тәкәллефләр[17], авыл ул бик садә[18],
Анда мин чынлык күрәм, чын төс күрәм;
Типсә, бер тимерең өзәр, куллар таза,

[14] Хөсне зан – яхшы теләк (уй).

[15] «Аң» – 1912-1918 елларда Казанда чыккан әдәби-фәнни, иҗтимагый-сәяси, рәсемле журнал.

[16] Ибраһимия (Ибраһимова) Рокыя – XIX йөз ахыры-XX йөз башында яшәгән шагыйрә, абыстай.

[17] Тәкәллеф – ясалмалык.

[18] Садә – гади.

Анда чын тормыш, күрәм, чын көч күрәм.
Тик авыл җыйган җиһанның бар ямен,
Күңелемә мөнбәр авыл, мин зурлыймын;
Шунсы бар: туктыйм ирексез, җитми көч,
Җырларым таплар ямен, дип шүрлимен.

Җиңгинең ачыклыгы, мулла хатыны булуына карамый безнең белән тәмам фикердәш булуы, яңалыкның иң чокырдан торганыннан да йөз чытмавы, фәләннәр белән өйдәге тормыш никадәр күңелле булса, тыштагы эшләр, бигрәк тә матур су буе манзарасы мине тәмам сихерле. Кояшны көн дә су юлында озатам. Бу су юлын шулкадәр матур итеп җыештырып куйган, Ходайга рәхмәт инде, дип уйлап куям кайчакта. Яшел чирәмне уеп кына агып киткән камышсыз-комсыз су, тезелеп киткән матур агачлар, челтерәп агып яткан чишмәләр белән җәннәтнең әһәмиятен бетереп торган бу күренешнең санигымы[19] дим, архитекторымы булган Ходайга күңелем ихласлы сәҗдәләрен тәкъдим итә башлый. Шунда мин караңгылыкны каршылыйм. Кеше өзелми йөреп тора. Урактан кайталар. Чишмәгә төшәләр, басмага төшәләр. Моңарчы хикәяләрдә генә укыган бу як тормышын үзем күреп, үзем аралашып йөреп, күп кенә серләренә вакыйф[20] булдым.

КУГНУР

24ендә Кугнур Шәйхи мөәзингә барып кайттык. Үзе рәсми мөәзин булдыгы хәлдә, йөз мең белән эш иткән бу кешенең йорт-җир, тормышлары да гаять шәп. Кибете – авылга күпсенердәй дәрәҗәдә мөкәммәл магазин. Баласы Мәкәрҗәдә[21] иде. Җиләк бакчасы ифрат шәп булып, эченә кергәч кып-кызыл җиләккә күмелеп каласың. Биек булып үскән кураның арасына кереп китеп, кандай кып-кызыл пешеп, агарга торган җиләкләрен өзеп ашауларның никадәр кызыклыгын тәгъриф[22] итеп бетү мөмкин түгел. Бөтен ишегалдыларына таш түшәлеп, әллә нинди бер шәһәр бае ишегалдына барып кергән шикелле тоелып китә. Урамга да һәйбәт тратвар[23] эшләткән. Хәер, бу кадәресе һәр авылда бар. Таш түшәлмәсә дә, урамның ике ягына канау ясап читенә агачлар утыртылган. Бәгъзеләре агачны рәшәткәләп-рәшәткәләп куйганнар. Шодада да бер урам шулай.

Шәйхи мөәзин садакага төшкән акчаларын аерым җыеп барып, ел тулганда мәсҗед-мәдрәсә файдасына бирә икән. Мәет юарга кеше яллап тотып, азан әйтергә үзе йөри, ди. Чәй янында балга болгаган киндер орлыгы ашадык.

[...]

ТУШТУ – АРЖЫМ – СУХАРИК – ШУРМА

Зеннән, Сәедгәрәй абзый белән, җимеш бакчалары күплеге белән мәшһүр Тушту авылына бардык. Барганда Дубровка, Гарь исемле авыллар үттек. Урыс авыллары татар авылларына караганда төзегрәк. Һәм урак, басу машиналары да байтак күренә. Тушту 50-60 йортлы гына авыл булса да, төзеклеге искиткеч. Урамның бер ягына

[19] Санигы – ясаучысы.

[20] Вакыйф – аңлаучы, эшнең төбенә төшенүче.

[21] Мәкәрҗә – Русиядәге иң зур ярминкә урыны.

[22] Тәгъриф – таныштыру, аңлату.

[23] Тратвар – тротуар.



Сухарик авылы планы

өйләр, каршыга бакчалар тезелеп киткән, шунлыктан манзарасы бик күңелле. Бакчалар да план белән тезелеп китеп, рәшәткәле, буяулы. Йортларының яртысыннан күбесе таш һәм икешәр катлы булып, һәр җире мөкәммәл китереп эшләнгән. Боларны бу дәрәҗә бакча баеткан.

Без төшкән урыс, былтыр 700 сумлык алма гына саттым, ди. Ул башка җимешләрнең хисабы юк. Бик шәп бакчасында пешкән, пешмәгәннәрдән шушы нәрсәләрне күрдек: кызыл, ак, кара кура җиләкләре (13 сорт кура җиләге бар нибарысы); кызыл, ак, кара карлыган; чия, крыжовник, җир җиләге, кызыл бөрлегән, виноград вә эрбет чикләвеге. Ул алмалар әллә тагы 50 төрле. Һәркайсының исемнәрен язып куйган. Бөтен тирәгә агачлар болардан сатылып, утыртып бирергә дә болар чакырылалар икән. Бакчачы, чәй эчереп, кунак итеп йибәрде. Яңа салынып бетеп килгән, 7000 сумга төшкән өен күрсәтеп йөрде. Вареньега җиләкләр, алмалар алдык. Кайтканда икенче юлдан Әсәйяк, Аржым, Сухарик, Шурма дигән авылларны үтеп кайттык. Аржым бик зур авыл. Байлары күп. Хосусан бер байның йорт-җирләре ис китеп карап торырлык. Чиркәү Малмыж чиркәвеннән күп һәйбәт. Сухарик та шәп. Моның бер хасыяте шул: Туштудагы кебек, бер як йортлар, каршыда – бакча. Ләкин болай гына калмый, бу бакчага тагы бер катар[24] бакча арка сөяп, аның каршына өйләр тезелгәнгә, ничек бу дәрәҗә осталык белән эшли алганнар, дип хәйран калырлык. Болай әйтү белән генә аңгартып булмады әле, рәсемне карагыз.

Шурма авылы да берьяклы утырган. Аның каршысына келәтләр, сарайлар, бакчалар тезелгән.

Текстны басмага Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе Сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлеге баш библиографы ***Рәйсә Шәрәфиева*** *әзерләде.*

Дәвамы бар ■

[24] Катар – рәт.

Безнең мирас №2 февраль 2017

ИСЛАМ ГАЛӘМЕНЕҢ КАЗЫК ЙОЛДЫЗЫ

Хөсәен Вәлиәхмәтов

Муса Бигиев. 10 июль, 1908 ел

XIX вә XX гасырлар аралыгын татар дөньясында гаять зур үзгәрешләр, яңарыш вә исләхать (реформа) чоры дип бәяли тарихчы һәм сәясәтче галимнәребез. Шушы ике гасыр эчендә туган, яшәгән, иҗат иткән, тиңдәшсез ачышлар ясаган әдәбият һәм сәнгать әһелләре, фән һәм дин, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре, легендар шәхесләребезнең исемнәре генә дә санап бетергесез. Алар өйрәнелде, өйрәнелә һәм өйрәнеләчәк. Бу нисбәттән галимнәр, фән эшмәкәрләре, әдәбият белгечләре шактый гына тикшерү-эзләнүләр алып бара.

Дөрес, бөтен мирасыбызны халыкка кайтару, аны киләчәк буыннарга җиткерү кебек гаять катлаулы һәм четерекле эшне колачлап бетерү мөмкин дә түгел кебек. Әле күпме шәхесләребезнең исемнәре, күпме әсәрләр, рухи кыйммәтләр архив киштәләре тузаны астында эзләнүчеләрен көтеп ята бирә. Шулар арасында әлегәчә бөтен иҗаты, эшчәнлеге, хезмәтләре киң җәмәгатьчелеккә ачылып җитмичә, күләгәдәрәк калып килгән бөек мәгърифәтче, ялкынлы публицист, дин белгече, сәясәтче, философ, нәшир, язучы-тәрҗемәче Муса Бигиев тә бар.

Бу даһи милләттәшебезнең исеме бөтенләй онытылган, дип әйтеп булмый, әлбәттә. Аның кыскача биографик белешмәләре белән «Татар энциклопедик сүзлеге»ндә (Казан, 1999), күптомлы «Татар энциклопедиясе»нең беренче томында (Казан, 2002), «Әдипләребез» дигән библиографик белешмәлекнең I томында (Казан, ТКН, 2009) танышырга мөмкин. Замандашларыннан берсе булган Габделбари Баттал-Таймасның «Муса Ярулла Биги: тормышы, эшчәнлеге вә әсәрләре» (Казан, 1997) китабында, Төркия галиме Мәхмәт Гүрмәзнең «Муса Җаруллаһ Бигиев» китабында (Әнкара, 1992), Айдар Нил улы Юзиев, Әбрар Кәримуллин, Яхъя Абдуллин, Индус Таһиров һәм башка күп кенә галимнәрнең, язучыларның басмаларында, газета-журнал битләрендәге мәкаләләрендә тулырак мәгълүматлар да бар.

Ләкин Муса Бигиев иҗатын, аның тормышын, эшчәнлеген өйрәнүгә аеруча күп көч куйган, бәрәкәтле эш башкарган кеше Айдар Хәйретдиновтыр, мөгаен. Мәрхүм Вәлиулла хәзрәт Якуб тарафыннан оештырылган «Иман» нәшриятында 1999 елда Айдар Габдулловичның беренче монографик басмасы дөнья күрде. Авторның фәлсәфә фәннәре буенча кандидатлык диссертациясенең нигезен тәшкил иткән ул хезмәт «Последний татарский богослов» дип атала иде. Китапка фатиха сүзен язган мәшһүр галимебез Яхъя ага Абдуллин, титаник шәхеснең халыкка кайтуына сокланып, болай ди: *«Хәзер аңлашыла, Муса Бигиев – кыяташ кантары икән... Аны өйрәнү өчен аерым махсус институт булдырырга кирәк...»*

Әйе, хак сүзләр әйткән Яхъя ага. Әмма исемнәре югарыда санап кителгән галим-эзләнүчеләрдән башка бу бөек шәхесебезгә игътибар итүчеләр юк диярлек. Әлегәчә бернинди институт-мазар да күренми. Шул ук Айдар әфәнде Хәйретдинов тырышлыгы белән, төрекчәдән үз тәрҗемәсендә Татарстан китап нәшриятында 2005-2006 елларда Муса Бигиевнең сайланма әсәрләреннән ике томлык төзеп чыгарылды. Ләкин бу хезмәтләр Бигиев мирасының йөздән бер өлеше генәдер, мөгаен. Айдар әфәнде үз монографиясе ахырында Муса Бигиев хезмәтләренең 90га якын библиографик исемлеген бирә. Әмма ул хезмәтләрнең үзен кулга тотып укып караучылар бармы икән бүген? Юктыр, чөнки 1925-1930 елларда илдә аның хезмәтләрен бастыру катгый тыела. Ә шуннан соң гомеренең соңгы көннәренә чаклы мөһаҗирлектә язылган дөньякүләм әһәмиятле китапларының кайсы илләрдә, нинди архив, китапханә шүрлекләрендә ятканы да мәгълүм түгел. Бу турыда йөз елдан соң, бүгенге мөхтәрәм әдипләребезнең берсе – Татарстанның халык язучысы, Коръән аятьләренең татарча мәгънәләрен өйрәнүгә зур көч куйган Рабит ага Батулла да ачынып яза. Казанның «Җыен» нәшрияты 2012 елда Рабит ага әзерләгән Коръән тәфсиренең яңартылган бишенче басмасын чыгарды. Авторның шушы басмага язган кереш сүзендә мондый юллар бар: *«Татарның мәшһүр акыл ияләре дә борынгы философларның әсәрләрен өйрәнгәннәр... Шулар арасында дин галиме Муса Биги аерым урын тота. Ул, гарәп, фарсы, урыс, төрек телләрен мөкәммәл белүе өстенә, диннәрнең тарихын, тәгълиматын чагыштырып өйрәнер өчен, дөнья буйлап сәяхәт итә... Коръәндәге кайбер аңлашылып бетми*

Муса Бигиевнең (рәсемдә уңнан беренче) Каһирәдә укыган вакыты. 1900 нче еллар башы

торган, беренче карашка каршылыклы булып күренгән аятьләрне үзенчә аңлата, шул турыда күп китаплар, мәкаләләр яза һәм бөтен ислам дөньясында шөһрәт казана, олуг остаз данын яулый. Без – кайчандыр, күп халыкларга гыйлем биргән, дин өйрәткән халык балалары, бүген бичара хәлдә; дин өйрәтүне төрекләрдән, гарәпләрдән көтеп ятабыз.... Ләкин Курсави, Фәхреддин, Биги кебек дин галимнәребезнең бөтен Гарәбстанына, бөтен Төркиясенә, бөтен Һиндстанына – бөтен Ислам галәменә дин дәреслеге булып хезмәт итүче китапларын кулланыр дәрәҗәдә белемебезнең булмавы аркасында, кем ни әйтсә – шуңа ышанып, гап-гади дини йолалар, кагыйдәләр мәсьәләсендә ызгышып-талашып ятабыз. Югыйсә, безнең бабаларыбыз аларны белеп оныткан. Муса Бигинең 120дән артык китаплары, мәкаләләре була торып, дин өлкәсендә һаман надан кала киләбез.Аяныч!».

Иҗаты, хезмәтләре генә түгел, хәтта тормышы, биографиясе дә тулысынча өйрәнелмәгән әле Бигиевнең. Аның бертуган абыйсы, классик язучыбыз Мөхәммәтзаһир Ярулла улының 1870 елда Ростов-Дон шәһәрендә туганлыгы билгеле. Ә менә Мусаның туган елы төрле чыганакларда төрлечә (1873, 1874, 1875, 1879...) күрсәтелә. 1873 елның 6 гыйнварында туган дигән фикерне истәлекләрендә Мусаның кызы Фатыйма (әнисе истәлегенә шулай кушылгандыр) Таһирҗанова (ул – Ленинград университеты профессоры (1946), Шәрык белгече, заманында Муса Бигиевтән гарәп, фарсы, төрек телләре буенча дәресләр алган һәм остазы кызына өйләнгән Габдрахман Таһирҗановның (1907-1983) хатыны) телгә ала. Ләкин бу уңайдан Муса Бигиевнең үз истәлекләренә мөрәҗәгать итү дөресрәк булыр. Ул дусты, фикердәше, олуг мәгърифәтче, нәшир һәм язучы Фатих Гыйльман улы Кәримигә (1870-1937) юлланган хатында: *«... якынча 1875нең ноябрь-декабрь айларында Ново-Черкасск тирәләрендә юлда туганмын»*, – дип яза. Ул моны 1896 елда хәрби исәпкә куелган елыннан санап чыгара (21 яшь?). Әгәр Мусаның яшьтән үк акыллы, гыйлемгә тартылучан, укымышлы булып үсүен, 11 яшеннән Ростовтагы дәүләти реальный лицейда, аннан инде Казандагы Апанаевларның Күл буе (бу вакытта Заһир абыйсы да шушы мәдрәсәдә укыган була) һәм Мәрҗани мәдрәсәләрендә, Кырымдагы Бакчасарай, Оренбургтагы «Хөсәения»


ВСЕМІРНЫЙ ПОЧТОВЫЙ СОЮЗЪ. РОССІЯ.
UNION POSTALE UNIVERSELLE. RUSSIE.
ОТКРЫТОЕ ПИСЬМО.—CARTE POSTALE.
Для письма.
Для адреса.
Ростовъ н/Д.
Богатянскій 56
Бигъевой
„Изданіе Комитета по постройкѣ соборной мечети въ С.-Петербургѣ".
Т-во Р. Голике и А. Вильборгъ.

М.Бигиевнең хатыны Әсмага язган хаты.
Октябрь, 1906 ел

мәдрәсәләрендә гыйлем эстәвен, ниһаять, атаклы Бохара мәдрәсәсенә барып, анда җәдитчелек ысулы белән укытучы Икрам һәм Айваз дамеллалардан фикх вә фәлсәфә нигезләрен, Р.Декарт, Р.Бэкон трактатларын өйрәнүен, дамелла Миршәрифтән математика вә астрономия дәресләре алуын, яраткан укытучысы өчен хәтта Эвклид, Пифагор, Архимед мирасларын русчадан төрекчәгә тәрҗемә итүен истә тотсак, аңа үзенең туган елын исәпләп чыгаруы кыен булмагандыр, дип әйтәсе килә.

Бигиевләрнең әти-әнисе дә укымышлы була. Ярулла, мәсәлән, башлангыч дини белемне Пенза губернасының Кикин авылында имам Хәбибулла хәзрәт мәдрәсәсендә ала. Соңрак аның кызы Фатыймага өйләнә дә хәтта. Аннан Мәскәү-Ростов-Дон тимер юлында подрядчы булып эшли. Бервакыт Оренбург мөфтие Сәлимгәрәй хәзрәт, Хаҗ сәфәренә узып барышлый, Яруллаларда тукталa. Ике укымышлы яшь кешене күреп, бик куана мөфти һәм үзенең вәкаләтләре белән Ярулла Бигине Ростов шәһәренең ахуны итеп билгеләгән.

С.-Петербургтагы Җамигъ мәчете проекты

Шулай итеп, яшь ахун гаиләсендә ике малай туа.

Тик кыска гомерле була Бигиевләр. 1881 елда, кисәк кенә авырып, әле 45не дә тутырмаган гаилә башлыгы үлеп китә. Унбер яшьлек Заһир белән алты яшьлек Мусаны кочаклап, Фатыйма

Безнең мирас №2 февраль 2017

берьялгызы кала. Балаларын укымышлы, гыйлемле итү өчен, яшь хатын бөтен көчен куя. Улларына башлангыч дини белемне дә, дөньяви дәресләрне дә үзе бирә. 1886 елда Заһирны Казанга Күл буе мәдрәсәсенә (1891 елга кадәр укый) озата, ә 11 яшьлек Мусаны Ростовның реальный лицеена бирә. 1888 елда ике туган да Казанда бер үк мәдрәсәдә укыйлар. Заһирның мәдрәсә шәкерте булып йөргәндә ике роман язып бастыруын бөтен татар җәмәгатьчелеге сенсация буларак кабул итә! «Өлүф, яки гүзәл кыз Хәдичә» – 1887 елда – 17 яшь! «Гөнаһе Кәбаир» («Зур гөнаһлар» – 1890 елда – 20 яшь! Аяныч ки, Ярулла хәзрәтнең бу талантлы улы да дөньядан бик иртә китә – 32 яшендә әнисе янында Ростовта вафат була, әмма аңа кадәр тагын ике роман («Катыйлә» һәм «Мөртәд»), Урта Азия буйлап зур сәяхәтнамә (Уфа, 1908) язып калдырырга өлгерә. Тик ике детектив романның кульязмалары югала.

Мусага исә Ходай озын гомер бирә. Ул бакыйга 1949 елның 28 октябрендә Мисырның башкаласы Каһирәдә күчә. «Әл-Әхрам» газетасы шул елның 29 октябрендә чыккан санында галимгә Сәид Нәфис мәчетендә җеназа намазы укылуы һәм мәрхүмнең Хидвиядәге патшалар нәселе күмелгән Афифә зиратында җирләнүе турында хәбәр итә. Замандашлары белән чагыштырганда озак яшәгән кебек күренсә дә, Муса Бигиев шикелле шулкадәр фаҗигале язмышлы кешене тагын табып булырмы икән?! Тормышының һәр көне, һәр сәгате диярлек киеренке хезмәт, иҗат, юл газаплары белән үрелгән аның: бөтен Аурупа һәм Азия илләрен, дәүләтләрен аркылыгабуйга йөреп чыккан, мөселманнарның милли-азатлык хәрәкәтенә җитәкчелек иткән һәм аның идеологы, юлбашчысы булган өчен эзәрлекләнгән, төрмәләргә утыртылган, ниһаять, 1930 елда, Советлар илендә алты баласын һәм хатынын калдырып, яшерен рәвештә Финляндия аша ерак-еракларга качып киткән һәм үлгәнче гаиләсен сагынып, бер күрергә тилмереп яшәгән ул.

Алдарак язып үткәнебезчә, Муса яшьтән үк дини һәм дөньяви фәннәрнең барысын да тырышып өйрәнә. Бохарадан кайткач (1901), ул Петербург университетының юридик факультетына керергә ниятли. Ләкин анда латин телен белү сорала. Муса Истанбулга китәргә мәҗбүр була. Анда Инженерлык мәктәбенә укырга керә. Шунда үзенең адашы һәм якташы, 1892 елдан бирле хәрби училищеда рус теле һәм икътисад фәннәрен укыткан Муса Акъегет-Задә (1864-1923) белән очраша. Якташы Мусага Ислам нигезләрен тирәнтен өйрәнергә киңәш итә. Бу турыда Бигиев соңрак болай дип искә ала: *«Тәңребез үз куллары белән йөрәгем түренә дини фәннәр үзләштерүгә мәхәббәт орлыклары салганлыктан, дистә елга якын төрле дини мәдрәсәләрдә гомер уздыргач, олы хыяллар белән мөселман илләренә чыгып киттем...»* («Әл-Лөзүмиять», Казан, 1907). Аны Төркиядәге уку йортлары гына канәгатьләндерми: башта Мисырга бара, Милли китапханәдә Коръән-Кәрим тарихын өйрәнүгә күп вакытын багышлый. Каһирә белән бер чорда ук төзелгән (972 ел) атаклы Әл-Әзһәр университетында укырга да өлгерә, мәшһүр профессор, ислам дине белгече Мөхәммәт Абдо белән (1845-1905) таныша, аның лекцияләренә яратып йөри.

Ике ел буена күп гыйлем эстәгәч, Мисыр уку йортларындагы укыту тәртибе дә туйдыра, алҗыта башлый Мусаны. Ул күпчелек вакытын Милли китапханәдә үткәреп, фәннәрне үзлегеннән өйрәнә. Аннан Һиҗазга (Сөгуд Гарәбстаны) хаҗ сәфәре кыла, ике ел дәвамында изге Мәккә вә Мәдинә мәдрәсәләрендә танылган дин галимнәре дәресләренә йөри. Рус, татар һәм төрек телләрен яхшы белгән яшь галим гарәп һәм фарсы телләрен дә «су кебек эчәр» дәрәҗәгә җиткереп өйрәнә. Шул елларда исемнәре бөтен ислам дөньясына танылган дин белгечләре алдында Муса Коръән-хафизлыкка (Коръәнне яттан белүче) сынау тота.

Дәвамы бар ■

Ташъязмаларда – газиз тарихыбыз!

(Татар ташъязма истәлекләрен өйрәнү тәҗрибәбездән)

Раиф Мәрданов, Ирек Һадиев

Эпиграфик истәлекләрне (каберташ язмаларын) өйрәнү һәм аларның сакланышын тәэмин итү ихтыяҗы бернинди дә бәхәс тудырмый. Чөнки, беренчедән, эпиграфик истәлекләрнең фәнни кыйммәте бик зур, икенчедән, милли мирасыбызның бер өлеше булган әлеге ядкярләр елдан-ел кимеп, юкка чыгып бара, өченчедән, киң җәмәгатьчелектә дә аларга карата хөрмәт-ихтирам, сакчыл караш тәрбияләү, «зират культурасы»на өйрәтү зарурлыгы арта.

Ташъязмаларның тарихны өйрәнүдәге әһәмияте галимнәр тарафыннан күп мәртәбәләр расланган. Борынгы чорлардан башлап, XX гасыр башына кадәр кабер ташларында вафат булган шәхескә бәйле рәвештә милли тарихыбызның аерым бер фактлары, халыкның мәдәни һәм әхлакый үсеш дәрәҗәсе чагылыш тапкан. Ташъязмалар хәбәр иткән тарихи-документаль мәгълүматлар башка төрле чыганаклардан алынганнарына бик саллы өстәмә. Аерым очракларда, эпитафияләр үзләре үк күпкырлы мөстәкыйль чыганаклар рәтенә кертелергә лаек. Халкыбыз тарихын өйрәнүнең кайбер бәхәсле мәсьәләләрен хәл итүдә комплекслы эпиграфик тикшеренү эшләренең әһәмияте гаять зур.

Соңгы егерме ел дәвамында без махсус экспедицияләр оештырып, Татарстанның сигез районындагы элекке кабер ташларын комплекслы өйрәнү һәм теркәү эшләрен башкардык.

Борынгы Болгар, Алтын Урда дәверләре, Казан ханлыгы кебек чорлардан калган ташъязмалар гына түгел, ә соңгырак чорларга караган истәлекләрнең дә әһәмияте зур. Фәкать алардагы мәгълүматларны тирәнтен өйрәнергә һәм лаеклы дәрәҗәдә кадерле, саклый белергә кирәк. Моннан йөз яки ике йөз ел элеккеге ташларны, борынгы түгелләр икән, дип, битарафлык күрсәтү дәвам итсә, булганнары да уалып-ватылып юкка чыгып бетәчәк. Югыйсә, алар безнең газиз тарихыбыз! Әллә кайчангы борынгылыкны гына эзләп йөреп, якынрак тарихтагы кыйммәтле чыганакларны да кадерсезләсәк, Ходай да кичермәс, киләсе буыннар да гафу итмәсләр! Шуларны фәһемләп, без иң башта үзебезнең туган төбәкләребез Әгерҗе һәм Кукмара районнарындагы барлык мөселман татар зиратларын максатчан тикшереп чыктык, булган ташларның текстларын укып, күчереп алдык, фотога төшердек. Шулай ук Саба, Алабуга, Менделеев, Балтач, Мамадыш һәм Әтнә районнарының зиратлары тулаем өйрәнелде, Удмуртиянең Можга, Алнаш, Кече Пурга, Кияс һәм Киров өлкәсенең Малмыж, Нократ Аланы, Слободской районнарындагы татар авылларына эпиграфик экспедицияләр үткәрдек.

Мәгълүмат өчен әйтеп үтик: 1998 һәм 1999 елларда Кукмара районына оештырылган фәнни экспедицияләребез нәтиҗәсендә 58 татар авылындагы 284 гарәп язулы кабер ташын өйрәндек. Әгерҗе районындагы 2000 елгы экспедицияләребез дәвамында 48 торак пунктка нисбәтле 226 кабер ташы







Мондый китаплар тәэсире белән күпләр үз кан-кардәшләренең кабер ташларын зиратлардан табып, тирәсен чистартып, ташын төзәтебрәк куяр, ихлас-тан багышлап догасын кылыр.

исәпкә алынды һәм тикшерелде. Саба районында исә 1994, 2001, 2002, 2004 елларда 62 авылдагы зиратларда гарәп язулы 218 ташъязма, Балтач районының 47 авылында 1997-2008 еллар арасында 214 ташъязма, 2004-2005 елларда Алабуга районының 10 торак пунктында 407, Менделеев районының 13 торак пунктында 147 гарәп язулы ташъязма истәлек, 2012-2015 елларда Мамадыш районының 43 торак пунктында 342 ташъязма, 2015-2016 елларда Әтнә районының 49 авылында 1476 истәлекядкяр өйрәнелде. Аларның иң борынгылары Алтын Урда (Мамадыш һәм Саба районнарында) һәм Казан ханлыгы (Әтнә, Саба, Мамадыш, Балтач районнарында) дәверләренә карый. Шулай ук XVII һәм XVIII гасыр кабер ташлары да җентекләп өйрәнелде. Теркәлгән истәлекләрнең зур күпчелеге XIX гасыр белән XX гасырның башына нисбәтле.

Кукмара, Әгерҗе, Саба, Алабуга, Менделеев, Балтач, Мамадыш һәм Әтнә районнарында урнашкан 330 торак пункттагы 3314 эпитафик истәлек өйрәнелгән икән, бу инде зур нәтиҗә, һәрхәлдә, табигый таушалу сәбәбеннән дә, адәм баласы үзе уйлап чыгарган ясалма афәтләр һәм игътибарсызлык аркасында да елдан-ел юкка чыгып, мәңгелеккә бетә баруларын исәпкә алганда, бу бигрәк тә мөһим күрсәткеч. Югыйсә, 30-40 еллар элек кенә галимнәр күргән-өйрәнгән борынгы ташлардан кайберләренең хәзер әсәре дә юк.

Үзебез өйрәнгән һәр төбәктәге эпиграфик истәлекләрнең фоторәсемнәрен һәм текстларын биреп, аерым китапҗыентыклар итеп бастырып халыкка

җиткерү эшебезнең башында ук күздә тотылган төп максат иде. Кыенлыкларга карамастан (мөмкинлекләре булган район хакимиятләре дә бу изге гамәлнең чыгымнарын үз өсләренә алырга ашыкмый), әлеге максат тормышка ашып килә. «Татар эпиграфикасы» сериясеннән Әгерҗе, Кукмара, Мамадыш төбәкләренең ташъязма истәлекләренә багышланган китаплар 2008, 2014, 2015 елларда укучыларга барып иреште, тиздән Этнә районыныкы да дөнья күрәчәк.

Мондый китаплар тәэсире белән күпләр үз кан-кардәшләренең кабер ташларын зиратлардан табып, тирәсен чистартып, ташын төзәтебрәк куяр, ихластан багышлап догасын кылыр.

Әйдәгез, зиратларны, каберләрне чистартып, койма-чардуганнарын төзәтеп, аеруча кадерле ташъязмаларның өсләренә түбәләр ясап, сынган-аерылган кисәкләрен үзара беркетеп, ауган-кыйшайганнарын турайтып яки башка юллар белән бер, ике гасыр, хәтта биш йөз елга якын торган истәлекләрнең гомерен тагын күп елларга озайтыйк!

Туган-тумачасы булмаса да, тарихи ядкярләрнең кадер һәм кыйммәтләрен аңлап, киләсе буыннарга да уалмыйча-ватылмыйча ирешүен хәстәрләр. Һәрхәлдә, без шундый теләктә һәм өметтә булдык. Арабызда игелекле затлар бар бит, әүвәлге тарихи ташларны җил-давылдан, ватылудан саклауның менә дигән мисаллары да аз түгел!

Бу китаплардан үзләренең нәселдәшләрен, элеккеге әби-бабаларының исемнәрен, ташларының рәсемнәрен табып куанучылар булыр. Андый бәхетле бәндәләр белән без дә бергә сөенәбез, тырышып эшләгән хезмәтебез бушка китмәгәнлеген тоябыз. Уртак шатлыкларыбыз китапларда исемнәре искә алынган һәркемнең рухларына изге дога булып ирешсә иде.

Ташъязма истәлекләрне кичектермичә барлау, өйрәнү, мөмкинлек булганда, юкка чыгудан саклау – изге бурычларның берсе. Чөнки бу кабер ташларында бабаларыбызның газиз исемнәре уелган. Һәркемнең күңелендә иман, беренче нәүбәттә, ата-бабаларның изге рухларына ихтирамнан башлана. Һәммәбез халкыбызның, нәсел-нәсәпләребезнең, авылдаш һәм төбәктәшләребезнең исемнәрен һәм гамәлләрен белергә, өйрәнергә һәм күңелләрдә сакларга тиешбез.

Тарихыбызның кыйммәтле чыганакларына карата яшәп килгән мөнәсәбәткә мисал итеп Казан шәһәренең Яңа Бистә зиратын гына китерик. Җанны өшетерлек әхлаксызлык күренешләре аз түгел монда. Элек кабер булган урында яңадан кабер казу, аны югары бәягә сату үзе үк әхлаксызлыкның зур бер чагылышы лабаса. Борынгы кабер ташларын вату, сындыру, урыннарыннан алып ташлау, өсләренә чүп-чар өю кебек төрлечә мәсхәрәләүләр дә җитәрлек. Эшләр шулай барса, бу ташларга, кайчандыр шушы кабер ияләренә укыган кебек, җеназа укырга гына кала. Казан элек тә, хәзер дә бу өлкәдә үз өлешен кертеп килә – дистәләгән, йөзләгән ташлары булган татар зиратларының берсе – XVIII йөзгә караганы – инде күптән асфальт астында, Киров районындагы тагын берсе – Идел сулары белән юылып бетеп бара, шул ук райондагы икенчесе – элекке Пороховой бистәсенең хәзерге «Рамазан» мәчете янәшәсендәге зираты яңа төзелешләр белән һәрьяклап кысрыклана һәм бик начар хәлдә тотыла. Төбәк һәм авыллардагы әүвәлге кабер ташларының да сакланышы мактанырлык түгел.

Бер яки берничә дистә ел элек язулары укырлык хәлдә булып, төз басып торган кабер ташларының хәзерге көндә бөтенләй юкка чыгуын яисә сынып, ватылып ятуын күрү, таш өслегендәге язу-

Безнең мирас №2 февраль 2017

Яшел Үзән районының Мулла Иле авылы зиратындагы урта гасыр кабер ташын саклауның бер үрнәге

лар ашалу белән бергә тарихи хәтернең дә юкка чыга баруын аңлау, зират коймаларын җимерү һәм ташъязма истәлекләрне бозу очраклары турында ишетү-белү, ниһаять, ата-бабалар, туганнар, авылдашлар җирләнгән зираткаберлекләрнең бөтенләй каралмавы, чистартылмавы кебек әхлаксызлык күренешләренә елдан-ел ешрак шаһит булу йөрәкләрне сыкрата. Фәнни яктан караганда да, бәһасез мәгълүматлар тупланган бу төр тарихи чыганакларның һаман да игътибардан читтәрәк булуы бик кызганыч. Шуңа күрә, авылларда, шәһәрләрдә яшәүчеләргә, җирле хакимият вәкилләренә, дин әһелләренә, мәчетләргә йөрүчеләргә, мәктәп укучыларына мөрәҗәгать итәбез. Әйдәгез, зиратларны, каберләрне чистартып, коймачардуганнарын төзәтеп, аеруча кадерле ташъязмаларның өсләренә түбәләр ясап, сынган-аерылган кисәкләрен үзара беркетеп, ауган-кыйшайганнарын турайтып яки башка юллар белән бер, ике гасыр, хәтта биш йөз елга якын торган истәлекләрнең гомерен тагын күп елларга озайтыйк! Бу фани дөньяга килеп киткәннәр дә бездән разый булсын, киләчәк буыннар алдында да йөзебез ак, күңелебез чиста торсын!

«МАМАДЫШ ТӨБӘГЕНЕҢ ТАШЪЯЗМА ИСТӘЛЕКЛӘРЕ»

исемле китаптан өзек

1677 елда Байыш суфый улы Дусмөхәммәд каберенә куелган таш

Дусай авылы әчендәге аерым каберлектә XVII гасырга караган ике ташбилге янәшә тора. Икесенең дә көньяк тарафында гарәп хәрефләре белән уелган язулары сакланган.

Ташларның сул яктагысы 1677 елда Байыш суфый улы Дусмөхәммәд каберенә куелган. Тексттагы «Байыш суфый угылы Дусмөхәммәд хафиз» дигәнгә өстәмә аңлатма бирү тиеш дип саныйбыз. «Хафиз» сүзе ул чорда мулла мәгънәсендә кулланылган. Димәк, Дусмөхәммәд исемле кеше мулла булган. Ә аның әтисе Байышның «суфый» дигән титулы бу кешенең аеруча зур дини белемгә һәм дәрәҗәгә ия булганлыгын белдерә.

Дусмөхәммәднең исеме Дусай авылының атамасы булып киткән дияргә тулы нигез бар. Чөнки татарларда элекке дәверләрдә дә озын исемнәрне кыскартып әйтү гадәти күренеш булган.

Ташларның уң яктагы икенчесе Сабай остабикә улы Шәехмөхәммәд каберенә 1679 елда куелган. Сабай остабикә исеме, ихтимал, Сабагөл, Сафагөл, Сабига кебек әүвәлге татар хатын-кыз исемнәренең берсеннән кыскартылгандыр.

Әлеге ике ташның янәшә торуына карап, аларда исемнәре язылган Дусмөхәммәд белән Шәехмөхәммәд кардәш-туганнар булгандыр, дип, фаразлаган идек. Архив документларын тәфсилләп өйрәнү, дөрестән дә, моны раслады. Тагын да киңрәк эзләнүләр нәтиҗәсендә, Дусмөхәммәд Байыш улының нәсел дәвамчыларын ачыкладык, алар **Дусмөхәммәд** → **Мөхәммәд** (1656-1733) → **Габдулла** (1714 елда туган) → **Әсән** (1735 елда туган) → **Үсәен** (1764-1831) → **Габделлатыйф** (1803 елда туган) → **Гыйззәтулла** (1823 елда туган) → **Рәхмәтулла** (1863 елда туган) → **Миңнехан** (1890 елда туган) → **аның улы Нургали (1930-2001) – Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановның, аның бертуганнары Рифкать белән Рәиснең этиләре.** ■

Безнең мирас №2 февраль 2017

Җефет калага сәфәр

Солтан Шәмси

СӘЯХӘТНАМӘ

Узган ел без гаиләбез белән сентябрь аенда Кырымның Евпатория каласында ял итеп кайттык. Элегрәк мин Кырымда бер тапкыр булган идем инде. Монысы икенче баруым. Күп еллар элек, бу 1990 еллар башы иде, без Рабит Батулла, Тәуфикъ Әйди һәм мин Исмәгыйль Гаспралының олуг юбилее уңаеннан Симферопольдә (Акмәчет) үткәрелгән ике көнлек фәнни җыенга барган идек. Шулвакытта мин Кырымны беренче кат күрдем.

Конференциядән соң безне Бакчасарайга алып барып, ханнар сараен күрсәттеләр. Симферопольнең зур сараенда кырым татарларының милли концертын карарга да насыйп булды. Шулай ук кырымлы дуслар безне Исмәгыйль Гаспралы мөгаллимлек иткән атаклы «Зынҗырлы» мәдрәсәсенә дә алып барды. Тик бу тарихи уку йорты ташландык, күптән ремонт күрмәгән бер бина булып чыкты, ул вакытта анда психик авырулар хастаханәсе урнашкан иде. Моны күреп, күңелебез бик нык әрнеде. Бу кырым татарларына карата мөнәсәбәт турында сөйли иде. Шулай да илдә ирек җилләре исә башлаган еллар иде ул. Кырым татарлары да Симферопольдәге концертта шактый кыю чыгышлар ясады, үзләренең тарихи җырларын да башкарды. Бер җырның рефрен булып кабатланган куплеты истә калган:

Алдым балта,
Бардым Ялта...

Тел белгән кешегә җырда сүзнең нәрсә турында баруы бик тә аңлашылып тора...

Бу юлы гүзәл диңгез буеннан кире

Казанга кайтып китәргә берничә көн калганда, без туристлар автобусы белән Бакчасарайга барырга булдык. Кырымга килеп тә Бакчасарайны күрмичә кайтып китү дөрес булмас иде. Гаиләбездә, миннән гайре, анда берәүнең дә барганы юк, шуңа күрә минем аларга Кырым ханнары сараен бик күрсәтәсем килә иде. Өстәвенә, бу экскурсия вакытында Бакчасарайдан ике-өч чакрымлап җирдә урнашкан тарихи Чуфут калага бару да каралган. Ә минем бу тарихи ныгытма-каланы бик тә күрәсем килә иде. Интернеттан аның турындагы мәкалә һәм фотосурәтләр белән дә таныштым. Кырым ханнарының беренче башкаласы биредә урнашканлыгы да миңа мәгълүм. Шулай булса да, хәзерге көндә фәнни әдәбиятта «Чуфут-кале» дип йөртелгән бу тарихи каланы үз күзләрем белән күрәсем, борынгы ташларын кулларым белән капшап карыйсым, каланың борынгы мохитен җаным-рухым белән тоясым килә иде. Кыскасы, көннәрдән беркөнне без Бакчасарайга чыгып киттек. Оныгыбыз кечкенә булганга, кызым гына безнең белән бара алмады.

Бакчасарайны тасвирлау бу язмада минем максатыма керми. Шуңа күрә, форсаттан файдаланып, берничә фактка гына тукталып үтәм. Бүгенге көндәге Бакчасарай – заманнар узу белән шактый үзгәртеп корылган хан сарае ул. Аны 1532 елда Кырым тәхетенә яңа гына утырган Сәхибгәрәй хан төзетә башлый. Миңлегәрәй хан углы Сәхибгәрәй 1521-1524 елларда Казан тәхете белән идарә итә. Тик ул 1524 елда туганнан туган энесе Сафагәрәйне Казанга чакыртып ала да, аңа тәхетне тапшырып, үзе Кырымга кайтып китә. Шулай итеп, унөч яшьлек Сафагәрәй көтмәгәндә Казан ханы була. Тарихчы Михаил Худяков үзенең Казан ханлыгы тарихына багышланган мәшһүр хезмәтендә Сәхибгәрәй Казан тәхетен энесенә калдырып киткәннән соң, төрек солтаныннан ярдәм сорар өчен Истанбулга юнәлә, дип яза. Әмма дөреслектә Сәхибгәрәй хан Казан тәхетен Истанбулга китеп барыр өчен калдырмаган, ул Кырым тәхетендә утырган Сәгадәтгәрәй хан янына ярдәм сорар өчен кайткан, чөнки бу вакытта, Казан белән Мәскәү аралары бик нык бозылып, сугыш башланырга торган. Әмма Сәгадәтгәрәй хан Сәхибгәрәйнең Кырымга кайтуын бер дә яратмый, аңа ярдәм итәргә дә җыенмый, Мәскәү явыннан куркып кайткансың, дип, аның өстенә гаеп ташлый, аны кулга алдырып, Балаклава зинданына яптыра. Бәлки, тәхетне тагын бер дәгъвалаучы артты, дип уйлагандыр. Бу вакытта Кырымда сәяси вазгыять бик катлаулы була, тәхет өчен көрәш бик нык кызып китә. Әлеге көрәш 1524 елдан 1532 елга кадәр, Сәхибгәрәй Кырым тәхетенә чыкканчы дәвам итә. Сәхибгәрәй зинданда озак утырмый, тиздән чыгарыла, агасы Сәгадәтгәрәй ханга үч сакламыйча, көрәш барышында гел аның ягында була. Шул сәбәпле, аңа үлем куркынычы яный һәм ул 1532 елда Истанбулга китәргә мәҗбүр була. Кырым аксөякләре белән уртак тел таба алмаган Сәгадәтгәрәй ханга да ахыр чиктә тәхеттән баш тартырга, шулай ук Истанбулга барып сыенырга туры килә. Бушап калган Кырым тәхетенә солтан Сөләйман Кануни Сәхибгәрәйне тәкъдим итә. Шул ук 1532 елда Сәхибгәрәй Кырым тәхетенә утыра. Күрәсең, хезмәтен язганда М.Худяков кулында Сәхибгәрәй хан турында тулы мәгълүмат булмаган.

Бакчасарай тарихына әйләнеп кайтыйк. Бакчасарай – Кырым ханлыгының өченче башкаласы. Ул барлыкка килгәнче Хаҗигәрәй белән Миңлегәрәй ханнар Кырык Ор исемен йөрткән Җефет калада торып идарә иткәннәр. Тәхеткә дәгъва кылучылар күп булганга, Кырым ханлыгының беренче ханнары, дошманнардан саклану өчен булса кирәк, Кырык Ор каласында урнашалар. Әмма тау өстендәге ныгытма-кала яшәү өчен уңайсыз була. Шуңа күрә Миңлегәрәй хан Җефет каладан бераз астарак Салачик дип аталган башкала төзетә башлый. Бераздан үзе дә шунда күчә. Салачик үзенең башкала статусын 1532 елга кадәр саклап килә. Нәкъ шушы елда яңа

тәхеткә утырган Сәхибгәрәй хан үзәннең киңрәк җирендә Бакчасарай дип аталган сарай төзетергә керешә. Бакчасарай Салачиктан ике чакрым ераклыкта торып кала. Киләчәктә ул Бакчасарайның бистәсенә әйләнә. Тора-бара Бакчасарай тирәсендә шәһәр барлыкка килә.

Кырым ханлыгы белән Русия арасындагы сугыш вакытында, 1736 елда, Бакчасарай рус гаскәрләре тарафыннан басып алына. Ул чакта гаскәр башында фельдмаршал Кристов Миних торган. Ул башкаланы да, ханнар сараен да яндырырга әмер бирә. Янгын Бакчасарайның шактый өлешен юк итә. Шуннан соң ханнар сарае яңабаштан үзгәртеп корыла. Сарайны торгызу эшләре Сәламәтгәрәй белән Кырымгәрәй ханнар заманында башкарыла.

Русия армиясенең бу явы бик зур югалтулар белән төгәлләнә. Ул хакта югары уку йортлары өчен чыгарылган тарих дәреслегендә дә берничә юл китерелә: *«В кампании 1736 г. русские перешли Перекоп, заняли столицу ханства Бахчисарай, но не уничтожили крымских войск. Командовавший войсками Миних боялся оказаться запертым на полуострове возвращавшимися из иранских провинций татарами и поспешно отступил из Крыма. За время этого похода армия только от болезней потеряла около половины своего состава»*. (История СССР. С древнейших времен до 1861 года. М., «Просвещение». 1983. – С.366.)

Бакчасарайга күпмедер үзгәреш керткән тагын бер-ике вакыйганы искә төшереп үтик. 1787 елда Екатерина II Бакчасарайга килә. Императрицаның килүенә багышлап, ханнар сараен төзекләндерү эшләре алып барыла. Сарайдагы бер бүлмәне кабул итү бүлмәсе итеп үзгәртеп коралар, ә икенчесе патшабикәнең йокы бүлмәсе итеп үзгәртелә. Моның өчен дивар тишелә, яңа тәрәзәләр куела, түшәм алтын буяу белән буяла, шулай ук киң ятак – альков урнаштырыла. Патшабикә Бакчасарайда бары өч көн генә була. Өч көн куну өчен күпме үзгәреш кертелә.

1818 елда Александр I шулай ук Бакчасарайны күрергә килә. Бу вакыйгага әзерлек вакытында искергән хәрам бинасы сүтеп ташлана, өч бүлмәле флигель генә утырып кала.

1822 елда И.Колодин дигән адәм җитәкчелегендә ханнар сараенда ремонт эшләре алып барыла. Дорофеев дигән унтер-офицер сарайны бизәү белән шөгыльләнә. Ул диварларның тышкы ягына үз белдеге белән геометрик бизәкләр, төрле букет һәм чәчәк сурәтләре төшерә. Кайчандыр Омәр атлы рәссам тарафыннан бизәлгән диварны буяу белән каплый. Шушы ремонт эшләреннән соң, Бакчасарайның әүвәлге йөзе шактый үзгәрә. Моның белән генә чикләнмичә, И.Колодин кушуы буенча Кышкы сарай, мунча комплексы, тагын берничә корылма бөтенләй сүтеп ташлана. Шулай итеп, кырым татарларының кыйммәтле архитектура ядкяре төрле тыкшынулар аркасында шактый үзгәреш кичерә. Ярый әле, 1961-1964 елларда алып барылган фәнни реставрация вакытында Бакчасарайның әүвәлге йөзен күпмедер дәрәҗәдә элекке хәленә кайтарырга тырышалар.

Бакчасарай комплексы шундый үзгәртүләр аркасында зур зыян күрүенә карамастан, бүгенге көндә дә үзенең матурлыгы, мәһабәт корылмалары белән тамашачыда соклану, кырым татарлары мирасына карата хөрмәт хисләре уята. Шуңа күрә дә, Кырымга ял итәргә килгән бик күп кеше бу гүзәл сарайны тамаша кылырга омтыла. Бакчасарай Казанда да, Кырымда да тәхет биләгән Сәхибгәрәй хан тарафыннан җәннәт бакчасы мисалында төзелә һәм бүгенге көндә дә үзенең гүзәллеге, гармониягә ия күренеше белән тамашачыда гаҗәпләнү хисләре уята. Бу сарай кырым татарларының бөек тарихы, мөстәкыйль дәүләте булуын искә төшереп тора.

Без, Бакчасарайны тамаша кылганнан соң, «Ашлама» кафесына юнәлдек, анда кырым татарларының милли ризыгы чебурек (бәлки, чәбөректер?) белән

сыйланып чыктык. Ул безгә бик ошады, эченә ит тутырылган камыр ризыгы икән. Аннан соң экскурсоводыбыз безне Җефет калага алып менеп китте. Тауны кисеп салынган шактый текә асфальт юлдан төркемебез белән өскә күтәрелә башладык. Җефет кала тау өстендә Бакчасарайдан 2,5 чакрым ераклыкта урнашкан икән. Уң ягыбызда – агачлар белән капланган текә тау, сул якта – гаять тирән, меңгән саен тарая барган үзән. Үзәннең ике ягында, мәһабәт диварлар сыман, биек кыялар басып тора. Биек һәм текә! Гүя алар күк гөмбәзенә асып куелганнар! Як-ягыбызга карангалап, юлны дәвам итәбез. Юл кырыена тезелешкән сувенир сатучылар безне үзләренә чакыра, тик экскурсовод ханым безне алга әйди, тукталып торырга ирек бирми. Берзаман аста, тар үзән төбендә шактый зур чиркәү, кыя киртләчләренә карлыгач оялары сыман ябышкан төрле корылмалар күренде. Барысы да агартылган, төзек. Бу Свято-Успенский монастырь корылмалары булып чыкты. Ирләр монастыре икән. Нигә аны мондый уңайсыз урынга салдылар икән, дип уйлап алдым. Үзән төбеннән су акканы да күренми, хуҗалык эшләре алып бару өчен дә җайлы җир түгел. Монастырь биек кыялар арасына кысылган. Алып баручы ханым безне туктатты да тәмләп аның тарихы турында сөйләргә кереште. Монастырьның кайчан салынганы төгәл билгеле түгел икән. Кайбер мәгълүматларга караганда, аны VIII-IX гасырларда Византиядән качып килгән греклар салган булса кирәк. Бу вакытта анда иконаларны юк итү (иконоборчество) хәрәкәте җәелеп киткән. Ул зур көрәшкә әверелгән. Ә инде XV гасыр ахырыннан монастырь Кырымдагы православие чиркәве үзәгенә әйләнгән. Кырым ханлыгы башкаласы Бакчасарай янында урнашуына карамастан, ул Кырым мөселманнарыннан зыян күрмәгән. 1921 елда монастырь большевиклар тарафыннан ябылган, бар нәрсәсе конфискацияләнгән. 1993 елда биредә кабат ирләр монастыре эшли башлаган.

Экскурсовод ханымның сөйләвеннән мин ике нәтиҗә ясадым. Беренчесе – качып килгән грекларның нигә мондый уңайсыз җиргә урнашуына кагыла.

Тау куышы

Безнең мирас №2 февраль 2017

Күрәсең, килмешәк грекларга уңайлы җирдән беркем дә урын бирмәгән, шул сәбәпле, алар кыялар арасына килеп кысылырга мәҗбүр булгандыр. Икенчесе – Кырым мөселманнарының монастырьга зыян салмавын Алтын Урда дәүләтендә диннәргә карата толерантлык көчле булуы белән аңлатырга мөмкиндер. Ә Кырым ханлыгы әүвәл Алтын Урданың бер олысы булган. Соңрак кына ул мөстәкыйль ханлык булып яши башлаган.

Текә юлдан менүебезне дәвам иттек. Менә берзаман сул яктагы кыя өстендә Җефет кала күренде. Ныгытма-калада түбәләре кызыл чирәп белән ябылган берничә бина да сакланган икән. Кала урнашкан кыя итәгендәрәк кара авызларын ачкан берничә тау куышы да күренә. Бу урында тирән тарлавыкны хәтерләткән үзән саекты, киңәеп китте. Аның аркылы Җефет калага таш юл сузылган. Без төркемебез белән үзәнне аркылы чыктык та гасырлар узу белән шактый тузган, төзеклеген югалткан юлдан өскә күтәрелергә керештек. Кыенлыклар менә шунда башланды. Кала капкасына алып менгән юл бик текә булганга, әле сулга, әле уңга боргалана, югарыга бары шулай гына күтәрелү мөмкин иде. Экскурсовод ханым безне борылыш саен туктата да бераз ял иттерә, кала турында сөйли. Ул диңгез өстеннән 500 метр югарылыкта тора икән. Аның кайчан төзелүе ачыкланмаган. X гасырдан биредә яһүд динен кабул иткән хәзәрләр яши башлаган, имеш. Алар соңрак караим халкы булып киткән. Бу мәсьәләгә без алда әле тукталырбыз. Язма чыганакларда Җефет кала 1299 елда Кырык Ор исеме белән теркәлгән, ягъни Кырык ныгытма исемен йөрткән. Шул ук елда Алтын Урда дәүләтендә төмәнбашы булган Нугай мирза каланы басып алган, талап киткән. Соңрак, Кырым ханлыгы барлыкка килгәч, кала ханлыкның башкаласына әверелә. Беренче ханнарның сарае шушында урнаша.

Җефет кала Кырым ярымутравындагы иң яхшы сакланган мәгарәле ныгытма-кала икән. Ниһаять, без шушы каланың капка төбенә менеп җиттек. Бу капка Кече капу – Кече капка дип атала. Капка чыннан да әллә ни зур түгел, ул дошман үтә алмаслык биек диварда уелган. Таррак коридордан эчкә үтәбез. Ары табан юл ясалма мәгарәләр янынан уза. Аларның кайсы кечерәк, кайсы зур. Мин берсенең эченә үк кереп карадым, мәгарә шактый зур бүлмәне хәтерләтә, түшәменә баш тиярлек түгел. Нинди максат белән ясалуы билгесез. Бәлки, берәр нәрсә саклау өчен ясалганнардыр. Андый мәгарәләр Кече капуның тышкы ягында да бар. Алары капка сакчылары өчен ышык урын булып хезмәт иткән булса кирәк. Кырымда җәйләр бик эссе була, яндыргыч кояш астында сакта тору мөмкин түгел.

Җефет кала тигез тау өстендә урнашкан. Борынгы заманда анда торак йортлар күп булган. Хәзерге көндә берничә бина гына күренә. Бераздан без караимнәрнең ике гыйбадәт кылу бинасы – кенасалар янына килеп туктадык. Аларның зурысы XIV гасырда ук төзелгән икән. Кечесе XVIII гасырда гына барлыкка килгән. Шунысы кызык, караимнәр яһүд динендә булсалар да, гыйбадәтханәләрен синагога дип түгел, кенаса дип атыйлар. Зурысында дини бәйрәм көннәрендә гыйбадәт кылынган, кечесе көндәлек гыйбадәтләр, җыелышлар үткәрү өчен файдаланылган. Алар бүгенге көндә дә төзек, караимнәр җәмәгате аларны карап-кайгыртып тора икән. Бераз алга киткәч, сакланып калган зур бина нигезенә килеп чыктык. Бу XIV гасырда салынган мәчет нигезе булып чыкты. Димәк, Җефет калада Кырым ханлыгы барлыкка килгәнче үк, Алтын Урда дәүләте чорында, яһүд динендәге төрки караимнәр генә түгел, мөселманнар да яшәгән. Мәчет каршындарак, юлның икенче ягында без таш кыяда уелган кое авызы һәм аның янында су җыю өчен ясалган дүртпочмаклы таш әрҗә-тагарак күрдек. Аның мәчет янында булуы табигый тоелды. Мөселманнар гыйбадәт кылу ал-

Җаникә ханым төрбәсе

дыннан госелләнү өчен суны шуннан алганнар булса кирәк. Бәлки биредә атлар да сугарганнардыр. Гомумән, Җефет калада, тау өсте булганга, су мәсьәләсе кискен торганга охшый... Без биредә яңгыр сулары җыю өчен ясалган шактый зур бассейн да күрдек, бассейнга төшү өчен ясалган таш баскычлар әле дә исән. Элегрәк биредә коелар да булган, тик XVII йөздә коелар кипкән, суны астан, үзәннән ташырга туры килгән. Мин шушы җөмләне язып куйдым да уйга калдым. Су мәсьәләсендә ялгышмыйм микән? Без бит «Ашлама» кафесы артындагы биек кыядан шактый мул сулы шарлавык агып ятканын күреп калган идек. Аңа сокланып карап та тордык. Димәк, тау өстендә су булган. Шарлавыкның бүгенге көндә дә агып ятуы шул хакта сөйли түгелме?

Аннан без яхшы сакланган, төзек, матур бер төрбә янына килеп чыктык. Сәлҗук архитектурасының гүзәл үрнәге булган бу төрбә Туктамыш хан кызы Җаникә ханымныкы булып чыкты. Ул биредә яшәгән, кала белән идарә иткән икән. Ул шушында вафат та булган. Аның турында риваятьләр дә сакланып калган. Җаникә ханым гүр иясе булганнан соң Хаҗигәрәй хан Кырык Ор каласына килеп төпләнә, каланы яңа барлыкка килгән Кырым ханлыгының беренче башкаласы дип игълан итә. Аның резиденциясе шушында урнаша. Биредә акча сугу сарае, әсир төшкән аксөяк әсирләрне тоту өчен төрмә дә салына.

Мин тау өстендәге Җефет каланы тамаша кылып йөргәндә монда элек барган тормышны күз алдына китерергә тырышып карадым. Кырым ханлыгы Алтын Урда дәүләтеннән аерылып чыккач, биредә Хаҗигәрәй, Миңлегәрәй һәм башка ханнар идарә иткән. Тик ул ханнар яшәгән сарайның кайда урнашуын да, нигез ташларын да экскурсовод ханым безгә күрсәтмәде. Гомумән, ул хакта сүз дә чыкмады, гүя Кырым ханлыгы тарихы Бакчасарайны төзегәч кенә башланып киткән. Кырым ханлыгының әүвәлге чорын сөйли башласаң, Алтын Урданы телгә алмыйча булмый. Алтын Урданы телгә алдыңмы, аның бөек татар мәмләкәте икәнен дә әйтергә туры килә...

Ахыры бар ■

МИЛЛӘТ ХӘБӘРЛӘРЕ

Фотолар һәм видео **beznenmiras.ru** сайтында

● Татарстан китап нәшриятында күренекле язучы һәм галим Адлер Тимергалин (1931-2013) төзегән «Миллият сүзлеге»нең беренче томы басылып чыкты. Сүзлекнең аерым өлешләре «Безнең мирас» журналында 2014 елның 3 нче санынннан алып дөнья күрә килә.

● 11 гыйнварда Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте идарәсендә быел беренче пленум утырышы булып узды. Утырышта мөфти Камил Сәмигуллин тәкъдиме белән «2017 ел - Галимҗан Баруди елы» дип игълан ителде.

● 17 гыйнварда «Болгар цивилизациясе музее»нда «Борынгы Болгар шәһәре» дип исемләнгән күргәзмә ачылды. Әлеге күргәзмәдә Р.Заһидуллинның «Яңа җирләрдә», «Капка сакчылары», «Изге хәбәр», «Ауда»; Ф.Халиковның «Яз», «Болгар төзелеше өчен таш чыгару», «Болгардагы Ага Базар»; Б.Гильвановның «Лачын»; Л.Нигъмәтҗанованың «Ак палаталар» дигән эшләре куелган.

● 18 гыйнварда «ТАТМЕДИА» бинасының (Декабристлар урамы, 2 нче йорт) брифинг-залында Татарстанның беренче Президенты М.Ш.Шәймиевкә багышланган «Илбашы» китабын (авторы - Рабит Батулла) тәкъдим итү булды.

● 19 гыйнварда Казанның Галактионов урамындагы 3а йортына мемориаль такта куелды. 1961-1973 елларда әлеге йортта фронтовик язучы, заманында укучылар арасында киң танылу алган «Яшәү белән үлем арасында» (1958) һәм «Җимерелгән бастион» (1965) дигән әсәрләр авторы Нәби Дәүли (Нәбиулла Хәсән улы Дәүләтшин,1910-1989) яшәгән.

● 19 гыйнварда Татар дәүләт «Әкият» курчак театрында күренекле шагыйрь Зөлфәтнең (Дөлфәт Госман улы Маликов, 1947-2007) тууына 70 ел тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә булып узды.

● 19 гыйнварда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының кече залында яшь иҗатчыларның «Калеб. Яңа дулкын» спектакле тәкъдим ителде. Тукай варисларының әлеге тамашада яңгыраган тәүге шигырьләре күпләрнең күңеленә хуш килде.

● Гыйнварда киң җәмәгатьчелек Татарстанның беренче Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиевнең 80 яшьлек юбилеен зурлап билгеләп үтте.

● «Казан-Казань» нәшриятында танылган шагыйрь Равил Бохараевның (1951-2012) «Тень Тамерлана: Булгарская поэма» һәм «Пьесы-сказки» исемле китаплары дөнья күрде. Әлеге ике китапның рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире – «Безнең мирас» журналының дизайнеры Диләрә Нәүрүзова.



Безнең мирас №2 февраль 2017

ШӘЙХЕЛИСЛАМ

Хатыйп Миңнегулов

Узган гасырның икенче яртысында Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыган студентларга, анда эшләгән укытучыларга уртача буйлы, юантыграк гәүдәле, зәңгәр күзле, игелекле карашлы бу зат бик тә яхшы таныш. Ул, ничектер, үзенең хезмәтләре белән генә түгел, ә шәхесе, сөйкемле сөяге, ихласлылыгы, самимилеге белән дә безнең күңелләргә сеңеп калган. Студентлар яраткан, үз иткән «Шәйхи абый»ның да фани дөньядан китүенә инде егерме елдан артык вакыт узган (21.03.1996). Әмма әле ул һаман да арабызда кебек: Тинчурин театры тирәсендәге йортыннан чыгып, Ленин бакчасына төшеп, оялчан гына елмаеп университетка килеп керер төсле.

Шәйхелислам Садретдинов шәхсән минем өчен аеруча якын, үз. Без инде аның белән студент елларында ук таныш идек. Татар әдәбияты кафедрасында бер үк вакытта эшли башладык, 30 елга якын хезмәттәшлек кылдык, аралаштык, берничә монографияне, дәреслекне бергәләп чыгардык. Аның хезмәтләре, гыйльми китаплары турында язганым һәм берничә мәртәбә радио-телевидение аша, конференция-җыелышларда сөйләгәнем дә бар. Ш.Садретдинов турында хезмәттәшебез М.Бакировның «Казан университеты галимнәре» сериясендә чыккан матур гына китапчыгы да бар (КДУ нәшр., 2003. – 17 б.). Анда галим язган күпчелек мәкаләхезмәтләрнең исемлеге дә бирелгән. Ш.Садретдиновның тууына 60 ел тулу уңае белән профессор Ф.Сафиуллина да «Мәгърифәт» гәҗите битләрендә (5 декабрь, 1996 ел) үз сабакташы хакында бик тә җылы эчтәлекле мәкалә язып чыккан иде. Анда галимнең шәхесе, эшчәнлеге турында бик кызыклы фикерләр, мәгълүматлар бар.

Мин соңгы дәвернең галим-әдипләре хакында язганда еш кына архив материалларыннан файдаланам. Бу юлы да Ш.Садретдиновның, гәрчә аның тәрҗемәи хәлен, эшчәнлеген яхшы гына белсәм дә, Казан федераль университеты архивында саклануча «Шәхси эше»нә («Личное дело»сына. – Опись 21, № 603, св. 30) мөрәҗәгать иттем. Анда галимнең биографиясенә, эшчәнлегенә, шулай ук университет тормышына, фәнгә, кафедра укытучыларына (шул исәптән без фәкыйрегезгә дә) мөнәсәбәтле кызыклы гына факт-мәгълүматлар бар. Хәзер хезмәттәшебезнең тәрҗемәи хәлен, гыйльми-педагогик эшчәнлеген кыскача гына бәян итәрмен.

Шәйхелислам Аләветдин (Галәветдин) углы Садретдиновның тормыш юлы XX йөзнең урталарында һәм икенче яртысында яшәгән күпләгән татар әдип-галимнәренең, журналистларының биографияләренә охшаш. Ул 1936 елның 5 декабрендә Чүпрәле районының Татар Бизднәсе авылында колхозчы гаиләсендә туа. Әтисе — Бөек Ватан сугышы инвалиды, 1958 елда вафат була.

Хатыйп Миңнегулов (сулда) һәм Шәйхи Садретдинов

Әнисе — Фатыйха Әхмәдулла кызы бер елдан соң, ягъни 1959 елда балаларын тәмам ятим калдырып, якты дөньядан китеп бара. Кечкенә Шәйхелислам 1944-1951 елларда туган авылындагы 7 еллык мәктәптә белем ала; 1951-1954 елларда — Чүпрәле урта мәктәбе укучысы. Берничә параллель сыйныфлы бу зур уку йортында ул сабакташы Нурмөхәммәт Хисамов кебек шактый билгеле була: тырыш, бик яхшы укый, рәсемнәр ясый, гармунда да уйнап җибәрә, матур-матур шигырьләр дә яза.

Урта мәктәне тәмамлап, бер ел туган колхозында («Победа») эшләгәннән соң, Шәйхелислам 1955 елда һич икеләнүсез, күп имтиханнар биреп, зур конкурсларны узып, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Бу — шәхес культы фаш ителеп, илдә аерым үзгәрешләр башланган чор. Милли яшәештә дә билгеле бер кузгалыш, хәрәкәт күзәтелә. Мондый атмосфера студентлар тормышына да сизелерлек йогынты ясый: тел-әдәбият, тарих, милли мәгариф белән кызыксыну арта, энтузиазм көчәя. Шәйхелислам укый торган төркем шаулы студент тормышы белән яши: укудан тыш, төрле кичәләр, конференция-семинарлар уздырыла, язучылар, күренекле кешеләр белән очрашулар оештырыла; һәр студент диярлек шигырь, хикәя, мәкалә, рецензия яза; хәтта Казахстан якларында чирәм җирләрдә дә эшләп кайталар. Чүпрәле егете дә боларның үзәгендә кайный. Аның илһамлана-илһамлана сәхнәдән шигырьләр укуын әле мин дә хәтерлим. Шунысын да искәртик: Шәйхелисламның күп кенә сабакташлары (төркемдәшләре) бераздан татар дөньясының билгеле шәхесләре булып китте. Болар арасында Флера Сафиуллина, Фәһимә Нигъмәтуллина (Хисамова), Нурмөхәммәт Хисамов, Казбек Гыйззәтов кебек фән докторлары, Әхмәт Рәшитов, Әгъзәм Фәйзрахманов, Рәшит Зәкиев, Мөнир Абдуллин кебек билгеле шагыйрь, журналистлар бар.

Әдәби иҗат, журналистика белән мавыккан, кызыл дипломлы Ш.Садретдиновны 1960 елда «Байрак» дип исемләнгән Баулы район гәҗитенә эшкә җибәрәләр. Биредә ул әдәби хезмәткәр,

хатлар бүлеге мөдире вазифаларын башкара. Ике елдан соң, «Байрак» ябылу аркасында, аны Бөгелмәдәге «Хезмәткә дан» («Слава труду») гәҗитенә бүлек мөдире итеп күчерәләр. Редакциядә эшләү елларында Ш.Садретдинов күпләгән мәкалә-очерклар яза, әдәбитәнкыйди эшчәнлеген дә дәвам иттерә. «Байрак»та эшләү вакытында булса кирәк, ул Люция исемле Баулы чибәре белән гаилә корып та җибәрә. Алар бербирсен яратышып, матур гына яшәделәр, ике кыз үстерделәр.

1963 елның көзендә университетның татар әдәбияты кафедрасы мөдире Хатип Госман чакыруы белән Шәйхелислам аспирантурага керә, күренекле шагыйрь С.Рәмиев иҗатын өйрәнә. Аспирантураны 1966 елда тәмамлагач, «Чаян» журналында бер ел тирәсе эшләп ала. 1967 елның ноябреннән башлап гомеренең ахырына кадәр ул — университетның татар әдәбияты кафедрасы мөгаллиме: әүвәл — ассистент, аннан — өлкән укытучы, 1978 елдан — доцент. Запастагы офицер. 1969 елдан КПСС члены.

1972 елның 27 апрелендә Казан университетында «Сәгыйть Рәмиев иҗаты» темасына диссертация яклап (гыйльми җитәкчесе — Х. Госман, рәсми оппонентлары — М.Гайнуллин һәм Й.Нигъмәтуллина), филология фәннәре кандидаты дәрәҗәсен алуга ирешә.

Ш.Садретдинов университетта эшләү чорында төрле гомуми һәм махсус курслар укытты: «XIX йөз татар әдәбияты», «XX йөз башы татар әдәбияты», «Татар әдәбиятында жанрлар формалашу», «С.Рәмиев һәм татар әдәбиятында романтизм», «Әдәби әсәрләрнең тел-стиле», «Драма теориясе» һ.б. Ф.Сафиуллина әйтмешли, ул, нинди курсны бирсәләр, шуны укытырга әзер иде.

Укыту планы нигезендә татар теле һәм әдәбияты бүлеге студентлары беренче курстан соң фольклор, икенче курсны бетергәч диалектологик практика узалар иде. Ике атналык бу чара экспедиция рәвешендә Татарстанда гына түгел, илебезнең милләттәшләр яши торган күп төбәкләрендә — Башкортостан, Чувашстан, Пермь, Оренбург, Төмән, Чиләбе, Сарытау, Ульяновск, Түбән Новгород, Киров һәм кайбер башка республикаларында һәм өлкәләрендә үтә иде. Болар белән безнең күпчелек укытучылар, шул исәптән Ш. Садретдинов та җитәкчелек итте. Аның авыл-бистәләрдә студентлар белән бергә концерт-кичәләрдә катнашуы да истә калган. Мондый экспедицияләр вакытында күпләгән фольклор материаллары, кулъязмалар туплана иде. Бераздан алар, шул исәптән Ш.Садретдинов төркеме тапкан материаллар да гыйльми, мәдәни бәйләнешкә кереп китте. Галимебез Казан пединститутты, Мәскәүдәге М.Горький исемендәге Әдәбият институты студентларына да бераз вакыт татар әдәбиятыннан лекцияләр укыды (Мәгълүм ки, 1972-1978 елларда бу Институтта татар әдәбиятыннан дистәгә якын тәрҗемәче әзерләнде. Анда Солтан Шәмси, Роза Баубекова (Кожевникова),Фирдәвес Әһлиуллина, Зәйтүнә Исхакова һәм кайбер башка каләм әһелләре белем алды. Күренекле тәрҗемәче Галия Хантимерова җитәкләгән әлеге төркемдә Марсель Бакиров белән без фәкыйрегез дә, Мәскәү университетында стажировка узу вакытында, берничә ай лекцияләр укыдык).

Соңгы дәвер татар әдипләренең күпчелеге Казан университетында белем алган. Аларны иҗади яктан әзерләүдә һәм үстерүдә Ш.Садретдиновның да роле зур. Ул башлап язучыларның үзенә күрә бер мәктәбе, иҗади мәйданы булган «Әллүки» түгәрәгендә дә актив эшләде, шул исемдәге стена гәҗитенең редакторы да булды. Ничектер, Ш.Садретдиновка студентлар нык тартыла иде. Алар остазларының фатирына да еш килеп торды. Люция ханым да килгән кешеләргә һәрчак ачык йөзле булды. Гомумән, хезмәттәшебез үзенең бөтен табигате белән ярдәмчел, кешеләргә игътибарлы зат иде.

Ш.Садретдинов, югары дәрәҗәле



Ш.Садретдиновның С.Рәмиев иҗатына багышланган хезмәте

(квалификацияле) белгечләр, әдип-галимнәр әзерләү, әдәби иҗат белән тыгыз бәйләнештә, әдәбият белеме, тәнкыйть өлкәсендә дә уңышлы гына эшләде. Ул фәнгә үзенең Сәгыйть Рәмиев турындагы саллы тикшеренүләре белән килеп керде. Егерменче йөз башларында бик тә популяр булган бу шагыйрь совет чорында, ничектер, игътибардан бераз читтәрәк калды, тиешенчә өйрәнелмәде һәм басылмады да. Ш.Садретдинов, объектив заруриятне тирән тоеп һәм остазы Хатип ага Госман киңәшләрен искә алып, яшьләргә хас мавыгу, дәрт белән С.Рәмиев иҗатын бик ныклап өйрәнде. Хезмәттә аеруча С.Рәмиевнең романтизм белән нинди мөнәсәбәттә торуы кызыклы тикшерелә. Ш.Садретдиновның диссертация яклавы гыйльми-мәдәни тормышта бер мөһим вакыйга рәвешендә узды. Хәтта кайберәүләр бу хезмәтне докторлык дәрәҗәсендәге тикшеренү дип тә бәяләде. Галимнең бу диссертациясе, бераз кыскартылып, 1973 елда Казан университеты нәшриятында аерым китап рәвешендә дә басылып чыкты (Сәгыйть Рәмиев иҗаты. — 162 б.).

Ш.Садретдинов С.Рәмиев иҗатын өйрәнүне гомере буе дәвам итте, дистәләгән мәкалә бастырды, докладчыгышлар ясады. «Татар әдәбияты тарихы»ның алты томлык академик басмасына (III том) шагыйрь хакындагы бүлекчәне дә ул язды. 1980 елда «Сәгыйть Рәмиев. Таң вакыты» дигән китап дөнья күрде (Казан. — 270 б.). Ш.Садретдинов тарафыннан тупланган, әзерләнгән бу җыентыкка әдипнең шигырьләре, проза һәм сәхнә әсәрләре, тәрҗемәләре, публицистикасы кертелгән. Бай эчтәлекле кереш мәкалә, шәрех-аңлатмалар да бар. Ахырда С.Рәмиев әсәрләренең, аның турындагы язмаларның библиографиясе дә урнаштырылган (259-299 битләр). 1980 елгы бу китап хәзергәчә шагыйрь әсәрләренең чагыштырмача тулы һәм ышанычлы җыентыгы хисаплана.

Ш.Садретдинов шактый еллар буе XIX йөз әдәбиятын укытты. Шуңа нисбәтән ул фәнни тикшеренүләр дә алып барды. Аеруча аны XIX йөз шагыйре Әбелмәних Каргалый һәм педагог, мәгърифәтче Мартемьян Иванов эшчәнлекләре кызыксындырды. Галим бу ике затның язма мирасын комплекслы өйрәнде. Әлеге эзләнү-тикшеренүләрнең төп нәтиҗәләре Казан университеты басмаханәсендә нәшер ителгән ике китапта урын алды.

Шунысы мөһим: бу ике китап та

Безнең мирас №2 февраль 2017

фәнни һәм мәдәни җәмәгатьчелек тарафыннан бик тә уңай кабул ителде: урыс, татар, башкорт телләрендә мәкалә-рецензияләр басылды; Казан университетындагы 1983 елгы фәнни эшләр конкурсында алар беренче урынны алдылар, китап авторлары лауреат исеменә лаек булды. Ш.Садретдиновның М.Гайнетдинов белән берлектә әзерләнгән «Әбелмәних Каргалый» дигән китапчыгы да бар (КДУ нәшрияты, 1978. — 36 б.). Ул студентларга әсбап-ярдәмлек рәвешендә язылган.

Мәгълүм ки, узган гасырның 80-90 еллар аралыгында, илдәге үзгәртеп коруларга нисбәтән, милли тормыш та шактый җанланып китте. Милли мәгарифне торгызу, мәктәпләрдә, уку йортларында татар телен һәм әдәбиятын ныклап өйрәнү көн тәртибенә куелды. Шуңа мөнәсәбәттә уку-укыту программалары төзелде, аларга нигезләнеп дәреслекләр язу башланды. Татар урта мәктәпләренең, гимназияләренең 9 нчы сыйныфы, педагогия училищелары, көллиятләр өчен дәреслек-хрестоматия төзү эшен Татарстан мәгариф министрлыгы Ш.Садретдинов белән без фәкыйрегезгә йөкләде. Ныклы фәнни әзерлек һәм педагогик тәҗрибә таләп итүче бу җитди бурычны без ул вакыттагы көчле милли энтузиазм, дәрт һәм гаять җаваплылык белән башкарырга омтылдык. Бу дәреслектә меңьеллык татар әдәби процессы, төп әдипләр, аларның әсәрләре, теоретик төшенчәләр, әдәби бәйләнешләр яктыртылды. Һәр бүлек тиешле сорау-биремнәр, методик аппарат белән тәэмин ителде. Аның Борынгы һәм Урта гасыр чоры, XIX йөзнең икенче яртысындагы поэзия, Акмулла, Гали Чокрый, Яков Емельянов турындагы бүлекләре безнең тарафтан язылды, ә XIX гасырның төп өлешен Ш.Садретдинов әзерләде. Программага, дәреслеккә туры китереп, без Тукайгача чор әдәбиятыннан IX сыйныф өчен 456 битлек хрестоматия дә төзедек. Әлеге дәреслек-хрестоматияләр инде ике дистә елдан артык гамәлдә: зур тиражлар белән алар инде дүрт мәртәбә кабат нәшер ителде. Бу китапларга, шул исәптән Ш.Садретдинов тарафыннан язылган бүлекләргә дә минем тарафтан аерым хосусый үзгәреш-төзәтмәләр кертелде. IX сыйныфка адресланган әлеге дәреслек-хрестоматияләр хакында укытучыларның, галимнәрнең (Ф.Нуриева, И.Галимов, С.Трофимова...) язмалары, кызыклы фикерләре бар.

Ш.Садретдинов XIX йөз татар әдәбиятында эстетик идеал проблемасын да ныклап өйрәнә башлаган иде. Бу юнәлештә ул берничә мәкалә дә язды, фәнни конференцияләрдә докладлар да сөйләде. Болар арасында аеруча аның «Акмулланың эстетик идеалында Ш.Мәрҗани образы» дигән чыгышы кызыклы булды. Ул 1983 елда Г.Ибраһимов исемендәге институт нәшер иткән җыентыкта да басылып чыкты («Материалы юбилейных торжеств и научной конфер., посвящ. 150-летию Акмуллы...»). Галим, архив материалларына нигезләнеп, 1993 елда «Татарские стихи в архиве Г.Р.Державина» дигән язмасын да бастырды. «Әдәбият белеме сүзлеге»нә, «Татар энциклопедиясе»нә мәкаләләр дә язды.

Ш.Садретдинов яшьтән үк шигырьләр дә язды, тәрҗемә белән дә шөгыльләнде. Аларның кайберләре көндәлек матбугат битләрендә басылып та чыкты. Әмма хезмәттәшебез үзенең әдәби әсәрләрен туплап, аерым җыентык рәвешендә нәшер итәргә әллә теләмәде, әллә өлгерми калды. Шунысын да искәртик: Ш. Садретдинов, остазы Х.Госман кебек, шигъри табигатьле кеше иде. Ул әдәбиятны, аеруча поэзияне нечкә тоемлады. Әлеге хосусият аның фәнни-тәнкыйди эшчәнлегенә, аеруча тел-стиленә дә уңай йогынты ясады.

Әмма, ни үкенеч, бу намуслы, тырыш галимгә, укытучыга, журналистка зуррак, республика дәрәҗәсендәге бүләк-исемнәр бирелми калган икән. Ул, бәлкем, өлешчә аның гадәттән тыш тыйнаклыгы белән дә аңлатыладыр.



Ш.Садретдиновка гомеренең ахыргы елларында өеп-өеп кайгы-мәшәкатьләр килеп торды: чирек гасырдан артык бергә яшәгән хатыны Люция ханым үлеп китте, кече кызы бәхетсезлеккә очрады; бер-бер артлы туган-тумачаларын җирләп торды... Кабат корып караган гаилә тормышы да озын гомерле булмады. Өстәвенә, Шәйхиебез аягын да сындырды. Бу төр сәбәпләр аркасында соңгы вакытта бик нәтиҗәле эшли алмавына Ш.Садретдинов үзе дә бик читенсенеп йөрде. Пенсия яшенә җитеп килүен исәпкә алып, аңа 1995 елның декабрендә яңадан бер елга гына эшләргә тәкъдим иттеләр. Шәйхи дустыбызның әлеге мәсьәлә каралган кафедра утырышындагы борчулы кыяфәте, үзен гаепле тоткандай сагышлы карашы хәзер дә күз алдында. Хезмәттәшебез алга таба да булдыра алган кадәр тырышып эшләп йөрде: дәресләр алып барды, гадәттәгечә, күп кенә курс-диплом проектлары белән җитәкчелек итте. Әмма, һич тә көтмәгәндә, рәхимсез үлем алтмышынчы яшен ваклап барган Шәйхи дустыбызны 1996 елның 21 мартында арабыздан алып китте. Алдагы көнне генә кичкә таба аның белән очрашкан идек. Зарланмады да, кәефе дә ярыйсы күренде. Икенче көнне иртүк кызы Гүзәл: «Әти үлде!» – дип шылтыраткач, ышанмадым: такси алып, тиз генә аларга киттем. «Яман хәбәр хак була», дип юкка гына әйтмиләр шул: Шәйхи дустыбыз утырган җирендә кинәт бөгелеп төшә дә, җан бирә.

Хезмәттәшебезне соңгы юлга озатуда гаять күп кеше катнашты. Ул гомер иткән Галактионов урамындагы йорт ишегалдында гына түгел, урам якта да дөнья кадәр халык булды. Бик күп җылы, хәтта үкенечле сүзләр дә әйтелде. Якыннарының теләге белән, Ш.Садретдинов туган авылында әтиәниләре күмелгән зиратта җирләнде. Шунысы куанычлы: Шәйхи дустыбызны аның хезмәттәшләре, шәкертләре, күпләгән укытучылар гына түгел, ә якташлары, авылдашлары да даими истә тота. Ул укыган мәктәптә музей бар, туган ягында төрле чаралар оештырыла. Казаннан да дуслары, шәкертләре килеп тора. ■

Безнең мирас №2 февраль 2017

Атым – пар канатым!

Казан татарларының ат бәйгесе. 1800 ел

ТӨРКИ ХАЛЫКЛАРНЫҢ АТЛЫ УЕННАРЫ

Борынгы заманнардан бирле татарлар да, кардәш-тугандаш төрки халыклар да атларны бик яраткан, кадерләгән, чөнки аларның тормышы вә көнкүреше дә, гореф-гадәтләре дә атка бәйле булган.

Бөтен төрки халыклар өчен «Анайорт» булган җирдән, Алтай тауларыннан без – татар, башкорт, төрек, хакас, чуваш, төрекмән, кумык, гагауз һ.б. – атларга менеп таралганбыз.

Хәтта борынгы төрки дәүләтләрнең тугра һәм байракларында да ат рәсемен күрә аласыз (ә инде хәзерге Татарстанга кайтсак, мәсәлән, «КамАЗ»ларны чыгара торган заводыбыз да, «Аргамак» журналы да үзләренә символ итеп шулай ук ат рәсемен сайлап алганнар).

Тарихчылардан татар җайдакларын Герберштейн, Худяков, Карамзин да үз китапларында мактап үтә.

Безнең мирас №2 февраль 2017

Күчмә халыкларның II Бөтендөнья атлы уеннары. «Кыз куу». Кыргызстан, 2016 ел

Атлы казакъ, татар, башкорт, калмык (ойрот) полклары Рәсәйгә 1812 елгы Ватан сугышында да зур ярдәм иткән, шуның турында татар халык фольклорында, җырларында мондый юлларны таба алабыз:

Казак китә, озатыйк
Ком аякка җиткәнче;
Кояш баеп, эңгер кабар,
Без аерылып киткәнче.
Казак булып китеп барам,
Кара каеш билләрдә;
Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз
Туып-үскән илләргә.

(«Казак озату» җыры, татар халык иҗаты, «Тарихи һәм лирик җырлар». – Казан, 1988 ел, 77 бит).

Татар, башкорт, казакъ халыкларында «Акбүз ат», «Тулпар» хакында күп әкиятләр, җырлар, шигырьләр дә иҗат ителгән.

Татар, ногай, кыргыз, карачай, казакъ һәм башка төрки телләрдән рус теленә ат белән бәйле байтак атамалар кергән: аргамак, арчак, чепрак, казак, есаул, ертаул, бахмат, джигит (йигит, игит; шуннан – «джигитовка»), табун, кутерьма, кумыс, айран, хайван, чубарый, лошадь («алаша-ат») һ. б.

Безнең күп бәйрәмнәребез ат катнашуы, ат чабышлары, бәйгеләре белән үткәрелгән; әле онытылмаган бәйрәмнәребездә – Сабан туенда, җыенда, Барда җыенында (фольклорчы Ф.Уразманова «ат аягы кыздыру» гадәте белән таныштыра: киләчәк бәйгеләргә атларны әзерләү – карлар эрегәч һәм юллар кипкәч, егетләр берничә кич атларга менеп чабышалар).

Әйе шул, егерме беренче (!) гасырда да ногай, хакас, карачай, кыргыз, казакъ, азәрбайҗан, төрекмән һәм башка тугандаш төрки халыкларда бәйрәмнәр атсыз үткәрелми...

Төрки бәйрәмнәрнең бу сыйфатына татар шагыйрьләре дә дикъкать иткән. Мәсәлән, шагыйрь Зиннур Мансуров **«кыз куу»** хакында үзенең Урта Азия хатирәсен хисле итеп менә болай язды:

«Бу җебегән егет икән,
Аты атмы?..
Ишәктер...»
Менә шулай уйлый-уйлый,
әйдә, мине кисәт бер.

Кисәтәсең...
Мин бит синнән
Баш тартырга теләмим.
Арага ят кералмасын.
Яхшы сизеп киләм мин!
Хиссиятем шикелле ук,
Атым бераз тыюлы.
«Нигә?..» – дисәң,
Сине юри
Тотыйм әле бу юлы»...

Ошбу шигырьдә күрсәтелгән Азәрбайҗан, Урта Азиядәге төрки халыклардагы «кыз куу» («кыз куумай») уены болай үткәрелә: атка менгән кыз стартка алдан чыгып чабарга тиеш (юлның озынлыгы 300-400 метр), аннары аның артыннан җайдак-егет кызны куып җитеп, аны үбәргә тырыша, ә кайбер төбәкләрдә бу уен аның кулыннан яулык тартып алу белән бәйләнгән.

Кыз, уен мәйданы кырыена килеп җиткәч, кире борылып чаба һәм егеткә камчы белән орырга тырыша.

Ярышлардан соң, иң күп осталык күрсәткән парга – егет вә кызга – бүләк бирелә. Төрки халыкларда чабышкы, аргамак атларга бәйле уен-йолалар гаҗәеп күп һәм бай.

«Байга» («бәйге», «байге», «пойга») – биш, ун яисә унбиш (борынгы заманда – илле!) километрлык дистанциягә чабыш: юлга туры чыгып чабышып, билгеле урында кире әйләнеп, тизрәк финишка җитәргә кирәк. Бу ярышта биштән башлап егермегә кадәр егет катнаша ала.

«Аударыш» («оодарыш», «эниш», «аударыспак») дигән уенның төп максаты – атларда утырган килеш көрәшеп, «дошман»ны өстерәп-этеп җиргә ташлау, аудару. Ярышта икедән күбрәк тә җайдак-көрәшче катнаша ала. Бу көрәштә «дошман»ны еккан көрәшче җиңүче дип санала.

...Җайдаклар катнашкан **«Улак тартыш»** («күк бүре», «бузкаши», русча – «козлодрание») дигән уенда бишәр-унар кешедән торган ике төркем-команда уйный. Бу уенны ешрак Алтайда, Кыргызстанда күреп була. Уен мәйданының озынлыгы 400 метр, ә киңлеге 30 метр була. Футболдагы кебек, капма-каршы ике капка бар.

Уен башланыр алдыннан ике команда мәйданның бер ягында тезелеп тора. Сигнал ишетелгәч, бөтен җайдаклар «улак» (кәҗә гәүдәсе) янына чабып килеп, аны алырга һәм мәйдан уртасындагы диаметры ике метр булган түгәрәккә ташларга тырыша.

Бу уен 15-30 минут дәвам итә. «Улак»ны түгәрәккә күбрәк мәртәбә ташлаган команда җиңә.

Кыргызларда исә егетләрнең осталыгын күрсәтү өчен иң киң таралган уен – **«күмис алу»** (казакъларда ул «тиен энмей» дип атала, безнеңчә исә

Күчмә халыкларның II Бөтендөнья атлы уеннары. «Күмис алу». Кыргызстан, 2016 ел

Күчмә халыкларның II Бөтендөнья атлы уеннары. «Аударыш». Кыргызстан, 2016 ел

– көмеш тәңкә алу). Атны бик тиз чаптырган егет җирдән кечкенә әйберләрне күтәреп өлгерергә тиеш (мәсәлән, акча – «тиеннәр»).

«Җегет җарыс» уены казакъ халкында киң таралган.

Уен башында катнашачак егетләр кулларына ияр тоткан килеш тезелеп тора, ә сигнал бирелгәч, тиз генә үз атларын иярләп, атланып, финишка беренче булып килергә тырыша. Бу ярыштан соң, хөкем итүчеләр, киңәшләшеп, үзара уртак бәһа чыгарып, ияре дөрес куелган атта иң беренче килгән егеткә бүләк бирә.

Анатолия (Анадолу) төрекләрендә **«җирит»** дигән уен бар. Бу уенда, «улак тартыш»тагы кебек, ике атлы команда катнаша (әмма госманлылар заманында җәяүлеләр катнашында да уен уздырылган). Һәр җайдакның берәр «җирит»е (сөңгесе, найзасы) бар. «Җирит»нең озынлыгы – 110 сантиметр. «Җирит» төсләре – сары яисә кызыл. Уен мәйданының озынлыгы – 120-160 метр, ә киңлеге 40-50 метр була. Һәр командада – җидешәр җайдак. Уен шулай башлана: командаларның берсеннән бер җайдак алга чыгып, башка командадагы берәүнең исемен әйтеп чакыра һәм көндәше алга чыкканда чакыручы җайдак аңа «җирит» белән атып тидерергә тырыша. Аннары үзе дә көндәшеннән качарга мәҗбүр була. Хәзер инде аның артыннан куып җитә торган икенче команданың җайдагы үз «җирит»енә атып тидерергә тырыша (ягъни «куян» белән «аучы» урыннарын алмашыналар). Бу вакытта куылган җайдакны коткарыр өчен, аның командасыннан башка җайдак чыгып, үзенә игътибар иттерергә омтыла. Кайсы команданың «җирит» тиюләре күбрәк булса, шул команда җиңүче булып санала. «Джирит» атамасы хакында (аны татарныкы дип күрсәтеп!) рус теле сүзлегендә мәшһүр филолог В.Даль язып та чыккан иде.

Татар яшьләре! Һәр мөмкинлекне кулланыйк: төрки бабаларыбызның уеннарын онытмыйк, оныттырмыйк!

Айрат Галимҗанов,
фольклорчы, тарихчы, тюрколог.
e-mail: ayrat.galimzyanoff@yandex.ru ■

Безнең мирас №2 февраль 2017

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ*

Габдерәшит Ибраһимов

ТӨРКЕСТАН

1907 елның ахырында мин, гаиләмне туган җирем Тара шәһәрендә калдырып, Төркестанга барырга дип юлга чыктым. Ташкент юлында урнашкан шәһәрләр шулар иде: Омск, Петропавловск (Кызылъяр), Чиләбе, Уфа, Кенил (Кәнил), Оренбург, Актүбә, Акмәчет, Төркестан, Ташкент.

ТАШКЕНТ

Моннан 40 еллар элек мөселман шәһәре булган Ташкент – бүген Русия губерналарының берсе һәм бөтен Төркестан, Фирганә һәм Сырдәрья губерналарына идарә үзәге.

Ташкент, читтән караганда, бербөтен шәһәр булып күренсә дә, эчтән әле дә ике мәмләкәт дип әйтерлек ике мәхәлләгә бүленгән, ягъни биредә ике төрле идарә ителә торган рус һәм мөселман мәхәлләләре бар һәм алар шулай атала да.

Рус мәхәлләсендә нигездә руслар яши. Мөселманнар да бар, ләкин бик аз. Аларның да күпчелеген җирле халык түгел, Русиянең эчке төбәкләреннән күчеп килгән татарлар тәшкил итә. (Җирле халык татарларны *ногай* дип атый, гомумән, бөтен Төркестан Русия татарларын *ногайлар* ди).

Ташкентның руслар яши торган өлешендә йортлар һәм кибетләр төзек, урамнар төз, тротуарлар тигез, электр утлары һ.б. бар. Аурупаның бер кисәген китереп куйганнар диярсең. Ләкин мөселманнар яшәгән өлеше моның капма-каршысы – 500 ел элек нинди булса, хәзер дә шундый: язын, көзен шәһәр эчендә бер өйдән икенчесенә җәяүләп барып булмый, юлларда шулкадәр сыек балчык була ки, сөйләп аңлатырлык түгел, кайбер урамнардан хәтта хайваннар да үтә алмый. Югыйсә, шәһәр – шул бер үк шәһәр, Ташкент. Идарәсе бер үк, керемнәре бер үк, шәһәр халкының күпчелеге – мөселманнар. Салымнарны мөселманнар да түли, тик керем христианнар яши торган урамнарны карау өчен генә тотыла. Ташкентта гына түгел, бөтен Төркестанда шушы ук хәл: рус Сәмәрканды – чиста һәм төзек, мөселман Сәмәркандында – баткаклык, рус Хоканды – төзек һәм тәртипле, мөселман Хокандында исә, аяк атлап йөрү түгел, атка яки ишәккә атланып та йөри алмаслык. Рус Маргиланы да шундый ук җитешле, мөселман Маргиланы исә, һәрвакыттагыча – мөселманнарга лаек! Саный китсәң, бар да бер үк... Кайда гына булса да, хаким – көч русларда, мәхәлләнең идарәсе һәм җыелган акча алар кулында, үз урамнары өчен чыгымнар уртак керемнән тотыла. Мөселманнар яши торган урамнар өчен ник бер тиен акча тотылсын, күтәртмә юллар да юк, фонарьлар да юк, гомумән, берни юк.

Мөселманнарга андый ук өстенлекнең кирәге дә юк! Төп мәсьәлә анда түгел. Тип-тигез тротуарлар булмаса да, һичьюгы күршеләр бер-берсенә азапсыз гына кереп чыга алырлык юллар ясалсын иде. Ләкин шунысы бар – чит ил

* Башы журналның 1 нче санында

Габдерәшит Ибраһимов

кешеләренә: «Менә күрегез мөселманнарның булдыксызлыгын, һич булмаса күршеләреннән гыйбрәт алсыннар иде, боларны менә Ислам шулай тәрбия кыла инде...», – дип, бу эштәге кимчелекне Исламга сылтаудан да тайчынып тормыйлар. Кешенең сукырлыгы шаккаттыра: бу кадәр золымга, хаинлеккә игътибар итми, ә кимчелекне Исламга сылтарга җөрьәт итә, урамдагы күтәртмә юлларның торышы өчен дә динне җаваплы итеп китереп куя.

Чынлап та, Ташкентның мөселманнар яши торган өлеше борынгы шәһәр булганга, урамнары тар, ләкин бу – тар урамны төзекләндереп булмый дигән сүз түгел лә. Киресенчә, тар урамнарга күтәртмә юллар ясау күпкә җиңел, чыгымы да азрак. Әгәр шәһәр идарәсе бер икән, салымнардан килгән акча уртак икән, күтәртмә юллар төзү, урамнарны яктырту – идарәнең вазифасы булып чыга түгелме?! Рус мәхәлләсен төзекләндергән идарә ни өчен мөселман мәхәлләсен төзекләндермәскә тиеш?! Бу бик уйланырлык мәсьәлә!

Чынбарлыкны тагын да ачыграк аңлар өчен менә бу хисапка карыйк әле: Ташкенттагы халык саны 200 мең дип исәпләнә, боларның 18 меңе – христианнар, калганнары – мөселманнар. Ташкентның хакимият идарәсендә җәмгысы 72 әгъза бар, боларның 24е – мөселман, калганнары – христиан. Болар барысы да сайлап куела, ләкин идарә канунында менә болай каралган: руслар белән мөселманнар катнаш яши торган районнарда, анда мөселманнар күп булуга да карамастан, шәһәр идарәсенә сайланачак мөселман әгъзаларның саны барлык әгъзалар санының өчтән берен тәшкил итәргә тиеш, шуннан артык була алмый. Билгеле инде, хакимият идарәсендә карарлар да күпчелек тавыш белән кабул ителә. Шулай булгач, кешелеклелек кайда инде? Тигезлек кайда? Менә сиңа XX гасыр мәдәнилеге!

Ташкент шәһәрендә һәм, гомумән, бөтен Төркестанда тагын бер сәер хәл бар. Шаккатырлык! Бу шәһәрдә Русиянең эчкәреге төбәкләреннән күчеп килгән татарлар күп. Төркестанның бар җирендә дә татарлар яшәве һәм биредә аларны *ногай* дип атаулары турында бераз алдарак язган идем инде. Менә шул ногайларга карата да бернинди тигезлек юк. Төркестанны яулап алганда, ногайларның күбесе гаскәри хезмәттә булган, рус гаскәрләре белән Төркестанга килгән, дин кардәшләренә каршы корал тотып сугышкан, Төркестан яулап алынганнан соң шунда яшәп калган, кайберләре гаилә корган, тормышларын җайлап, йортлы-җирле булуга да ирешкән.

Соңгы сәфәрләрем вакытында белдем: хәзер исә Русия хөкүмәте Төркестан губернасына кагылышлы махсус канун кабул иткән: ногайлар бөтен Төркестанда күчемсез мөлкәткә ия була алмаячак. Инде бөтен Төркестанда ногайлар йорт-җирләрен сатарга мәҗбүр ителде. Барысы да сатты. Әгәр үзләре сатарга теләмәсә, хөкүмәт аукционга куеп сатты. Төркестан яулап алынган вакытларда мөселман кардәшләренең канын түккән ногайлар менә шундый «тәкъдир бүләге» алды!



Ташкент күренеше. 1907 еллар тирәсе. © Пряхин С.Г., 2016

Ташкент шәһәрендә мин бер ай тордым, галим һәм зыялылардан бик күп кешеләр белән күрешеп таныштым, дуслаштым. Алардан шактый мәгълүмат тупладым, түбәндә шуларны кыскача бәян итәм.

Русия хөкүмәте бөтен Төркестан губернасына идарә итү турында аерым бер канун чыгарып, Төркестанны Русия хөкүмәте идарәсеннән бөтенләе белән аерган, бүлгән. Төркестанның мөселман халкы бүген Русия гражданнары хокукларына ия түгел. Төркестанда бөтен канун һәм кагыйдәләр җирле халыкның холык-табигатенә яраклаштырылган. Алдарак та әйтеп үткәнемчә, Ташкент үзе – бүгенге көндә Русия губернасы, ләкин Ташкентта яшәүче кеше Русия гражданы, ягъни ватандашы булып саналмый. Ташкентта яшәүче мөселман кешесен граждан дип түгел, әсир дип атау дөреслеккә күбрәк туры килә, чөнки аларга ватандашларга карата булырга тиешле мөнәсәбәт күрсәтелми. Бигрәк

Ташкент күренеше. Кауфман проспекты. 1907 еллар тирәсе

тә Ташкент ногайлары ватандаш түгел. Әгәр ватандаш булса, алар Ташкентта йорт-җир җиткезә алыр иде.

Бу урында шуны да әйтергә кирәк: Ташкент үзе – губерна, ләкин биредә губернатордан башка тагын гадәттән тыш хәлләр буенча хәрби идарә башлыгы да бар, аңа генерал-губернатор диләр. Югары урындагы бу кеше бары тик Ташкент өчен генә түгел, бөтен Төркестан өчен дә абсолют хакимият вәкиле булганга, Төркестан белән бәйле мәсьәләләрдә, кирәк дип табылса, канунны да санга сукмау хокукына ия. Төркестан губернасы гына түгел, Бохара әмирлеге дә күпчелек мәсьәләләрдә генерал-губернатор күзәтчелеге һәм идарәсе астында тора. Бохара әмире шәхсән бер эш белән Петербургка мөрәҗәгать итәргә теләсә, моны бары тик әлеге генерал-губернатор аша гына, аның рөхсәте белән генә башкара ала. Түрәнең тоткан урыны җирле халык карашында да шундый зур, шундый дәрәҗәле ки, бу мөхтәрәм затка алар хөрмәтләп, олылап «ярты падишаһ» диләр. Төркестанның бүгенге тормышы һәм яшәешенең дәвамлы булуы тулысынча шушы «ярты падишаһ» идарәсендә һәм хөкемендә. Ташкентның менә шундый югары хакимият үзәге булуын һәм моңа бәйле рәвештә җәмгыятьтә мөһим урын биләргә тиешлеген дә исәпкә алсак, бу үзәктәге мөселман мәхәлләсенең баткаклыкта калуын берничек тә аңлап булмый. Шундый олы дәрәҗәле үзәктә, алдарак әйтеп үткәнебезчә, күршеләрнең бер-берсенә керү-чыгуы өчен дә юллар ясалмаган, сазлык мәхәлләнең булуына һич ышанырлык түгел. Әмма, бар. Әле нинди диең?! 180 мең кеше яши торган мәхәллә! Шунысын кистереп әйтергә мөмкин: Төркестанда мондый шәһәрләр, мондый мәхәлләләр булуы турында Аурупа сәяхәтчеләренең берсе генә дә, берни дә язмаган булса кирәк. Әгәр язган булсалар да, бу кимчелекне, артталыкны, һичшиксез, Исламияткә сылтаганнардыр.

Ташкентның мөселман халкы тирәюньгә фаш булган бу кызганыч хәл турында инде берничә тапкыр хөкүмәткә мөрәҗәгать иткәннәр, әле һаман да итәләр, хәтта Петербургка махсус вәкилләр дә җибәреп караганнар. II Дума җыелышында Ташкент депутатлары бу мәсьәләне Дума утырышына

куеп караганнар иде, ләкин сүзләренә игътибар бирүче генә табылмады. Кайбер Дума әгъзаларының Ташкент депутатлары сөйләгән сүзләргә ышанасылары да килми.

Ташкент бүгенге көндә Төркестанда зур сәүдә үзәге булып тора. Аурупадан бирегә сәүдәгәрләр килә, сату итә, мал ала. Мөселманнар арасында да дәүләтле кешеләр күренгәли. Зур сәүдә белән шөгыльләнүчеләрнең күбесе җирле яһүдиләр булып, бу эшне кулларында алар тотса да, мөселманнар арасында да күренекле сәүдәгәрләр бар. Соңгы елларда бөтен Төркестанда «Американ» дигән мамык сәүдәсе зур абруй казанды. Хәзер монда берничә мамык эшкәртү фабрикасы бар. Шунысы куанычлы: бу өлкәдә шактый эш мөселманнар карамагында.

Ләкин гаҗәп һәм кызганыч ки, бу көнгә кадәр Төркестан мөселманнарының бер генә мәктәбе дә юк. Җирле мөселманнар арсында русча белүче кеше – бик сирәк күренеш. Миссионерлар йогынтысыннан курыкканга, мөселманнар балаларын рус мәктәпләренә бирмиләр. Шул рәвешле бөтен Төркестан мөселманнары җаһиллек дәрьясына баткан, әхлакый бозыклык һәм эчкечелек бик тиз арта бара. Боларны күреп аңлаган кешедә хәтта: «Төркестан милләте – үлемгә хөкем ителгән милләт» дигән фикер туарга мөмкин. Ләкин шул ук вакытта, Төркестанның бөтен шәһәрләрендә дә, озын караңгы төннәрдә ара-тирә ялтыраган яшен уты кебек, мөселманнарның үз көчләре белән ачкан кечерәк кенә башлангыч мәктәпләре, элекке заманнардан калган мәдрәсәләре дә күренгәли, барлы-юклы өметне болар сүндерми, яшәү чаткылары кабына калса, янә боларда кабыначак. Төркестан яулап алынганга 45 ел үткән булса да, рус югары уку йортларын тәмамлаган бер генә мөселман кешесе дә юк, якын киләчәктә дә булырга охшамаган.

Ташкент халкы – бик кунакчыл, югары әхлаклы, ачык йөзле, искиткеч талантлы һәм зиһенле. Араларында аз булса да, һич мәктәп күрмәгән, ләкин камил дәрәҗәдә русча һәм немецча сөйләшүче кешеләр бар. Шунысы аяныч: әлегә кадәр милли тәрбиянең зарурилыгын тану юк. Бер генә өмет бар: Ташкент мөселманнары сәүдәгәрлек белән төрле тарафларга юнәлгәннәр; Мәскәү, Петербург һәм башка зур шәһәрләргә сәүдә капкаларын ачканнар; боларның балалары, һичшиксез, барган җирләрендә миллият фикере белән танышачак һәм, шул рәвешле киләчәктә милли көчкодрәт тупланачак.

Ташкент халкы җирле үзбәкләрдән яки катнаш төрки кавемнәрдән оешкан, телләре – саф төрки үзбәк теле. Фарсыча сөйләшүчеләр дә күп. Фарсыча шигырь һәм әдәбият белән шөгыльләнүчеләр дә аз түгел.

Белмим, нишләптер, җирле мөселманнарны, бөтен Төркестан һәм Бохара мөселманнарын *сарт** дип атау киң таралган. Бигрәк тә безнең татарлар һәм руслар *сарт* атамасын куллана. Ләкин сартларның күпчелеге моны кабул итми, кайберләре хәтта алай атаганны яратмый, үзләрен «шәһәр халкы» диләр.

Ташкентта биналары борынгы сәнгать үрнәкләре дип күрсәтерлек шактый мәдрәсә һәм зур мәчетләр бар. Хөкүмәт тарафыннан ачылган кечкенә бер китапханә белән кечкенә генә бер музей да бар. Болардан тыш искә алып әйтерлек башка берни юк.

Дәвамы бар

Текстны төрек теленнән
***Асия Рәхимова** тәрҗемә итте.* ■

*Сартлар – XV-XIX гасырларда Урта Азиядә яшәгән халыкның бер өлешенең атамасы. XX гасырның беренче чирегенә кадәр, Урта Азиядәге күчмә халыклар бу исемне утрак тормыш белән яшәүче үзбәкләргә һәм таҗикларга карата кулланган. *(тәрҗ. иск.)*

2017 ЕЛДА ДИНИ БӘЙРӘМНӘР
ҺӘМ ИСТӘЛЕКЛЕ КӨННӘР

Мөселман ай календаре буенча 1438-1439 һиҗри еллар

29 март – мөселман календаренда изге саналган Рәҗәб аеның беренче көне. Бу айда Ибраһим (г.с.) пәйгамбәрнең, Гайсә (г.с.) пәйгамбәрнең туган көннәре һәм башка истәлекле көннәр билгеләп үтелә. Шулай ук кече хаҗ, гомрә хаҗы кылына.

31 март – Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кич – Рәгаиб кичәсе дип атала. Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе дә.

24 апрель – Мигъраҗ кичәсе. Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә – Аллаһы Тәгаләнең тәхете янына кылган могҗизалы сәяхәте. Мигъраҗ уразасы 100 көн ураза тотуга тиңләнә.

11 май – Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтул-Бәраәт». Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышларын билгели.

21 май – Идел Болгарстанында Ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн (310 нчы һиҗри, 922 нче милади ел).

27 май – изге Рамазан ае һәм Ураза башланган көн. Рамазан аенда иң кадерле кичә – Кадер кичәсе.

25, 26, 27 июнь – Гайдел-фитыр, Ураза бәйрәме. 25, 26 июнь – ял көннәре.

31 август – Гарәфә көне. Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

1 сентябрь – Гайдел-Әдъхә, Корбан бәйрәме. Мөселманнарның иң зур (җомга көн һәм гает) бәйрәмнәренең берсе. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме, ул 3 көн дәвам итә. Бу көн Татарстан Җөмһүриятендәге барлык календарьларда кызыл төс белән билгеләнгән.

2, 3, 4 сентябрь – Тәшрикъ көннәре. Бу көннәрдә мөселманнар, фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһы Тәгаләне мактап зикер әйтә.

Хаҗи Абдулла Дубин *әзерләде.*

Безнең мирас №2 февраль 2017

АК ӘБИ

Җәлил хәзрәт Фазлыев,
Татарстанның баш казые

Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдулилләәһи раббил гәәләмиин. Үәссаләәту үәссәләәму гәләә расүүлинә Мухәммәдиү үә гәләә әәлиһи үә әсъхәәбиһи әҗемәгиин.

Пәйгамбәребез с.г.в. үзенең бер хәдисендә: «Бәндә Аллаһыга якынрак булган саен, Ул аны катырак сынар, сынауны уңышлы үткән саен, Аңа якынрак булыр», – дип белдергән. Икенче бер хәдисендә исә: «Шундый заман килер, дин тоту утлы күмер тоткан шикелле булыр: тотсаң – пешерер, ташласаң – сүнәр, сөенеч шул кешеләргә – кемнәр шундый вакытта Ислам динен саклап, башкаларга җиткерә алсалар», – дигән. Партадаш дустым Зәкиулланың әбисе Фатыйма абыстай менә шушы аятькә һәм хәдискә туры килә торган абыйстай иде. Мин 7 нче класста укыганда, гарәп хәрефләрен өйрәнеп, китаплар таный башлагач, Аланнан (бездән 6 чакрым ераклыктагы авыл) килеп укучы партадашым Зәкиуллаларга кунакка бардым. Шунда Зәкиулла белән икәү аның әбисе Фатыйма абыстайның хәлен дә белдек. Ул Зәкиуллалардан ерак түгел, ялгыз яши иде. Мин аны әле хәзер дә Марсель Галиевнең: «Ак сакаллы бабайлар, ак әбиләр кайда сез хәзер?» – дип куйган соравына ачык мисал итеп күрәм. Нәкъ ул сурәтләгәнчә, шундый күркәм, чын ак әби – татар карчыгы иде Фатыйма абыстай. Без анда ишегалдында вактөяк эшләр белән маташтык һәм инде Зәкиулла дустым әбисенә минем гарәп хәрефләрен белүемне әйткәч, Фатыйма абыстай миңа тагы да хөрмәт белән караган күк тоелды. Зәкиулла миңа да әбисенең чормасында шактый китаплар барлыгын «чиште». Фатыйма абыстай бер дә аптырап тормыйча: «Барыгыз, менегез һәм үзең укый торганнарын, күңелең ятканнарын алып төш», – диде, миңа карап. Без Зәкиулла белән чормага мендек. Минем андагы «байлык»ка исем-акылым китте, бу – Әбүгалисинаның мәгарәсеннән бер дә ким түгел иде: андагы китап, андагы китап... Араларында шактый зурлары, хәтта чөй (рун) язуы белән язылганнары да бар иде. Кызганыч, ул китапларның хәзерге язмышын белмим. Шактый еллар үткәч, Миркасыйм ага Госманов экспедиция белән килгәч, без Аланга бардык, әмма чормадагы китапларның берсе дә юк иде инде. Ләкин мин әле дә анда күргән китапларны оныта алмыйм. Ул чагында мин гарәп хәрефләре белән язылган татарча китапларны, күпме кирәк – шулхәтле алып төштем. Фатыйма абыстай аларны карап: «Менә монысын кире китерерсең, монысы үзеңдә калсын», – дип, кайсын вакытлы гына укып торырга, ә кайберләрен үземә үк бүләк итеп бирде. Шулай итеп, мин китапларга шактый баедым.

Әле хәзер уйлап утырам: нинди авыр, куркыныч еллар булуга карамастан, үзенең хәзрәтенең (ирен алып китеп атып үтергәннәр) һәм Яңгул

Фатыйма абыстай (уртада) туганнан-туган сеңлесе Рәйсә Галиәкбәрова (сулда) һәм бертуган сеңлесе Хәлилә Хәйретдинова белән. 1980 нче еллар. З.Минһаҗев фотосы

мулласының китапларын (анысы куылган вакытта бөтен китапларын Фатыйма абыстайга биреп калдырган) – менә шул бөтен хәзинәне Фатыйма абыстай йөрәкләнеп алып кала алган һәм күз карасыдай саклаган.

Безнең үзебезнең әби-бабайлар урыс хәрефләрен дә укый-яза белмиләр иде. Мин Фатыйма абыстайның, шушы китапларны укып, шулкадәр дини һәм дөньяви мәгълүматы булуына да шакката идем. Ул бик оста мөгаллимә һәм шул ук вакытта психолог та иде: бик матур итеп сөйли, җайлап кына безне вәгазьли, бервакытта да каты итеп бәрелми.

Бервакыт Фатыйма абыстай безгә: «Сездән җүнле кеше чыгармы икән инде? Мәктәбегездә дә җүнлелеккә һич өйрәтмиләр», – диде. Без, аптырап: «Ничек инде өйрәтмиләр?» – дидек. «Сезгә бит анда:

«Тиздән үсеп җитәрбез,
Әтиләр эшен дәвам итәрбез», – дип җырлаталар. Әтиләрегез салырга ярата, аларның эшен дәвам иткәч, сез дә исерекләр булырсызмы икән», – диде Фатыйма абыстай, моңа җавап итеп. Еллар үткәч, хәзер аның бу сүзләрен уйлап утырам: ул бит безне шулай тәрбияләгән, бала тәрбияләүдә аның үзенә генә хас алымнары булган. Ул вакытта безне кызыксындырган дини сорауларга да матур гына иттереп җавап бирә алган Фатыйма абыстай.

Күрше Сәрдегән авылында хәзрәтнең карчыгы Зәйнәп абыстай Мифтахова бар иде. Мин аңа да китап алырга төшкәли идем. Һәм шушы ике абыйстай – Зәйнәп әби белән Фатыйма әбидән алган китаплар арасында аларның берберсенә гарәп хәрефләре белән Корбан гаете, Ураза гаете, Мигъраҗ кичәләре уңаеннан котлап язган открыткалары килеп чыккалый иде. Шундый авыр заманда да алар авылдан-авылга хатлар язышып, дини бәйрәмнәрне (ул вакытта өйләрендә телефоннары булган кешеләр дә бик сирәк) искә алганнар, курыкмыйча, йөрәкләнеп шушы китапларны безгә биргәннәр, ислам динен күңелләребезгә салырга юл тапканнар. Алар искиткеч гүзәл карчыклар – чын ак әбиләр. Урыннары оҗмахта булсын!

Фатыйма абыстай 100 яшькә чаклы яшәде, аның урыны һәрчак түрдә булды. Зәкиулланың әти-әнисе – Тәүхидә апа белән Зыятдин абый аны, бер авырсынмыйча карады, кадерләде һәм матур итеп соңгы юлга озатты.

Фатыйма абыстай белән Зәйнәп абыстай – романнар язарлык заманнарының чын герой әбиләре. Язган сүзләребез аларга дога булып ирешсен, Аллаһының рәхмәтендә булсыннар. Инде Раббым һәрбарчабызга да Фирдәвес җәннәтләрендә очрашуларыбызны насыйп кылсын! ■

Безнең мирас №2 февраль 2017

Зәкиулла Минһаҗев: «Аналарыбыз яшәү көчен каян алган?!»

(Монологны журналга әзерләүче һәм кереш сүз авторы – язучы Юныс Сафиулла)

Кешелек дөньясы тудырган Акыл хәзинәсендә мондый фикер бар: Адәм баласының җитлегүенә өч төп шарт кирәк. Беренчесе – нәселдән килгән сыйфатлар, икенчесе – тәрбия, өченчесе – сине әйләндереп алган мохит-тирәлек.

Без яшьлек таңыбызда әле менә мондый сорауга да җавап эзли идек: аз санлы милләтләр өчен йә Боз океанына, йә ком чүленә әверелеп торучы Россиядә ислам дине тотучы татар халкы ничек исән кала алды икән?

1973 елны шагыйрь Мөдәррис Әгъләмнең әнисенә багышланган «Бердәнбер» шигырен тыңлагач: «Елатты әле синең бу шигырең», – дигән идем. Тегесен-бусын сөйләгәндә шыттыра торган гадәте дә булган Мөдәррис, ничектер җитдиләнеп: «Бу шигырем әниемә хәер-догам, үткәннәребезгә хәер-догада булсак, киләчәгебез безгә моның әҗерен кайтарыр», – дигән иде.

Әнкәемнең затлы сыйфатлары яшәешемне илһамландырып торуын тасвирлап, «Сөембикә» журналында «Әнкәй» дигән мәкалә бастыруым да әлеге сөйләшү тәэсире нәтиҗәсендә булса кирәк. Гаҗәп, бу юлы мине Мөдәррис үзе эзләп тапты. Аналарыбыз турындагы сөйләшүдән соң бик күп еллар узса да онытмаган икән: «Менә, ниһаять, син дә әниеңә хәер-дога булып барырлык әсәр яздың, тик моны хикәя-очерк итеп кенә калдырма, повесть итеп яз, аңла, бу – бик мөһим!» – диде.

Зәкиулла Зыятдин улы Минһаҗев монологына якын килер өчен, башта шуны әйтәм: танышлыгыбыз 1986 елда башланды. Ул, Югары Ослан районының баш архитекторы буларак, Студенец дигән авыл янәшәсеннән Камал театры артистларына дача җирләре бүлеп бирешергә дип килгән иде. Бик күркәм холыклы, бер генә артык сүз дә сөйләми торган эшлекле бу шәхес, һич тә көтмәгәндә, Фатыйма әбисе турында бәян кылды:

Зәкиулла Зыятдин улы Минһаҗев

– Алан авылы кешеләреннән ишеттем: алар әбиемне әле дә онытмыйлар, очрашканда, яхшы якларына сокланып, кызык якларыннан исә көлеберәк тә сөйлиләр. Әйтик, менә алардан ишеткән бер сөйләк.

Төнлә берәү килә дә: «Фатыйма абыстай, ишекне ач әле», – ди. Әби: «Син

Уртада – әбием Фатыйма абыстай. Уңнан беренче – Минһаҗ бабам (әтиемнең әтисе). Алан урманы. 60 нчы еллар

кем?» – дип сорый. Тегесе, фәлән кеше мин, ди. Әби кабат: «Син кем?!» – дип сорый икән. Теге тагы җавап бирә, аннары да ишек ачылмагач: «Туганыгыз бит инде мин», – дип тә өсти. Әби янә туганы икәнлеген белгәч тә аның кемлеген сорый. Һәм туган дигәнебез башка берни әйтми генә кире борылып чыгып китә.

– Әби, миңа шулай диделәр, дөресме шул, ни өчен шултикле аптыраттың инде, ник кертмәдең?! – дим.

– Төнлә җен йөри, китап өйрәтүе буенча, төнлә шакучыдан өч тапкыр «син кем?» дип сорарга кирәк, ике соравыңа җавап биреп тә өченчесен җавапсыз калдыра икән, инде ишекне ачарга ярамый, – дип җавап бирде ул. Әбиемдә андый мәзәк вакыйгалар күп иде. Җен адәм баласы янына сөйгән кызы булып та, хатын-кыз янына хәләл ире булып та килә икән. Озак еллар балалар укыткан әбиемне тыңлау җан рәхәте иде.

Шунда мин сөйләүчедән әбисенең яшен сорадым. 82дә икән. Түзмәдем: «Ә минем әбием Шәмсекамәр 97 яшенә җитеп дөнья куйды», – дидем. Шуннан бер-беребезне белеп калдык. Мине Зәкиулла әфәнденең, аеруча, шушы сүзләре тетрәндергән иде:

– 1929 елны мулла бабам Габделкаюм Фатыйхов, колхозга каршы коткы таратуда гаепләнеп, атарга хөкем ителә (ату хөкемен 1930 елның гыйнварында Архангельск шәһәренә ун елга лагерьга озату белән алыштыралар һәм бабам 1931 елны әлеге лагерьда үлә), әбием өч сабый бала белән кала. Әнием Тәүхидәгә хәтта 4 кенә ай була, аларның йортларын кыш уртасында тартып алып, үзләрен мунчага чыгаралар.

Безгә бу баш архитектор белән якынаеп китәргә вакыт якларыбыз комачау иткәндер, мәгәр Югары Осланда очрашырга туры килгән чакларда Зәкиулла Зыятдиновичтан: «Әбиегезгә йөз яшь тулдымы әле, кайчан аның турында язасыз инде?» – дип сорап уза идем. 1993 елны Фатыйма әби 99 яшенә җитеп бакый дөньяга күчте, дигәч: «Әниегез Тәүхидә ападан ишеткән истәлекләрегезне язсагыз, алар һәммәбез өчен дә кадерле булыр иде, дөньяда эш бетми инде ул, тәвәккәлләгез инде!» – дигән идем.

Һәм менә, ниһаять, ул миңа үзенең «өлгереп җитүе» турында хәбәр салды. Вакыт дигәнебезнең икебездә дә бик чамалы булуын белгәнгә, бу әзерлекнең

шулчаклы озакка сузылуына аптырамадым. Аннары, вәгъдә иткән монологын гына сөйләмәде Зәкиулла Зыятдинович, кадерлеләре Әлфия (хатыны) һәм Зилә (кызы) белән бергә архивлардан эзләп тапкан күпысанлы документларны да, әнисе Тәүхидәнең Фатыйма әби турында сөйләгәннәрен дә (алары магнитофон тасмасына ук теркәлгән), үзләренең шәҗәрәләрен дә, фотоларын да, бабасы Габделкаюм турында Татарстан прокуратурасыннан алынган аклау кәгазьләрен дә тапшырды. Шулай итеп, ул, зыялы шәхесләргә хас булганча, үткәннәр һәм киләчәк каршында булган изге бурычын үтәде, ягъни буыннар чылбырын ялгады. Ихлас җанлы Мөдәррис Әгъләм исән булса, мөгаен, күзләре яшькә чыланып: «Бу изге эш, афәрин!» – дип куяр иде.

Шуны да өстәү лязем: Зәкиулла әфәнденең монологы, миңа биргән тарихи документлары һәм дә шул юнәлештә туган уртак уй-фикерләребез ярдәмендә, тагы да тулылана төште.

– Нәселдән килгән сыйфатлар турындагы сүзләргә уңай карыйм. Әлбәттә шулай. Безнең илдә элек-электән сүз ирeгe дә, матбугат ирeгe дә булмаган. Мәктәп ачарга да, газеталар чыгарырга да рөхсәт ителмәгән, җитмәсә, халыкларны әле бер-беренә өстергәннәр. Сталин дәвере исә бер милләт эчендәге кешеләрне дә бер-беренә каршы куярга остарып җитә. Һәм шушындый махсус куертылган караңгылык эчендә дә нык рухлы ирләр, олы җанлы хатын-кызларыбыз күпләп үсеп чыга алган. Бу, чыннан да, могҗиза.

Нәсел дигәннәре бит аның бер-беренә үрелеп барган. Шул ук безнең нәсел агачына да бик күп төбәк кешеләре ялганган. Безнең Габделкаюм бабабызның атасы Фатыйх хәзрәт – Казан артыннан. Габделкаюм бабай үзе Арча районының Кырлай-Күнче авылында туган. Әбием Фатыйма – Арча төбәгенә урнашкан Тимерче авылындагы Закир мулла кызы. Безнең нәселдә Балтач ягы, Мамадыш, Саба төбәгеннән чыгучылар да бар дип беләм. Әнә, олы галимебез Марсель Әхмәтҗанов, безнең татар халкы яшәгән төбәкләрдә Кырым иле ханнары белән килгән гаскәриләр дә, нугай татарлары да күпләп төпләнеп калган, дип язды. Сармат һәм болгарларны инде әйтеп тә тормыйк. Татар халкында крепостнойлык булмаган. Татарлар бер авылдан икенче авылга иркен генә күчеп утыра торган булганнар. Борынгы заманнарда яшәгән галимнәрнең кабат басылган китапларыннан кайбер бабаларыбызның Кытай, Корея һәм башка ил халыклары белән тел, лөгать вә әхлак алмашып яшәве турында укып белдек. Әйтик, кытай галимнәре безнең музыка – татарныкы, татарлар кул астында яшәгәндә кергән, диләр икән. Кыскасы, җәһәннәм утларына тиң чорларның казаннарында кайнаган бабаларыбыз гел яңарып торган. Әйе шул, әйе, Юныс, син, бакчачы кеше булгач, белеп әйтәсең, кыргыйлана башлаган алмагачларны да яңа бөреләр ялгап яңартырга була. Татар халкы да һаман яңара, тарихи шартлаулар басымы аны ныгыта, чүп-чарыннан аера. Фатыйма әбием һәм аның кызы Тәүхидә мисалында да күренә бу: тормыш иткәндә нинди генә авырлыклар кичермәгәннәр һәм шунсы кадерле – өерелеп килгән авырлыкларны алар, Ходай сынавы бу, дип кабул иткән.

Фатыйма халыклар төрмәсе дигән яман тамга сугылган Россиядә 1894 елда туа. Бабам Габделкаюм Фатыйх улы Мөхәммәтфатыйховның туган елы 1888дә. Алар икесе дә мулла балалары. Кавышкан еллары – 1918. Әбиемнең дә, бабамның да балачаклары гыйлемгә омтылучы гаиләләрдә узганын әйтеп үтү мөһим. Закир хәзрәт тә, Фатих хәзрәт тә балаларына, байлыкка табынуга караганда, белемгә омтылу яхшырак, дигән тәрбия бирә алганнар. Мулла булу белән бергә мөгаллимлек тә иткән Габделкаюм бабам Беренче Бөтендөнья сугышына мулла рәвешендә алына. Яралана, госпитальләрдә дәвалана. Атаклы Курса мәдрәсәсендә укыган әбием дә белемле мөгаллимә була. Дини белемнән тыш, дөньяви белемнәрне дә бик теләп үзләштерә. Әтисе Закир хәзрәтнең гаиләсе һәрчак эш сөючәнлеге белән

Рәсемдә уңнан беренче – Каюм бабай. Беренче Бөтендөнья сугышы вакыты. Госпитальдән соң

аерылып торган. Хәзрәт кызлары тегү, чигү, туку кебек һөнәрләрнең зур осталарына әверелгән. 12 яшьлек Фатыйма, апаларына ияреп, паласлар тукыган, тастымал, кашага, ашъяулык, намазлык, чаршау кебек нәрсәләр чиккән. Сөлгеләрне нинди генә ысул белән сукмаган ул. Фатыйма әбиебезнең сабый кулларыннан 110 ел элек төшкән әлеге бирнә әйберләре бүген дә сокланырлык рәвештә саклана.

1918 елда Габделкаюм белән Фатыйма төзегән яшь гаилә, Яңгул авылы мулласы Нәкыйпнең тәгъдиме белән, Балтач районының Алан авылына күчеп килә. Чыгышы белән Мирҗәм авылыннан булган Нәкыйп мулла Габделкаюмның сеңлесе Гөлзәйнәпне хәләл җефетлеккә алган икән. Төрле авылларда яшәүләре арадашлык итәргә комачау итмәгән. Габделкаюмга Алан авылы мулласының бакый дөньяга күчүе турында да әлеге Нәкыйп хәзрәт җиткергән һәм муллалыкны алып бирүдә дә ярдәмләшкән.

Россия бу чорда гражданнар сугышы тоткынлыгында. Болай да ярлы гомер кичергән илдән бәрәкәт киткән чор. Яшь гаиләгә Аландагы тормышкөнкүрешләрен өр-яңадан корырга туры килә. Мирҗәм авылындагы иске генә йортларын Балтач ягындагы Алан авылына күчерәләр. Хуҗалыкларын булдырырга бик зур көч куялар. Үз авылларыннан, төрле җимеш агачлары, помидор, кыяр кебек яшелчәләр үрчетү нияте белән, орлыклар да алып килгән булалар. Хуҗалык күтәрелә башлый. Мул уңыш бирә торган карлыган, кура җиләге кебек куаклар, чияләр тирәсендә ботаклары алмалардан сыгылып торган алмагачлар да үсеп җитешә.

Ахыры бар ■

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

Соңыннан *Елдырык* һәм *Айгыр* балкый,
Ирәнтез килә һәм бер сафта атлый.

Менә *Сукеч* купты, югары менде,
Һәм *Исрафил* сорнай сайрата инде[1].

Һәм Үгделмеш торды —
мәшрикъка бакты —
Көн башын калкыткан, дөнья яп-якты.

Югары ургылды кояш нурлары,
Күк йөзенә алсу ялкын үрләде.

Сөйгән яр шикелле дөнья елмайды,
Сагышлар кыскарды, шатлык озайды.

Үгделмеш юынды, намазын кылды,
Атын менде, тауга карап омтылды.

Җитеп, аттан төште, ишеккә тук-тук,
Кардәше ачты һәм кылды бер табуг.

«Сәлам сезгә», – диде Үгделмеш, күрче,
Уйгырмыш кайтарып сәламен бирде.

Кулга-кул тотынып, керделәр өйгә,
Хәл-әхвәл сорашып, килделәр телгә.

Әйтте: — И, кардәшем, ничек килдең, әйт,
Очрашканыбызга ай үтмәде, шәт.

Төшенкерәк күрәм мин чыраеңны,
Йөзеңдә, гүяки, бар саргаюлык.

Ни кайгы тиде, йә, хәлләрең ничек,
Серләреңне чишеп, бер сөйләп бирче.

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ҖАВАБЫНДА СӨЙЛӘГӘНЕ

Җавапта Үгделмеш әйтте: — И, кардәш,
Фәләк ук яудырды, күпне күрде баш.

Фәләк үгет биреп, кыйнаса-ярса,
Үлеп терелерсең (тик тере калсаң).

Гафләт йокысында булган күңелем,
Фәләк-чор укытты һәм, менә, белдем.

Күңел күзе илә сабак тыңладым,
Юлдан язганымны тәмам аңладым.

Тереклегем сүнә, йөгем авыррак,
Инде гөнаһлардан тәүбә кылыр чак.

Гомер сарыф итеп хезмәттә булдым,
Инде гыйбадәт тә кирәген белдем.

Дәүләт килә бирде, көн үтә бирде,
Терелек төкәнгәч, дөнья ни инде?

**Үлемне онытма — тәүбә кыл алдан,
Гафил булма — үлем тотар якаңнан.**

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы санынннан басылып килә.
[1] Ягъни, «таң ата барды». Исрафил — сур (сорнай) кычкырта торган фәрештә, русчасы Серафим.

Мин дәүләт теләдем дөньям өченгә,
Тереклегем беткәч, дөнья чүп кенә.

Бүгенге бу көнем үтеп барамы?
Иртәгә булырмы — ансы караңгы.

Чәчем язгы кавыл кебек: ак, сирәк
Сакалым ак шоңкар төсенә кергән.

Кирәктер үтәргә җәреңге эшне,
Үтәлсен, дим ул эш, и, изге кешем.

Бу хакта хәтергә килде шундый сүз
(Бу сүзне гамәлгә тот, и, күңеле төз):

Үкенәмен узган гомергә үзем.
Ничә көнем калды икән, ай йөзем?

Зая үтеп китте егетлек чорым,
Зая булмасын, дим калган гомерем.

Ашап эчтем малдай, мәгънәсез, зая,
Ачыктырыйм әле үземне, кая.

Күп ашап симерде тәнем һәм җаным,
Бүгеннән, дим инде, тыйыйм аларны.

Күп үтте гомерләр рәхәттә ятып,
Бүгеннән аякта торырга вакыт.

Күп адәмнәр миндин кыерсытылды,
Сөенечле итим иге эш кылып.

Тел вә кул озайттым хәтсез кешегә,
Гозер сорыйм мәллә, дим, һәрберсеннән?

Йөредем күрсәтеп кеше гаебен,
Үземне кисәтим инде, газизем.

Качак мин — Алладан качкан бер надан,
Һәртөрле гөнаһка күмелдем тәмам.

Хәзер тәүбә итеп, кайтыйм Аллага,
Гозеремне әйтеп карыйм мин аңа.

Тәүбәгә киләрәк инде тәмаман
Гафу сорау кирәк, димен, Алладан.

Ни ди, ишет, әнә, белеме тирән
(Сиңа таман бу сүз, күңле нык ирән):



**Үлем тотмас борын уяу бул, саклан,
Үлем тоткач файда булмас — ул чакта.**

«Үлемнән нәфесне тыеп ерагай
(Югыйсә, үкенеп файда юк, агай):

Үлемне онытма — тәүбә кыл алдан,
Гафил булма — үлем тотар якаңнан.

Егет чагында ук намазга баш ор,
Карыйлык килсә, көч-куәтең таксыр».

Үлем тотмас борын уяу бул, саклан,
Үлем тоткач, файда булмас — ул чакта.

Шул уйларым белән мин сиңа килдем,
Нигезле-фикерле бер киңәш бир, дим.

Ни эшләргә инде миңа, кардәшем?
Рәхимле бул, синең белән киңәшим.

УЙГЫРМЫШНЫҢ ҖАВАБЫ

Җавапта Уйгырмыш әйтте: — И, кардәш,
Сүземне тыңла, бул миңа фикердәш.

Нияте-теләге изге булганда
Ир җитә максатка ошбу дөньяда.

Бигүк изге ният кылмышсың үзең,
Ходай бирсен тәүфикъ, яктырсын күзең.

Бер үк төрле түгел тәүбәдә белек,
Төрле-төрле эш бар кул тигезерлек.

Шулардан берсен мин әйтим — син тыңла,
Тәүдә бел һәм уйла, гамәл ит соңра.

Бүген анда тору сиңа игерәк,
Янә монда тору миңа игерәк.

Бүген синнән фәтва күптер ил өчен:
Бастырасың бераз каргыш-сүгешне.

Сиңа илбик бирде чын озын куллык[2],
Тәртип урнаштырып абруйлы булдың.

Халык имин хәзер, төзектер илең,
Дога кылыр һәрбер рәгыять теле.

Ни ди, ишет, файда китергән кеше
(Фәтүә[3] китергән кешеләр башы):

«Кеше арасында кеше шул булыр:
Аңардан кешегә фәтүә килер.
Файдасыз кеше ул — кеше актыгы,
Чын инсан файдасы дөньяга тулыр».

Нияте-теләге изге булганда
Ир җитә максатка ошбу дөньяда.

«Яхшы ният — ярты мал», диләр бездә,
Эшкә ашмаса да үкенмәс бер дә.

Изге булса ният, ил булса тыныч,
Халык шундый ирдән табыр сөенеч.

Хөкемең дөрес һәм төгәл куелды,
Җинаятьче явыз эштән тыелды.

Бу эшләрне ташлап китсәң җиреңдә,
Рухың да бозылыр, үкенерсең дә.

Үзара тикшерү китәр ул чакта,
Бозылыр ил, тагын басмас аякка.

Синең урыныңа килер бер исәр,
Халыкны елатыр, иминлек китәр.

Исәр илне тартыр акылсыз юлга,
Яманлык шул якка эз салып куйган.

Моның өчен Алла җавапка тартыр
Сине һәм югалыр бар изге атың.

Яманлык эшләмә һәм явыз түрә
Яман эш уйласа, мөмкинлек бирмә.

Ни ди, ишет, холкы, күңеле тугры
(Чичәнчә сөйләнгән — онытма моны):

«Яманга ягылма, телгә салынма,
Яманлык кылганга ярдәмче булма.
Игелеккә тартсын эшең вә телең,
Һәр ике дөньяда чүпкә катылма».

Ходай тәүфикъ биргән сиңа — изгегә,
Кулың изге эштә булсын гел генә.

Нигә бозырга, ди, табигатеңне?
Үзеңә зыян ич, и, күңле тере.

Үзеңә һәм илгә зарар тигереп,
Бу җирдә табарсың нинди игелек?

«Хәерлерәк миңа монда», дисәм мин,
Сәбәбе бар аның, йөзе гүзәлем.

Мин мал табып, урда төзеп йөрмәдем,
Теләк-арзуларга күңел бирмәдем,

Халык арасында эш йөртмәдем мин,
Бийләр белән бергә эш итмәдем мин.

Үзем дә күрмәдем бу дөнья малын,
Һәм халыкның яхшы-яман әхвәлен.

Изге булса ният, ил булса тыныч,
Халык шундый ирдән табыр сөенеч.

[2] Озын кул борынгы төрки телдә «хакимият, власть» мәгънәсендә кулланылган һәм бу тәгъбир борынгы рус телендә долгорукий рәвешендә калькалаштырылган.
[3] Фәтүә (татар сөйләшләрендә) киң мәгънәдә — «матди вә рухи файда».

Хәзер шул хәлемдә тагатьне куйсам,
Начар булыр, илдә булмас миңа сан.

Берәү, һич күрмәстән алтын-көмешне
Эш итсә, ишетер тик мең сүгешне.

Ни ди, ишет, әнә сартларның башы,
Дөнья гизеп йөргән Кытай аргышы[4].

«Ярлыдан тырышып хәлләнгән кемсә
Тырышлыгын ташлый, тәмам байдисә.

Фәкыйрьдән баекса бер байлык колы,
Тиз үк ташлый намус-тугрылык юлын».

Котсыз йөреп бермәл ирешсә котка,
Кылыксыз зат афәт китерер йортка.

Илбик булып алса бер затсыз кеше,
Кулын салыр илгә, батырыр тешен.

Ә син исә кулга кергәч бу дәүләт,
Күңлеңне басып, булдың канәгать.

Күзең-күңлең тыныч, комсыз түгелсең,
Илбик белән тиң дус булып йөрисең.

**Исәр илне тартыр акылсыз юлга,
Яманлык шул якка эз салып куйган.**

**ТУГРЫЛЫККА ТУГРЫЛЫК,
КЕШЕЛЕККӘ КЕШЕЛЕК ТУРЫНДА**

Болар әле бер хәл, тагын да берсен
Мин әйтим, син тыңла, төшенеп бел син.

Оныттыңмы яки хаталык китеп,
Бу эшкә юл бирдең[5], файдасын көтеп.

Бу дөньяда мактау, беләсең үзең,
Вафалы кешегә тия, газизем.

Бар булса дөньяда тәртип нигезе,
Кешегә кешелек шуның билгесе.

**Яманлык эшләмә һәм явыз түрә
Яман эш уйласа, мөмкинлек бирмә.**

Игелеккә каршы кылса игелек:
Берен алса, артык бирсә ун өлеш.

Асыл-нәсле ару булса кешенең,
Син шуннан көт илгә файда тиерен.

Көмәнле бер хатын су алса урлап,
Туар угыл һәм ил болгатыр ул зат.

Күрә бел — һиммәтле сиңа бу илбик:
Бирде ич җиемлек һәм дә киемлек.

Гыйлем алдың — сиңа дөнья ачылды,
Илбик кенә моңа сәбәпче булды.

Оныттың мени бу изгелекләрне?
Җавабын бирмикме, и, күңле тере?

Катырак сөйләдем бугай, кардәшем,
Хафаланма, ләкин, хәтрең калмасын.

Туры сүз еш кына ачу ул, агу,
Ләкин йота белсәң бик әйбәт дару.

Пошынма туры сүз тисә күңелгә,
Җәберсенмә шуннан, ярсынма бер дә.

Бу бапта хәтергә килде бу сүзем
(Тыңла әле шуны, и, күркәм йөзем):

«Туры сүз ачы ул, йот һәм сеңдер син,
Шуннан иртәгәсен бер сөенерсең».

Туры сүз күңелгә чыннан да каты,
Тик аның була шәп, тугры сыйфаты.

Атаң үлде, углан, кече чагыңда,
Тәрбия булмады синең яныңда.

Сине илбик алды, тәрбияләде,
Кеше булды шуннан, яхшырды хәлең.

Дәвамы бар ■

[4] Сарт – «сәүдәгәр», Кытай аргышы – «Кытайга барып йөргән кәрванчы».
[5] Нинди эшкә – аңлашылмый.

Безнең мирас №2 февраль 2017

ЧЫҢГЫЗХАННЫҢ АК БОЛЫТЫ

Романга бәян

Чыңгыз Айтматов
(1928-2008)

Аларны мыскыл итәргә сөйрәп чыгарыр алдыннан, баласын тирмәдә соңгы тапкыр имезеп өлгерде ул. Берни дә аңламаган бәхетсез сабый, тына барган барабан тавышлары астында җиңел йокыда изрәп, тырышып-тырмашып, иреннәрен чәпелдәтте. Хезмәтче Алтун янәшәдә тора иде. Күз яшьләренә буылып, үкереп елаудан тыелырга тырышып, әледән-әле учы белән авызын каплый. Шул мәлдә алар үзара бер-ике сүз алышып өлгерде.

– Кайда ул? – дип пышылдады Догулаң, баланы бер имиеннән икенче ягына күчереп, гәрчә үзе белмәгәнне Алтун да белә алмаганын ул аңлый иде.

– Белмим, – дип җавап бирде тегесе, яшьләренә күмелеп. – Ерактадыр, дип уйлыйм.

– Шулай гына була күрсен! Шулай булсынчы! – дип инәлеп әйтте Догулаң. Хезмәтче, җавап йөзеннән, ачынып, башын какты. Алар икесе дә бу мәлдә бернәрсә турында уйлый – йөзбашы Эрдене качып котыла алсын да атына атланып ераккарак чапсын, күздән китеп югала алсын иде, Ходаем.

Тирмә артында адымнар, тавышлар ишетелде:

– Йә, кайда алар! Өстерәп чыгар!

Чигүче, баласының төчкелтемрәк исен сулышы белән суырып алгандай, хәсрәткә чумып, аны соң тапкыр күкрәгенә кысты һәм калтыранган кулларыннан хезмәтчегә тапшырды:

– Күпмедер яши калса, ташлама инде, зинһар, күз-колак бул...

– Ул турыда уйлама! – Алтунның бүтән тыелыр хәле калмады, бугазындагы яшь төерен йотып җибәрә алмыйча, чарасызлыктан, ул үксеп елап җибәрде.

Һәм шунда ук ясавыллар аларны тышка таба сөйрәп алып китте.

Кояш инде офык өстенә күтәрелеп, даланы якты, җылы нурларына чумырган иде. Чигүчене җәзалаганнан соң юлын дәвам итәр мизгелне түземсезләнеп көткән кара болыттай гаскәр һәм олаулар төркемен төрле яктан урап, иксез-чиксез Сарүзәк далалары җәйрәп ята. Калкулыкларның берсендә хаканның алтынсу тәхете-паланкины балкый. Тирмәсеннән чыккан арада, Догулаң, күз кыры белән, җеназа кабыгын хәтерләткән ул паланкинны – җирдәге Алла шикелле, беркем якын килә алмаслык хакан үзе биләгән тәхетне һәм шул мескен корылма тирәли дала җилендә җилфердәгән, авызларыннан ут-ялкын ургытып торучы аждаһалар белән бизәп, нәкъ менә аның оста куллары укалап чиккән һораң-байракларны күреп өлгерде.

Зиннәтле чатыр астында җәелеп утырган Чыңгызханга әлеге калкулыктан барысы да яхшы күренеп тора – дала да, гаскәр дә, олаулардагы кешеләр дә, ә өстә, һәрвакыттагыча, аның баш очында ак болыт йөзеп йөри иде. Чигүчене җәзалап үтерү ул иртәдә юлга чыгуны тоткарлады. Әмма, алга таба барыр өчен, монысын да эшләү фарыз бит. Җәзалау вакыйгасы аның катнашуында булган җан кыюларның беренчесе түгел, билгеле, һәм соңгысы да булмас, – төрле-төрле очракларда аны тыңламаган бәндәләр нәкъ шул ысул белән юк ителде; хакан һичкайчан бөтен гавам алдында

Башы журналның 2016 елдагы 8 нче санында. Тәрҗемәче – **Мөдәррис Вәлиев**.

җәзалауның халыкны иң югары зат билгеләп куйган бердәм тәртипкә буйсындыру өчен хезмәт итүенә икеләнмәде, чөнки болай үтергәнне куркып һәм, бер үк вакытта, әле үзләренә кагылмаганга күрә, мескеннәрчә куанышып тамаша кылулары кешеләрне хак юлга – бу рәхимсезлекне тиешле чара дип кабул итү һәм шуңа күрә хакимиятнең мондый адымга баруын аклау гына түгел, яклау һәм хуплау юлына да бастыра.

Менә әле дә, чигүчене тирмәдән сөйрәп чыкканда һәм аны мәсхәрәле, нәфрәт тулы карашлар астында уздыру өчен арбага менәргә мәҗбүр иткән вакытта, кешеләр төркеме, шөпшә күчедәй гүләп, хәрәкәткә талпынып алды. Чыңгызханның чыраенда исә бер генә тамыры да тартышып куймады. Ул чатыр астында, җилфердәгән һоруңнар һәм байрак саплары янында таш бүкәннәр кебек катып калган кизүвыллар уртасында тыныч кына күзәтеп утыруын белде. Игълан ителгән җәзалап үтерү шуңа исәп тота да инде –һәркайсы белеп торачак: Кояш баешына таба бөек яу сәфәре барышында кечкенә генә комачаулык ясау да гафу ителми. Күңеленнән хакан аңлый: яшь хатыннан, анадан бу кадәр үк рәхимсез үч алуга бармаска, аны ярлыкарга да мөмкин иде, мәгәр анда мәгънә күрми, – һәртөрле киң күңелллелек күрсәтү һичкайчан яхшылык белән бетми, – хакимият көчсезләнә, кешеләр оятсызлана бара. Юк, ул бернигә дә үкенми, аңарда бердәнбер канәгатьсезлек тойгысы уяткан нәрсә – бу чигүченең сөяркәсе кем булганын шулай да ачыклап булмады бит.

Ә ул, асып үтерелергә хөкем ителгән хатын, күкрәк турысында күлмәге ертылган, чәчләре тузгыган хәлдә, инде арбада, саф-саф булып тезелгән гаскәр һәм олаулар каршыннан узып бара – иртәнге кояшта күмер кебек янып-ялтырап торган куе кара чәч учмалары аның каны качкан, нуры киткән йөзен яшерә. Шулай да Догулаң башын имәде, бушап калган күзләреннән тирә-ягына хәсрәтле карашын чәчеп бара, – хәзер аның бернидә дә гаме юк сыман. Әйе, аның сере ачылды: менә ул – гомереннән артык күреп яраткан ирне сөйгән хатын, әнә аның тыелган бәгырь җимеше – шул мәхәббәттән туган бала!

Әмма кешеләрнең кызыксынуы көчле, алар аны кычкыра-кычкыра озаталар:

– Бия, ә синең айгырың кайда соң? Кем ул?

Үз-үзләрен ярсытып һәм явызлана барып, бу адәми затлар өере, әлеге гаеп-гөнаһ аларга да ягыла күрмәсен, дигәндәй, төрле яктан ерткычларча кычкыра:

– Асарга кирәк зиначыны! Хәзер үк асарга! Сәфәр чыгасы бар. Нәрсә монда көтеп торырга?

Җәзаны оештырулар шуңа исәп тотканнар да иде: чигүченең рухын нәкъ менә шашынган халык төркеме ныграк изә, сындыра ала. Гаскәриләр арасыннан күзләре баканыкы кебек кабарып торган сыбайлы бер нойон, акырып-бакырып йөрергә оста булса кирәк, хакан каршында бу юлы да үзен күрсәтеп каласы килде бугай, аерылып чыкты да, бер чарасыз калган чигүче арбасы һәм аның белән янәшә кулында бала тоткан килеш атлап баручы хезмәтче хатын янына юртып килеп җитте.

– Йәле, җәмәгать! – Ул, барысын да туктатып, бигрәк тә рәт-рәт булып баскан атлыларга карап, каты итеп кычкырды: – Минем сүземә колак салыгыз! Бу оятны качкан фахишә кемнән бала тапканын күрсәтергә тиеш! Кем белән зина кылганын! Ә хәзер әйт, бу ир-атлар арасында синең балаңның атасы бармы?

Догулаң, юк, дип җавап бирде. Рәтләр буйлап ышанмыйча-сагаеп гүелдәү тавышы узып китте.

Арба сафтан сафка таба тәгәрәде, ә йөзбашлары, бер-берсен үртәп, үзара кычкырыша башлады:

– Миндә юк булып чыкты! Бәлки, ул айгыр синең йөз арасындадыр?

Ул арада күк күкрәгәндәй тавышка ия нойон чигүчедән, кабат-кабат, яңа туган баланың атасын төртеп күрсәтүен таләп итте. Менә арбаны чираттагы атлылар төркеме алдында туктаттылар һәм яңадан шул ук сорау:

– Күрсәт, уйнашчы, кайсысыннан таптың?

Нәкъ шул сафта, бу йөзнең башында, Эрдене үзенең кашкасы Акйолдызга атланып тора иде. Аның гаепле сыман карашы Догулаңныкы белән очрашты. Аларның күз карашларын нинди авырлык белән аеруына, шуны сиздермәс өчен, маңгаена төшеп чуалган чәчләрен артка ташлаганда, Догулаңның ничек тетрәнеп китүенә, бер мизгелгә йөзе кабынып һәм шунда ук сүнүенә гомуми ыгы-зыгыда берәү дә игътибар итмәде. Яшен тизлегендә күзләр белән бу күрешеп алу Догулаңга нинди куаныч һәм нинди әрнү алып килгәнен бары тик Эрдене генә белә иде. Күк күкрәгәндәй тавышлы нойонның соравына айнып киткән Догулаң, үз-үзен кулга алып, яңадан нык итеп җавап кайтарды:

– Юк монда минем баламның атасы, юк!

Йөзбашы Эрдененең шулчакта башын июенә дә янә беркем игътибар итмәде, тик ул үзен бик тиз кулга алды, йөзеннән генә ниндидер күләгә узды.

Ә җәлладлар инде әзер тора. Җиңе сызганулы киң озын кара халат кигән өчәве уртага ике өркәчле дөяне чыгарып маташа, ул шундый зур ки, иярдәге җайдакның аяк очы дөянең корсак уртасына гына җитә. Ачык далада урман-агач булмаганлыктан, күчмә кавемнәр борын-борыннан җәзаның шундый юлын сайлаганнар – үлемгә хөкем ителгәннәрне ике яктан пар итеп бер бауга бәйләгәннәр яки, ялгызын гына асарга туры килгәндә, буш ягын ком тутырылган капчык белән «тигезләгәннәр». Чигүче Догулаңга шундый капчык әзерләп куелган инде.

Акыра башлаган дөянең ярсуын өстенә кычкырып та, таяклар белән орып та көчхәл белән басып, җәлладлар аны тезләнергә һәм, эре сөякле озын аякларын астына җыеп, җиргә ятарга мәҗбүр иттеләр. Дар агачы әзер иде.

Барабаннар да җиңелчәрәк гөрселдәшеп уяна башладылар, алар, кирәкле мизгелдә дөпелдәп, колакларны тондырырга һәм күңелләрне урыныннан кузгатырга тиеш иде. Шулчакта күк күкрәгән тавышка ия нойон яңадан чигүчегә мөрәҗәгать итте, инде бу юлы кызык табар өчен генә булса кирәк.

– Соңгы тапкыр сорыйм. Сиңа, тавык миле сөйрәлчеккә, барыбер дөмегәсе һәм синең токымсыз эт баласына да яшәү юк! Шулай да сине ничек аңларга соң, чынлап та кемнән йөккә узганыңны белмисеңме? Бәлки, бераз көчәнеп карарсың да исеңә төшерерсең, ә?

– Кемнән икәнлеген хәтерләмим. Ул күптән һәм моннан бик еракта булган иде, – дип җавап кайтарды чигүче.

Дала өстен тупас ир-ат хахылдавы һәм зәһәр хатын-кыз чинашуы тетрәтте.

Нойон һаман бәйләнүен белде:

– Ничек аңларга, – кайдадыр базарда ясатып кайттың булып чыгамы әллә?

– Әйе, базарда! – дип, үчекләп җаваплады Догулаң.

– Сәүдәгәр яки илгизәр идеме? Бәлки, базар карагыдыр?

– Хәтерләмим, сәүдәгәрме яки илгизәр булдымы, әллә базар карагымы, – дип кабатлады Догулаң.

Тамашага җыелган халык бу юлы да рәхәтләнеп хахылдашты һәм чинашты.

– Ә аңа нинди аермасы бар, сәүдәгәр булды ни дә, илгизәр яисә бур булды ни, иң мөһиме – бу эш белән базарда шөгыльләнү!

Һәм шулчак, көтмәгәндә, сугышчылар арасында кемнеңдер тавышы яңгырады. Бер ир-ат көчле һәм каты итеп кычкырды:

– Бу мин – баланың атасы! Әйе, беләсегез килсә, бу мин!

Һәм барысы да берьюлы тынып, катып калдылар – кем булды соң бу? Ахыр минутта, чигүче чишмәгән серен үзе белән мәңгелеккә алып китә, дип торганда, үлем авызына кем кереп бара?

Һәм, барысын да шаккаттырып, үзенең кашка атын биетеп, рәтләр арасыннан йөзбашы Эрдене алга чыкты. Һәм, Акйолдызны туктаган урынында тотып, өзәңгесенә баскан көе, халык төркеменә борылды да яңадан кычкырып кабатлады:

– Әйе, бу мин – баланың атасы! Бу – минем улым! Улымның исеме – Кунан! Улымның анасы – Догулаң! Ә мин – йөзбашы Эрдене!

Шул сүзләр белән ул бөтен халыкның күз алдында атыннан сикереп төште дә Акйолдызның муенына кизәнеп шапылдатты, тегесе куркудан сикереп китте, ә йөзбашы үзе барган шәпкә коралларын салып, аларны төрле якка ыргытты, үзе исә инде кулыннан җәлладлар эләктереп алган чигүчегә таба атлады. Әле генә хахылдашкан, чинашкан кавем дәшми-тынмый карап торды: барысы да үз иреге белән үлемгә каршы барган кешене күрде. Җәзага әзер торган сөйгәне янына килеп җиткәч, йөзбашы Эрдене аның алдында тезләнде һәм аякларыннан кочып алды, ә хатын, иркәләп, аның башыннан сыйпады, алар үлем каршында, шулай янә бергә кушылып, тын калдылар.

Шул минутта ук добулбаслар телгә килде, кинәт нәрсәгәдер тынычлыгын җуйган үгез көтүе кебек буыла-буыла үкереп, дәррәү дөбердәргә кереште. Бу – халык-чирүнең, үз-үзен белештермичә, хакан ихтыярын үтәп, шашынып канга сусауларын белдерү авазы иде. Һәм барысы берьюлы исләренә килде, һәрнәрсә кабат үз урынына кайтты, һәркайсына хәрәкәткә, юлга чыгарга әзер булып торырга, дигән боерык яңгырады. Барабан-хакимнең әмере бер: барчасына да башкалар кебек булырга, һәммәсе дә берсүзсез буйсынырга һәм үз бурычын үтәргә тиеш! Ә җәлладлар, тәҗрибәле мал чалучылар кебек, кичекмәстән эшкә кереште. Җәлладларга ярдәмгә тагын өч ясавыл ташланды. Алар йөзбашын җиргә егып, тиз генә аның кулларын аркасына каерып бәйләделәр, чигүчене дә шулай богаулап салгач, икесен бергә җирдә яткан дөягә тартып китерделәр, икесенә уртак бау ташладылар, аның бер элмәген йөзбашына, икенчесен, дөянең өркәчләре арасыннан уздырып, чигүченең нәфис муенына кигезделәр һәм, бик ашыгып, барабаннарның тынып тормаган шавы астында, дөяне аягына бастырырга керештеләр. Малкай, инде бу юлы ипләп кенә яткан җиреннән торасы килмичә, өстенә нинди гөнаһ аласын аңлагандай, үҗәтләнеп, каршылык күрсәтте, ул ямьсез итеп акыра, ачулы шакылдаткан тешләре белән берәрсен эләктереп алырга маташа иде. Әмма сыртына таяклар төшә башлагач, бөтен зур гәүдәсе белән торып басарга туры килде. Бер-берсен кабергәчә яраткан ике зат – үлем алдыннан да бер бауга бәйләп куелган пар корбанның җансыз гәүдәләре өркәчләрнең ике тарафыннан асылынып калды.

Барабан ыгы-зыгысында хаканның чатырлы алтын тәхетен калкулыктан алып киткәннәрен күбесе сизмәде, ахрысы. Хәер, хакан үзе дә җәза мәрәкәсе үтәлгән җирдә юк иде инде, аңа күргән кадәресе бик җиткән; куелган бөек максатка ирешелде, хәтта көткәннән дә артык булды – чигүче белән йоклауны Дөньяның Дүрт Тарафы Әмиренә йөгенүдән өстен күргән теге билгесез ир-ат барыбер табылды, ул аның йөзбашларыннан берсе икән ләбаса, канун бозучының канга сусаган кешеләр көтүе күз алдында фаш булуы һәм шунда ук тиешле җәзасын алуы да шәп бит, бәлки, әнә күптәнге, заманында аның дошман коллыгына төшкән Бортэсен куенында иркәләп, аннары гомере буена хакан күңеле белән үзенеке итә алмаган беренче баласының атасы булуы ихтимал, ул чакта да, соңыннан да кем икәнлеге беленми калган теге адәм актыгы өчен үч алу түгелме икән әле бу бәхетсез корбан...

Дәвамы бар ■

Безнең мирас №2 февраль 2017

ГЫЙБРӘТЛЕ ХИКӘЯТЛӘР

АЛТЫНГА КЫЗЫКСАҢ...

Имам Газали (рәхмәтуллаһи галәйһи) «Ихйа[1]» исемле китабында әйтте:

Бер кеше Аллаһу Тәгаләне бер һәм бар дип белеп гыйбадәт кылучы иде. Бер каумнең бер агачка гыйбадәт кылганын ишетеп, бик ачуланып, кулына балта алып, бу агачны кисеп екмакчы булып, өеннән чыкты.

Юлда барганда, адәм сурәтендә булып, Иблис юлыкты. Бу кешедән сорады:

– Кая барасың? – диде.

Бу кеше аның Иблис икәнен белмичә әйтте:

– Фәлән җирдә бер каум бер агачка гыйбадәт кыла икән. Шуңа ачуым килеп, шул агачны кисәргә барамын, – диде. Шәйтан әйтте:

– Хата итәсең, әгәр ул агачны киссәң, алар икенче бер агачка гыйбадәт кыла башларлар, файда итә алмассың. Кайт син, гыйбадәтеңдә бул, кеше өчен кайгырма, тиз картаерсың, – диде. Бу кеше:

– Юк, калдырмам, – дигәч, шәйтан бу кеше белән сугыша башлады. Бу кеше дә шәйтанны бик яхшы гына суккалап, җиргә екты.

Шәйтан әйтте:

– Син бер фәкыйрь кеше, ул агачны кисмә, өеңә кайт, гыйбадәт кыл. Мин сиңа һәр көн баш астыңа ике алтын тәңкә куярмын, син бу фәкыйрьлектән котылырсың, һәр көн ике алтын тәңкә кулыңа кергәч, файда итәрсең, әлбәттә, бай булырсың. Әгәр Аллаһу Тәгалә ул каумне иманга кертәсе булса, пәйгамбәр җибәреп, ул агачны кистереп, бу каумне иманга өндәтер иде. Син үзең шул агачка гыйбадәт кылмагач, һичнәрсә юк, – диде.

Бу кеше, Иблиснең сүзенә ышанып, ике алтын тәңкәгә кызыгып, өенә кайтып китте. Иртә торса, баш астында ике алтын тәңкә тапты, янә бик шатланды һәм әйтте:

[1] Ихйа – «Ихйау гулүми-д-дин» – Әбү Хәмид әл-Газалинең (1111нче елда вафат) дини-фәлсәфи әсәре: «Дин турындагы гыйлемнәрне тергезү».

– Менә бу агачны киссәм, бер тиен акчасыз, арып-талып кына кайткан булыр идем. Хәзер һәр көн ике алтынны алу өметендә торам. Кайвакытта шәйтан сүзен тотсаң да ярый икән, – дип уйлап утырды.

Янә кич булып, ятып йоклады. Иртән торса – баш астында алтын юк. Хатыны иртәрәк торган иде. Хатыныннан:

– Алтынны син алдыңмы? – дип сорады. Хатыны:

– Алганым юк, – дигәч, ышанмыйча, хатынын бик рәнҗетте. Янә бик ачуы килеп, үзен-үзе сүгеп:

– Шәйтанга ышанып, җәмәгатеңне сүгеп йөрисең, – дип, балтаны кулына алып, янә агачны кисәргә китте.

Янә юлда Иблис очрап, бу кешегә бәйләнеп:

– Барма, китермәм! – дип, бу кеше белән сугыша башладылар. Шәйтан бу кешене җиргә екты. Бу кеше әйтте:

– Минем сиңа әүвәл ничек көчем җиткән икән? – диде. Шәйтан әйтте:

– Син әүвәл вакытта Аллаһу Тәгалә ризалыгы өчен ул агачны кисәргә чыккан идең, инде хәзер алтын бирмәгән өчен кисәргә барасың. Шуның өчен, ягъни Аллаһу Тәгалә ризалыгы өчен булмаганга көчең җитми, – диде.

Бу хикәяттән беленде: Аллаһу Тәгалә ризалыгы өчен бер эшне эшләмәкче булсаң, шәйтанның туктатырга көче җитми. Әгәр дә Хода ризасы өчен булмаса, шәйтанның ул эшне бозуы вә булдырмавы бик ихтимал.

НӘЗЕР

Әүвәл заманда бер кеше нәзер әйткән икән:

– Әгәр Аллаһу Тәгалә миңа мал бирсә, фәкыйрьләргә сәдака бирер идем, – дип. Бу кешегә Аллаһу Тәгаләнең әмере белән бер кеше бер алтын тәңкә бирде.

Бу нәзер әйтүче кеше бу бер алтын тәңкәне алгач, күңеленнән уйлады:

– Бу акчага бервакыт мохтаҗ булырмын, фәкыйрьләргә бирмим әле, – дип, җыеп куйды.

Бераз көннәр үткәннән соң, бу кешенең теше сызлый башлады, көч-хәл белән түзеп йөрде дә ахырда, түзә алмагач, тешен алдырды. Бу тешен алдыргач, янә икенче теше сызлый башлады, янә бу тешен дә алдырды.

Шул арада бер тавыш ишетелде:

– Әгәр теге алтынны фәкыйрьләргә бирмәсәң, бер тешеңне калдырмый суыртып бетерербез, – диде.

Бу кеше әлеге тавышны ишеткәч, кылган эшенә тәүбә итеп, алтын тәңкәне фәкыйрьләргә сәдака итеп биреп бетерде.

Инде бу кыйссадан беленде: нәзер иткән нәрсә фәкыйрьләр хакы була, ә ул фәкыйрьләр хакын бирмәсәң, малыңа, яки малың булмаса, тәнеңә зарар ирешә икән. Һәм шуның кебек зәкәт вә гошер тиеш булып, бирмәгән кешенең дә малына яки тәненә зарар ирешер.

КЕШЕГӘ ЧОКЫР КАЗЫСАҢ...

Әүвәл заманда бер падишаһ бер вәзирен бик сөядер иде. Бер кеше падишаһның аны бик сөюен белеп, падишаһтан бу вәзирне ераклаштырмакчы булды. Янына килеп әйтте:

– Синең фәлән вәзирең: «Падишаһның авызы сасы икән», – дип әйтә, – диде. Падишаһ әйтте:

– Сүзеңнең раслыгын кайдан белербез? – диде. Бу кеше әйтте:

– Ул вәзир, синең яныңа килеп, сөйли башлагач, кулын авызына куяр, – диде.

Падишаһ вәзирне чакырды. Бу кеше шул сәгатьтә вәзирне өенә чакырып, кунак итеп, күп сарымсак салынган аш ашатты.

Вәзир бу кешедән чыккач, падишаһ катына барды. Падишаһ алдында сөйли башлагач, вәзир, «сарымсак исе падишаһка таба бармасын», дип, кулын авызына куйды.

Падишаһ вәзирнең кулын авызына куйганын күргәч, «теге кешенең сүзе раст икән», дип, каләм алып хат язды. Падишаһның гадәте шул иде: әгәр үз кулы белән хат язса, ул хат бүләк бирү өчен була иде.

Бу кеше падишаһның хат язганын күргәч, «вәзиргә бүләк бирә», дип белде. Падишаһ вәзиргә:

– Хатны фәлән вәлигә[2] илтеп бир! – дип боерды.

Бу кеше, «бүләкне мин алырмын», дип уйлап, вәзирдән сорады:

– Син мәшәкатьләнеп йөрмә, хатны үзем илтеп бирим, – диде. Вәзир каршы килмәде, хатны бирде, теге кеше падишаһ боерган вәлигә илтеп тапшырды.

Бу вәли тиз генә хатны укып, падишаһ боерганча, бу кешенең башын кистерде...

Көннәрдән беркөнне бу вәзир падишаһ янына килеп керде. Падишаһ хәйран булып, вәзирдән сорады:

– Син теге хатны илтеп бирдеңме? – диде. Вәзир:

– Юк, ул хатны миннән фәлән кеше сорап алды, – диде. Падишаһ әйтте:

– Син мине сасы авызлы дип сөйләдеңме? – диде. Вәзир:

– Һич сөйләгәнем юк, – диде. Падишаһ:

– Ни өчен минем белән сөйләшкәндә авызыңа кулыңны куеп тордың? – диде. Вәзир әйтте:

– Ул кеше миңа, синең катыңа барганда туктатып, сарымсаклы тәгам ашаткан иде, шул сарымсак исе сиңа бармасын, дип, авызыма кулымны куеп тордым, – дигәч, падишаһ әйтте:

– Хәер, үзе казыган базына үзе төшкән икән, – диде.

ТӘКЪВА[3] КЫЗ

Һинд аучыларыннан бер кеше балык тотарга диңгез буена барды. Үзе белән бергә бер кызын балыкны җыеп торырга дип алып килгән иде.

Бу кеше ятьмәсен салып балык алгач, ул балыкларны кызына бирә торды. Ә кызы алган бер балыкны кире диңгезгә җибәрә иде.

Кайчан бу кеше балык тотудан туктагач, балык савытын караса – бер балык та тапмады. Кызыннан сорады:

– Бу тоткан балыклар кайда? – дигәч, кызы җавап бирде:

– Әй, атам! Син миңа Расүл әкрамнан[4] ишеткән хәдисеңне әйткән идең: «Балыклар Аллаһу Тәгаләнең зикереннән гафил булмаса, ауга кермәс, мәгәр Аллаһу Тәгаләнең зикереннән гафил булган балык кына ауга керер», – дигән идең. Мин шуның өчен, ягъни Аллаһу Тәгаләнең зикереннән гафил булган балыкны ашыйсым килмәгәне өчен, диңгезгә җибәрдем, – диде. Атасы да: «Бәрәкалла!», – дип, буш кул белән кайтып киттеләр. Шулвакыттан соң бу кеше балык аулаудан туктады.

КИРЕБЕТКӘН КӘФЕРЛӘР

Разый[5] исемле галим сөйләде:

Кыйбтыйлар[6] халкы фиргаун[7] кауменнән булып, Муса галәйһиссәламгә иман

---

[2] Вәли – шәһәр башлыгы.
[3] Тәкъва – үтә динле, Алладан куркучы.
[4] Расүл әкрам – Мөхәммәд пәйгамбәр. Әкрам – хөрмәтле.
[5] Зикер – Аллаһны телгә алу, исемнәрен кабатлау.
[6]Разый – Фәхреддин әр-Разый (1209да вафат), тәфсирче галим, фәйләсуф.
[7] Кыйбтыйлар – Мисырның борынгы җирле халкы.
[8] Фиргаун – фиргавен.

китермәделәр. Муса галәйһиссәлам ничә вә ничә могҗизалар китерсә дә: «Сихерче син, сихер белән безне ышандырмаучы буласың» – диделәр. Муса галәйһиссәлам болар иманга өндәүне кабул итмәгәч, бу каумгә газап теләп, дога кылды. Аллаһу Тәбарәкә вә Тәгалә бу кыйбтыйларга газап итеп туфан җибәрде. Ул туфан кичә вә көндез бертуктаусыз булып һәм кояш яктылыгын каплап, һичнәрсә күренмәс булды.

Бу хәлне вә бу куркынычларны күргәч, кыйбтыйлар фиргауннән үтенделәр. Фиргаун Муса галәйһиссәламнән үтенде һәм әйтте:

– Әй, Муса! Раббыңа дога кыл, бу газапны бездән күтәрсен, – диде.

Муса галәйһиссәлам Аллаһу Тәбарәкә вә Тәгаләгә дога кылды. Аллаһу Тәгалә Муса галәйһиссәламнең догасын кабул итеп, туфан вә яңгырны туктатты да җил җибәрде. Җирдән бик тиз арада куе үләннәр үстерде. Үләннәр җиргә сыймаслык рәвештә үсте.

Бу кыйбтыйлар Аллаһу Тәгаләнең бу нигъмәтенә рәхмәтле булмыйча, сабырсызлык кылдылар. Аллаһу Тәгалә, көферлекләрендә калганнары өчен, чикерткәләр җибәреп, ул үләннәрне ашатып бетерде. Ул чикерткәләр кыйбтыйларга бик тарлык вә уңайсызлык китерделәр. Ул чикерткәләр очкан вакытта кояшны каплыйлар иде, шулкадәр күп иделәр.

Бу катылыктан зарланып, Муса галәйһиссәламнән ярдәм сорадылар. Муса галәйһиссәлам Аллаһу Тәгаләгә дога кылды, Аллаһу Тәгалә Муса галәйһиссәламнең догасын кабул итеп, ул чикерткәләргә җил җибәреп, барысын да диңгезгә ташлады.

Кыйбтыйлар, янә дә «калган игеннәребез ашарга җитәр», дип, Муса галәйһиссәламгә итәгать кылмыйча, кәфер булдылар. Аллаһу Тәгалә бу кыйбтыйларга янә дә газап итеп «камел[9]» исемендә бернәрсә җибәрде. Кайберәүләр аларны канатсыз чикерткә диделәр, кайсылары борча, бет, диделәр. Бу бетләр кыйбтыйларның хайваннарына бер үлән дә калдырмый ашап бетерделәр, тәннәренә кереп, ашап, корчаңгы кебек итеп бетерделәр.

Болар янә дә Муса галәйһиссәламнән ярдәм сорадылар. Муса галәйһиссәлам Аллаһу Тәгаләгә дога кылды, Аллаһу Тәгалә догасын кабул итеп, ул бетләргә эссе җил җибәреп һәлак кылды.

Бу кыйбтыйларны Муса галәйһиссәлам янә иманга өндәсә дә, кабул кылмадылар, көферләрендә калдылар. Аллаһу Тәгалә бу кыйбтыйларга газап итеп бакалар җибәрде, ул бакалар кыйбтыйларның игеннәренә һәм ашларына вә түшәкләренә дә керделәр, боларга бик тарлык китерделәр.

Янә Муса галәйһиссәламнән ярдәм сорадылар. Муса галәйһиссәлам Аллаһу Тәгаләгә дога кылды, Аллаһу Тәгалә догасын кабул итеп, бакаларны үтерделәр, яңгыр биреп, ул бакаларны шул яңгыр суы белән диңгезгә агызды.

Бу кыйбтыйлар янә дә Муса галәйһиссәламгә иман китермичә, көферләрендә калдылар. Аллаһу Тәгалә бу кыйбтыйларга газап итеп, кан җибәрде. Бу кан эчә торган суларына вә тәгамьнәренә катышты. Кайберәүләр әйттеләр: «Бу кыйбтыйларның Аллаһу Тәгалә борыннарын каный торган итте» – дип. Шул бәла белән җиде көн бәлаләнделәр, кан эчәләр вә кан белән ашый иделәр.

Бу кыйбтыйлар Муса галәйһиссәламгә килеп үтенделәр:

«Әй, Муса! Әгәр бу бәлане бездән алсаң, әлбәттә, сиңа иман китерербез, – диделәр. Муса галәйһиссәлам Аллаһу Тәгаләгә дога кылып, газапны бетерсә дә, иман китермәделәр. Аллаһу Тәгалә бу кыйбтыйларны фиргаун белән Нил диңгезендә батырып һәлак кылды.

Текстны кульязмадан басмага ***Нәҗип Нәккаш-Исмәгыйль*** *әзерләде.* ■

[9] Камел – бет.

Безнең мирас №2 февраль 2017

Әмирхан Еники: «Бу инде Мәһдинең талантын инкарь итү белән бер булачак...»

Рүзәл Мөхәммәтша

«Безнең мирас» журналына тугры һәм хәтере нык укучының исендәдер: 2015 елның 12 санында Әгъзам Фәйзрахмановның «Мөхәммәт Мәһдиев: «Егет булыйк әле бер...» исемле мәкаләсе басылып чыкты. Артык тирәнгә кермичә, шуны гына искәртәм – Мөхәммәт Мәһдиев Язучылар берлегенә юллаган хатында 1984 елгы Тукай премиясенә кандидат буларак Әмирхан Еникине тәкъдим итә. «Башка идарә членнарының, әгәр аларның берсенең кандидатурасын параллель рәвештә күрсәтсәләр, самоотвод биреп, Ә.Еники кандидатурасын ялгыз калдыруларын үтенәм». Ул чакта Мөхәммәт аганың бу гамәленә редакция белән сокландык.

Әмирхан Еникинең дә шундый ук эчтәлекле, әмма бу юлы М.Мәһдиевнең үзен яклап язган хаты бардыр, күпмедер вакыттан анысы да табылыр, дип, кем башына китерсен! Кульъязмалар янмыйдыр, валлаһи... Машинкада җыелса да. Имзасы «тере» бит!

Еники хаты ТАССРның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе буенча комитет әгъзаларының азаккы фикеренә тәэсир ясаганга охшый. Комитетның 1990 елгы эшчәнлеген ачып салган документлар арасында Әмирхан ага фикерен кабатлаган урысча текст бар. Кулдан язылган бу кәгазь битләре берәр чыгышның яисә утырыш беркетмәсенең караламасы булырга мөмкин.

Ихтимал, кемдер, «очраклылык», дияр, ләкин ассызыкламый кала алмыйм: Әмирхан Еники бу мәртәбәле бүләкне Мөхәммәт Мәһдиев Язучылар берлегенә хат язган 1984 елда, ә Мөхәммәт Мәһдиев – Әмирхан Еники комитет әгъзаларына язган 1990 елда ала.

Тукай әйтмешли, ярар, хуш. Урамда җөмһүриятебезгә бәйсезлек китерәсе (һәрхәлдә, Декларациядә шулай язылган) 1990 ел тантана итә дип күз алдына китерик. Комитет утырышында Татарстан АССРның (әлегә автономияле!) Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә кандидатлар карала. Алар арасында язучы-шагыйрьләр Мөхәммәт Мәһдиев, Ибраһим Сәлахов, Рәшит Әхмәтҗан, Роберт Миңнуллин, композиторлар Алмаз Монасыйпов һәм Сара Садыйкова бар.

Инде Әмирхан Еникинең үзенә сүз бирик:



Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе комитеты әгъзаларына

Мөхәммәт Мәһдиев Язучылар союзы тарафыннан Тукай премиясенә өченче тапкыр тәкъдим ителде. Димәк, Мәһдинең соңгы тапкыр куелуы, башка инде аны тәкъдим итеп булмаячак. Шуңа күрә бу юлы аңа премия бирү-бирмәү мәсьәләсен аеруча бер җаваплылык белән карау кирәктер дип беләм.

Өченче тапкыр тәкъдим ителгән әсәрләренә тукталып тормыйм, алар һәммәсе дә киң таралган, яратып укылган әсәрләр. Үзләренең художество дәрәҗәләре белән моңарчы Тукай премиясе алган әсәрләрдән һич тә ким түгелләр, дөресен генә әйткәндә, кайберләреннән өстен дә торалар. Ә авыл хәлләрен, авыл кешеләренең катлаулы язмышларын бик нечкә тоеп, белеп, борчылып язылулары белән безнең әдәбиятта күренекле аерым урын тоталар – шик юк ки, киләчәктә дә ул әсәрләрнең әһәмияте һәм кыйммәте төшмәячәк, киресенчә, арта гына барачак.

Әмма шуңа да карамастан, моңарчы ике тапкыр инде аларның премиядән мәхрүм ителүләре күңелдә ирексездән зур борчу тудыра. Әгәр бу юлы да мәхрүм ителсәләр, бу инде Мәһдинең талантын, бөтен иҗатын һәм бүгенге актив эшчәнлеген инкарь итү белән бер булачак. Һәм мондый гаделсезлек әдипнең җанына һич төзәлмәс тирән яра салачак.

Шуңа күрә мин комитет әгъзаларыннан бик үтенәм: М.Мәһдигә Тукай премиясен бирү мәсьәләсен һәртөрле конъюктура законнарыннан, исәпләреннән өстен торып, бары тик гаделлек принцибыннан чыгып карасагыз иде. Минем бу үтенечем комитет утырышында укылыр һәм игътибарсыз калмас дип ихластан ышанасым килә.

Әмирхан Енеки,
Татарстан халык язучысы

17.03.90. Әмирхан Еники

Әмирхан Еники хаты. 1990 ел



11–12 февраля списки кандидатов были опубликованы на страницах республиканских газет, переданы по республиканскому телевидению и радиовещанию.

В условиях демократизации общества и гласности вышеотмеченные кандидатуры стали предметом широкого обсуждения так на страницах печати, ~~передачах~~ радио и телевидения, так и среди населения республики.

Наиболее яркие по содержанию публикаций и письма поступили по творчеству писателя Мухамата Магдеева. В адрес Комитета поступило от общественности 17 писем, всех их читать думается не надо, но на одном из них хотел бы остановиться. Так, народный писатель Амирхан Еники обратился в Комитет по Госпремиям следующими словами ~~письмом~~:

Зачитывает –

Известный, смелый, народный писатель в своем обращении говорит о том, что для Магдеева, талантливого прозаика это уже последняя попытка стать лауреатом премии им. Г. Тукая, т.к. он уже ~~ставится~~ предлагается третий раз. Он подчеркивает, что Магдеев ~~популярный, любимый~~ Татарстана [illegible] писатель, [illegible] народом [illegible] и необходимо признать его талант. Если и в этот раз его кандидатура не пройдет, то [illegible] это было бы несправедливость и просит не допустить такую несправедливость по отношению к нему.

Язма авторы Әмирхан Еникинең хатын искә ала. 1990 ел

Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе комитеты әгъзаларына

Мөхәммәт Мәһдиев Язучылар союзы тарафыннан Тукай премиясенә өченче тапкыр тәкъдим ителде. Димәк, Мәһдинең соңгы тапкыр куелуы, башка инде аны тәкъдим итеп булмаячак. Шуңа күрә бу юлы аңа премия бирү-бирмәү мәсьәләсен аеруча бер җаваплылык белән карау кирәктер дип беләм.

Өченче тапкыр тәкъдим ителгән әсәрләренә тукталып тормыйм, алар һәммәсе дә киң таралган, яратып укылган әсәрләр. Үзләренең художество дәрәҗәләре белән моңарчы Тукай премиясе алган әсәрләрдән һич тә ким түгелләр, дөресен генә әйткәндә, кайберләреннән өстен дә торалар. Ә авыл хәлләрен, авыл кешеләренең катлаулы язмышларын бик нечкә тоеп, белеп, борчылып язылулары белән безнең әдәбиятта күренекле аерым урын тоталар – шик юк ки, киләчәктә дә ул әсәрләрнең әһәмияте һәм кыйммәте төшмәячәк, киресенчә, арта гына барачак.

Әмма шуңа да карамастан, моңарчы ике тапкыр инде аларның премиядән мәхрүм ителүләре күңелдә ирексездән зур борчу тудыра. Әгәр бу юлы да мәхрүм ителсәләр, бу инде Мәһдинең талантын, бөтен иҗатын һәм бүгенге актив эшчәнлеген инкарь итү белән бер булачак. Һәм мондый гаделсезлек әдипнең җанына һич төзәлмәс тирән яра салачак.

Шуңа күрә мин комитет әгъзаларыннан бик үтенәм: М.Мәһдигә Тукай премиясен бирү мәсьәләсен һәртөрле конъюктура законнарыннан, исәпләреннән өстен торып, бары тик гаделлек принцибыннан чыгып карасагыз иде. Минем үтенечем комитет утырышында укылыр һәм игътибарсыз калмас дип ихластан ышанасым килә.

Әмирхан Еники,
Татарстанның халык язучысы
17.03.90

ДӘРДЕМӘНД
(1859-1921)

Дәрдемәнд (Мөхәммәтзакир Мөхәммәтсадыйк улы Рәмиев), Октябрь түнтәрелешеннән соң бар байлыгын Совет хакимиятенә тапшырып, соңгы көннәрен ачлыкта-мохтаҗлыкта кичерә, дигән фараз яши. Бу турыда үз вакытында Рабит Батулла болай дип язган иде: «Элекке хезмәтчесе йортында яшәгән Дәрдемәнд көннән-көн ачыга, корый башлый һәм 1921 елда атаклы шагыйрь, алтын тауларының хуҗасы – бөек Дәрдемәнд ачтан җан тарта. Кышкы зәмһәрир суыкта Дәрдемәнднең җәсәден нибары ике кеше каберстанга алып китә: ызба хуҗасы белән аның кызы. Дәрдемәнднең җеназасын чыптага төреп чанага салалар, чананы хәлсез кыз тарта, арттан ата кеше атлый. Ач бичаралар Дәрдемәнднең гәүдәсен көч-хәл белән генә гүргә иңдерәләр, карт кабер якасында җеназа укый».

Ләкин шагыйрьнең тормыш юлын җентекләп өйрәнгән Лерон Хәмидуллинның бу турыда фикере башка. Ул язганча, Оренбург большевиклар тарафыннан яулангач, Закир һәм аның җәмәгате Мәхүбҗамал Рәмиевләр 1918 елның февраль азагында Орск шәһәренә күченә. Башта туганнары йортында гомер кичерәләр, соңрак, 1920 елдан, аерым йортка чыгалар. Биредә Дәрдемәнд, нигездә, алтын базларын «яңа хуҗалар»га тапшыру мәшәкатьләре белән мәшгуль була. Бу чорда шигырьләр язганмы ул? Билгесез. Кайбер әдәбият белгечләре Дәрдемәнднең пессимизм

белән сугарылган әсәрләрен шушы чорга нисбәтләп карый. Ләкин моны дәлилләүче кульязмаларның табылганы юк.

Бай китапханәсе, архивы һәм шәхси әсбапларының байтагы Оренбургта калганлыктан, шагыйрь ике арада еш йөри. Ул вакытта әлеге шәһәрләр тимер юл белән тоташмаган була әле. Ватандашлар сугышы заманында мосафирлар әүвәл олауга утырып 140 чакрым ераклыктагы Актүбәгә (бүген бу шәһәрчек – Казакъстанның район үзәге), аннары поездда 300 чакрым узып, Оренбургка җитәләр.

1919 елдагы коточкыч сугышлардан соң Оренбург губернасында тиф һәм ваба (холера) чирләре тарала. 1921 елда тиф Дәрдемәнднең өлкән кызын – Өммегөлсемне аяктан ега һәм озакламый бакыйлыкка алып китә. Шагыйрь кызы белән бәхилләшергә, бер уңайдан, ятим калган дүрт оныгының (кияве Гариф Камалов та вафат була) язмышын хәл итәргә Оренбургка килә.

Кара кайгы, авыр юл газаплары, көзге салкыннар Дәрдемәнднең сәламәтлеген яхшы ук какшата һәм Орскига кайтып бер атна вакыт үтүгә – 1921 елның 9 октябрендә шагыйрь җан тәслим кыла. Тифтан түгелме икән, дигән шик бар.

Закир Рәмиев-Дәрдемәндне калкулыкта урнашкан һәм шәһәрнең затлы нәселләре генә күмелгән Ильяс утары зиратында җирлиләр. (Иңкүлектә урнашкан башка зиратларны Урал елгасы ташып су астында калдыра торган була.)

1930 елда Ильяс авылы урынында яңа шәһәр күтәрелә башлый, «Юж-Уралмаш» машина төзү, «Никель» төсле металл эретү, «Крекинг» нефть эшкәртү заводлары корыла. 1941 елда СССРның көнбатышыннан эвакуацияләнгән заводларның берсе Ильяс утарының киң-иркен зираты өстенә салына.

Сугыштан соңгы елларда Дәрдемәнднең кабер ташы исән була әле, кабер үзе завод кырыенда кала. Ләкин соңрак завод киңәя, кабер ташлары, күрәсең, төзелеш эшләренә тотыла. Бөек шагыйрьнең җәсәде бетон астында калып, күз уңыннан (әмма халык хәтереннән түгел!) мәңгелеккә җуела.

«Безнең мирас» журналында (№11, 2015 ел) басылган «Бәрәкәтле Оренбург» туфрагы мәкаләсендә Лирон Хәмидуллин болай дип яза: *«Житмешенче еллар җиткәч* (узган гасыр, билгеле – Р.М.), *Равил Бохараев ачлык чорында* (1921 елда) *Дәрдемәнд гаиләсенә бирелгән азык-төлек купоннарын алып кайтып, Татарстан Дәүләт музеена тапшыра. Ул заманда Закир белән Мәхүбҗамал, Искәндәр белән Шәрифзадә* (шагыйрьнең улы белән килене – Р.М.), *Оренбургтан вакытлыча китеп тору сәбәпле, әлеге «карточкалар»ны тота алмаганнар. Алар киткәч тә, төп йортта калган дүрт кешелек Вәлиевләр гаиләсенә* (Закир Рәмиевнең кызы Зәйнәп, кияве Ярулла һәм аларның балалары – Р.М.) *бу купоннарны куллану, шәһәрдән китеп торучылар исеменнән ризык юнәтү мөмкин дә булмагандыр. Дөресрәге, килешмәгәндер. Шуңа күрә алар тотылмыйча Зәйнәп апаның кәгазьләре арасында илле ел чамасы тик яткан да инде.* <...> *Ул «ачлык купоннары» музейга эләкте һәм соңрак «Дәрдемәнд ачтан үлгән» дигән уйдырма хәбәр таралуга сәбәпче булды».*

***Рүзәл Мөхәммәтша** әзерләде.* ■

Әдәбият:

1. Батулла. Тузга язмаган хәлләр: Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1997. – Б.106.
2. Хамидуллин Л.Х. / Дэрдмэнд. Лирон Хамидуллин; пер. с татарского Б.Хамидуллина. – Казань: Татарское кн. изд-во, 2010. – С.46-48.
3. Лирон Хәмидуллин. Бәрәкәтле Оренбург туфрагы. – Безнең мирас. – №11, 2015. – Б.78-79.

Безнең мирас №2 февраль 2017

ДӨРЕСЛЕК – ИҢ БӨЕК КӨЧ

Сезнең игътибарга тәкъдим ителгән бу «Утлы кисәү» дигән язма авторы турында кайбер фикерләрем белән уртаклашыйм әле.

Безнең Мөслим районында табигатьнең искиткеч матур урынында урнашкан Түреш исемле кечкенә авыл бар. Аны күпләр мәшһүр артист Наил Әюпов, шагыйрь Харрас Әюпов, балалар шагыйре Мөҗәһит Әхмәтҗанов һәм прозаик, шагыйрь, драматург Ләбиб Леронның туган авылы буларак белә.

Бу истәлек-язманың авторы Лерон Гыйльфанов – Ләбиб Леронның әтисе. Ул гомере буе Түреш авылында яшәп, иншаллаһ, быел 83 яшен тутыра.

Лерон Гыйльфанов 1957 елдан алып тракторчы булып эшләде. Авылның дилбегәсе элек механизаторлар кулында иде, хәзер дә ул шулай. Тракторчылар колхоз-совхоз басуларын эшкәртте, игеннәр чәчте, уңышны җыйнап алуда катнашты, кара көздән иртә язга кадәр азык-төлек, төзелеш материаллары, ягулык ташыды, авыл хуҗалыгы машиналарын ремонтлады, басуларга черемә чыгарды, кар тотты. Әле бит халыкның шәхси бакчаларын сөрү, кешеләргә агач материаллары, утын ташу кебек мең төрле мәшәкатьләр дә алар өстендә иде. Тракторлар саны аз булган-

Уңнан сулга: Лерон Гыйльфанов, Фоат Садриев, Мөҗәһит Әхмәтҗанов, Ләбиб Лерон. 13 август, 2006 ел

лыктан, тракторчыларга алны-ялны белмичә эшләргә туры килде. Лерон Гыйльфанов исеме 60 нчы елларда район газетасы битләрендә мактап телгә алына иде инде. Соңрак үзем шул газета хезмәткәре булып эшли башлагач, Лерон абый белән ныклабрак кызыксына башладым. Аның турында берәр очерк язасым килеп йөрдем.

Иң элек ул игътибарымны үзенең тынгысыз рухы, җитешсезлекләрне кыю тәнкыйтьләве белән җәлеп итте. Л.Гыйльфановның кайнар чыгышларын үзләренең колхоз җыелышларында да, район күләмендә уздырылган чараларда да тыңларга туры килде миңа. Туфрак эшкәртүне, гомумән, игенчелек технологиясен бозучы механизаторларга да, хуҗалык эшләрендә ялгышлар җибәргән җитәкчеләргә дә нык эләгә иде Лерон абыйдан. Кимчелекләрне төзәтү буенча конкрет тәкъдимнәре дә күп булды аның. Тәҗрибәле механизатор авыл тормышының һәрбер өлкәсен үзенекедәй якын күреп кайгыртучы хуҗа буларак яшәде. Аның белән кызыксынган саен, мин бу фикергә ныграк инана бардым. Ул чорларда Лерон абый биш-алты авылны берләштергән колхоз җирлегендә иң күп газета-журнал алдыручы, аларны җентекләп укып баручыларның берсе булган. Тормышка актив мөнәсәбәт, яңалыкка омтылу, коллектив мәнфәгатьләрен алга куеп фикерләү юктан гына тумый шул.

«Лерон Гыйльфанов җиргә әнисенә караган кебек кадерләп карый», – диде миңа колхоз җитәкчеләре. Әгәр тракторы ватылса, ул төн йокысын йокламаса йокламаган, әмма техникасын ремонтлап, иртән эшкә чыгарлык хәлгә китермичә күңеле тынычланмаган.

Мөҗәһит Әхмәтҗанов бер елны аның прицепщигы булып эшләп алган. «Төнге сменамы, көндезгесеме – озаклап ял итү юк иде, – дип сөйли ул. – Ашарга туктасак, Лерон абыйның букчасында сөт, ипи, йомырка, берәр төрле яшелчә була. Капкалап аз генә ял итәбез дә кабат сөрергә тотынабыз».

Күршеләре, авылдашлары аның искиткеч ярдәмчеллеген, карусызлыгын бүген дә рәхмәт хисләре белән телгә ала.

Без, аерылмас дусларга әверелеп, үткән тормышыбыз, авыл язмышы турында озаклап сөйләшсәк тә, аның турында очерк язарга дигән ниятемне тормышка ашыра алмадым. Ләкин тракторчыны баш герой итеп алган ике повесть («Шаһзаманов эше», «Көлми торган кеше»), бер зур хикәя («Авыш басу икмәге») һәм «Иртәгә нидер булачак» дигән драма яздым. Ул геройларда Лерон Гыйльфановның күп кенә сыйфатлары чагыла, әлбәттә.

Лерон абый социалистик системаның яшәүчәнлегенә, киләчәктә зур уңышларга ирешәчәгенә инанган иде. Ул үзен шул уңышларны тизләтергә тиешле кеше, гаделлек өчен көрәшче, тормышның хуҗасы итеп тойды. СССРны таркатып, океан кебек гаять зур илебезнең җир өсте һәм җир асты байлыкларын ул байлыкларда бернинди дәхеле булмаган затларның эләктереп алуларын, колхоз-совхозларның, авылларның таркатылуын ул шәхси фаҗигасе рәвешендә кабул итте. Бүген дә бәгыре телгәләнүдән тынычлана алмый. «Өч ел буе Түреш басуына иген чәчмәделәр, – дип өзгәләнә ул. – Ата-бабаларыбыздан, әнкәйләрдән оят миңа! Аларның рухы алдында кызарып яшим. Без бит мохтаҗлык хәттин ашкан елларда да мондый хәлгә төшмәдек. Басудан кайтмасак кайтмадык, эшкәртүен дә эшкәрттек, чәчүен дә чәчтек, югалтмыйча җыйнап та алдык».

Менә шушы кичерешләр Лерон Гыйльфановны каләмгә тотынырга мәҗбүр иткәндер дә инде. Ул гомере буе дөреслеккә табынды, ялганны күрә алмады. Аның язмаларында авыл тормышының үткән чорлардагы кырыс дөреслеге чагыла. Ә дөреслек – меңнәрчә тонна асылташтан, алтын-көмештән дә кыйммәтрәк бөек көч ул. Шул көч яшәгәндә генә җәмгыять алга атлый ала.

Фоат Садриев,

Татарстанның халык язучысы.

Мөслим

УТЛЫ КИСӘҮ

Лерон Гыйльфанов

(Истәлекләр, уйланулар)

Балачактан алып бүгенгәчә янып бетмәгән «утлы кисәүләр»не гел болгатып, хәрәкәттә тотыйк әле.

Монда язылганнар бар да дөрес булыр. Мин алдакчыларны, кеше үтерүчеләрне, кеше байлыгын талаучыларны, эчкечеләрне яратмыйм.

НӘСЕЛ ҖЕПЛӘРЕМ ТУРЫНДА БЕРНИЧӘ СҮЗ

Гыйльфан бабам: ул – Актаныш районының Олы Имән авылыннан. Бабам үткән гасырның Беренче Бөтендөнья сугышында үлә. Әбием Зөләйха исемле, тумышы белән Мөслим районының Бүләк авылыннан.

Бабам белән әбиемнең биш баласы була.

Әти – Хөҗҗәт исемле, ул 12 яшендә әтисез кала.

Аның бер энесе Мирзанур, Ватан сугышында булып, аннан исән-сау кайта. Чиләбе-Урал якларында яшәве мәгълүм. Аралар өзек.

Әтинең тагын бер энесе Гыйльметдин сугышта булган, яраланган, снаряд кыйпылчыгы тын юлына тигән иде. Ул Украинада өйләнеп, шунда калган. Алардан бернинди хәбәр юк.

Әтинең янә бер энесе (исемен хәтерләмим) була. Әни әйтә иде: сугыш башланган көнне – 22 июньдә Ташкентта үлгән.

Әтинең бер генә сеңлесе була. Ул Мөслим районының Исәнсеф авылында кияүдә булып, балалары туа, бер кызы Казан шәһәре янындагы кайсыдыр бистәдә яши.

МИНЕМ ИСЕМЕМ КАЯН ТАБЫЛГАН?

Әни кечкенә чагында Алабугада балалар йортында яшәгән. Шунда яшәгәндә (елын белмим) бер җитәкчедә бала караган. Лерон исемле булган ул бала. Әни аны бик яраткан. Әгәр кияүгә чыгып малаем булса, аңа шушы исемне кушар идем, дигән. Үсеп җиткәч, Ижау якларына барып чыга. Ул чорда Пермь, Ижау яклары безнең күп халыкны үзенә тарта.

Минем әти 1905 елгы иде. Аның артыннан да «утлы кисәү» калмаган. Әти шулай ук Ижау ягына юл тоткан. Менә шунда әти белән әни таныша, гаилә кора. Анда күпме яшәгәннәрдер, әйтә алмыйм, кире Олы Имән авылына кайталар.

Әти бик оста гармунчы булган. «Сабантуйларда бер иптәше белән бөтен мәйданны тота иде», – дип, әни мәрхүмә бик еш искә ала иде. Без дүрт бала идек: ике малай, ике кыз. 1936 елгы сеңлем Фәния өч яшендә чакта башына кызу сугып үлде. Ә төпчек энекәш Васыйф 1943 елда нининдер чирдән якты дөньядан китте.

Әти бик башлы кеше булган. Авыл җирендә нинди техника бар – һәммәсен яхшы итеп ремонтлаган. Шуңа да аны шул чорда ук контракт белән авылдан авылга йөрткәннәр.

ӘТИ ЭШЛӘГӘН АВЫЛЛАР

Башта Татар Бүләр авылына киләләр. Менә шунда мин – «утлы кисәү» – Лерон дөньяга килгәнмен.

Аннан соң булган авыллар – Яңа Сәет (шагыйрь Зөлфәт туган авыл), Минзәлә районының Иске Иркәнәш авылы, Ык елгасы буенда урнашкан бер авыл (Билитский

Лерон Гыйльфановның ялкынланып нотык тоткан чагы

диебрәк исемдә калган, Минзәлә районындагы Бикбау-Бикбулат авылы булмадымы икән?!), Пучыдан биш километр ераклыктагы Чәчер авылы.

Күпмедер вакыттан кабат Олы Имәнгә кайттык. Анда Зөләйха әбиләрдә тордык. Әти Пучыда (Олы Имән-Пучы арасы – 15 чакрым) МТСта эшләде.

Олы Имәндә торганда бер үлеп терелдем. Ул чагында өйгә, мунчага ягарга утын юк. Салам, тирестән сугылган «кирпеч» (кизәк) ягалар иде. Бервакыт мунчага баргач, башыма ис тиеп, аңымны югалтканмын. Мине, шәрә килеш, «утсыз» алып кайтканнар. Ничек терелеп кеше булганмындыр, белсә, аны бер Аллаһы Тәгалә генә беләдер...

МИН НИЧЕК ТҮРЕШ КЕШЕСЕ БУЛГАНМЫН?

Әтине яңадан Олы Имәннән Яңа Сәеткә алып китәләр. Әти анда эшләү срогы чыкканчы эшли. Зур канкойгыч сугыш башланырга ун көн кала – 1941 елның 12 июнендә безне Яңа Сәеттән Түрешкә Мөҗәһитнең этисе белән аның бертуганы – колхоз председателе алып килә. Түрештә безне Әхмәтҗан бабай яшәгән йортка яшәргә керттеләр. Без Шәрип абый гаиләсе белән бергә яшәдек. Бик тату булдык. Шәрип абыйны ныклап бер генә күргәнем хәтердә. Бу 1942 елның җәй ае иде булса кирәк. Сугышка киткәндә, ул канауга ятып бик озак елады.

«Утлы кисәү»нең әле алда ныклабрак янасы булган.

Әни әйтүенчә, эти Түрешне бик яраткан. Яңадан күченеп йөрмәбез инде, шушында төпләнербез, дия торган булган.

1941 елда беренче класска укырга кердем. Минем балачак дустым берәү генә иде. Ул – Васил Әхмәтҗанов. Аның белән җиденче классны бетергәнче бер парта артында утырдык. Бик башлы, музыка коралларында (гармун, балалайка һ.б.) бик шәп уйный иде, соңыннан көйләр дә яза башлады. Аның өстенә бик матур итеп портретлар ясый иде. Сәләтле кешенең бер ягы җитеп бетми: Василның сәламәтлеге 100% түгел иде. Вакыт булганда, үзебезчә уйнап та ала идек. Башлангычта безне авылдашыбыз Мөзәянә апа һәм Мәллә Тамактан Гөлсинә апа укытты. Мәктәптә Тимерханның әнисе Сәхибкамал җыештыручы булып эшләде.

Менә җәйләр, көзләр үтеп, кышка да кердек. Авылдан шактый кешеләр сугышка китте. 1942 ел безнең өчен җиңелдән башланмады. Әткәйне 2 мартта комиссия үтәргә чакырдылар. Күп тә үтмәде, сугышка китәргә повестка килде.

Әткәй китәр алдыннан авылдагы бар техниканы ремонтлап бетерә. Аннан соң район җитәкчелеге әткәйне Кырынтау авылына җибәрә. Ул анда да бар нәрсәне ремонтлап кайта.

Гыйльмегали (шагыйрь Харрас Әюповның әтисе – уңда) белән Ислам (шагыйрь Мөҗәһит Әхмәтҗановның әнисе ягыннан бабасы)

Шулай итеп, әткәй 1942 елның 7 мартында сугышка китте. Аны ат белән авылыбыз егете Хәбибулла абый алып китте. Ә без берни белми капка төбендә озатып калдык. Хәзер уйлыйм: нигә фермага – Өске урман ягына хәтле озатып бармаска инде?! Сеңлекәш (Флүрә) тәрәзә төбенә басып карап калды.

И-и, гомер... Алда «утның» тагын да ныклап янар көннәре көтә иде.

Безнең Түреш авылы бар яклап урман эчендә утыра иде. Авылдан өч километр ераклыкта каланча корылып куелган иде. Башлангычта укыганда, һәр ел «Тәпәк» чокырына барып, шуннан кузгалак, сарыбаш ашап кайта идек. Анда баргач, әлеге 25 метр биеклектәге корылмага менеп, ике-өч тапкыр авылны караганым хәтердә калган. И самими, күңелле балачак...

Авыл, шулай итеп, ил белән бергә үз көнен төрле газаплар белән үткәрә килде. Түрешкә председатель итеп Иске Карамалыдан чибәр генә, карасу йөзле, 18 яшьләр тирәсендәге кызны куйдылар (исеме истә калмаган). Ул бик кешелекле, булсынга эшли торган булды.

Ул вакытта Түреш авылы «Игенче» колхозы дип атала иде. Мәхмүт абыйлар планында председатель атын, пожарный атларын тоттылар. Шушы торак өстендәге калайга «Игенче» дип язылган иде. Әлеге язу ерактан күренеп торды.

Армиядән кайткач, менә шул атларны Хәкимәнең әтисе Гыйльмегали абый бик яхшы итеп карады. Биредән ерак түгел колхоз кәнсәсе, клуб, 2 бригада атлары бар иде. Башта 70-80 баш ат булды. Яхшы атларны армиягә ала тордылар.Тарту көчләре кимегәннән-кими барды. 1942 елның җәеннән 7-8 яшьлек балаларга да эшкә нәрәт (наряд) белән әйтә иделәр. Май аеның унбишләреннән әниләр белән көн дә эштә булдык. Икмәк чыккач, чүп утый идек. Печән өсте вакытында атлар белән чүмәлә китердек. Урак өстендә өч сезон – 1942-1944 елларда ашлык сукканда өч малай – Гыйлемҗан, Рифкать һәм мин барабан атларын кудык. Барабанга көлтәне Кәбир бабай бирә иде. Атлар хәлсез, көне буена алар белән без дә бик арый идек. Аннан соңгы елларда, үсә төшкәч, Гыйлемҗан һәм башкалар белән әниләр урган көлтәләрне суктырырга ындыр табагына ташыдык. Үгез ат түгел инде, кызу чакта тамагы кипсә, тыңламыйча, буага су эчәргә кереп китәр иде. Гыйлемҗанның үгезе буага көлтәле килеш кереп китте. Мин җиккәне зур гәүдәле, Маймыч исемле иде. Берчакны Күбәк ягына барганда,

Рәсемдә: уң якта – Лерон Гыйльфановның әнисе Хәмдия. 1954 ел

Маймыч куе чикләвек агачлыгына кереп китте, белмим, ничек чыгылгандыр. Аннан соң 8-9 класста укыганда да миндә шул үгез иде. Рифкать, Мизхәт абыйның энесе, Гыйльмиямал апа – өч үгез белән Карамалы «глубинка»сына хөкүмәткә сентябрь башына хәтле илттек. Берсендә үгез күбенде, күп вакытлар куып йөрттек – терелде.

Болар бар да дөрес: болар – ут күмерендә янып бетмәгән хатирәләр.

ӘТИ ТУРЫНДА ЯНӘ БЕРНИЧӘ ХАТИРӘ

Әни, сугышта машиналар аз булган бит, дип әйтә иде. Тәгәрмәчле пушкаларны атлар белән сөйрәп йөрткәннәр, әти шундый частьта булган. Атларның аякларын дагалаганнар. Әти язган: бервакыт кул сугышы булып, 3 немецны үтердем, дип. Яраланып, бер айлап госпитальдә булган, яңадан алгы сызыкка җибәргәннәр. Әти хатларын бик еш язган. Мин бәләкәй чакта хәтердә иде. Ул хатлар яңадан кая китеп беткәннәрдер, белмим.

Әни әйтә иде: әтидән хат килү 1943 елның җәй уртасында туктаган. Василлар янында торган чакта чын-ялган күрәзәчеләр йөри иде. Алар, әтиең кайта, дип әйтә иде. Юк шул – ялганлап әйткәннәр. Шуңа да беренче дошманым – ялганчы. Ялганчылыктан янып бетмәгән кисәү калдыгы хәзер дә йөрәк түрендә.

Авылда, яшьләре зур булып, сугышка бармаучылар – Шәйгәрдән, Әбелфатих бабайлар. Мөҗәһитнең бабасы, аның белән бертуган – Мирзасалих, Мирхаҗиян, Миркасыйм бабайлар. Чишмә очы Хәйдәр бабай, Габделхак, Кәбир, Закир бабайлар бар иде. Бу чорда алар авылның иң авыр хезмәтен башкарды. Бу фидакяр бабайлар белән бергә хатын-кызлар һәм яшь буын егет-кызлар теләсә нинди эштә эшләп, җиңүгә үзләренең күркәм өлешләрен кертте.

Бер хатирә истә калган.

Ялгышмасам, июнь ае иде. Тәпәктән печән өеп кайтуга, урам як койма җимерелгән, тәрәзәләр ватылган иде. Бу күренеш бозлы, көчле җил-яңгыр аркасында булган. Тәпәктә бозлар булмаган иде. Боз, дигәннән, тагын 1960-1970 еллар арасында ферма ягындагы өске урман буенда 180 гектар өлгереп килгән бодай басуын боз сугып китте. Бер гектарын да суктырып ала алмадылар. Ә авылда яңгыр гына булды. Мин ДТ-54 тракторы белән Күбәк ягы басуында эштә идем, яуганда туктап тордым.

Дәвамы бар ■

САРА САДЫЙКОВА

Рәфкать Кәрами

Татарстан Язучылар берлегенең Матур әдәбиятны пропагандалау бюросында эшләгән чорда миңа әдәбият-сәнгать әһелләренең күбесе белән бәйләнешкә керергә туры килде. Чөнки очрашуларга әдипләрне генә түгел, композиторлар, музыкантлар, нәфис сүз осталары һәм җырчыларны да чакыра идек. Күпчелек очракта бу заявка бирүчеләрнең теләген искә алып эшләнә иде. Шуңа күрә алар бик шатланып «Казан язы», «Туган тел бәйрәме» кебек әдәби-музыкаль кичәләрдә чыгыш ясады.

Сара апа Садыйкованы да чакыргаладым. Олы яшьтә булуына карамастан, ул ризалаша иде.

Бервакыт мин аны кайсыдыр заводның тулай торагына дәштем. Очрашу кичке якта буласы иде. Сара апаны өе янында, урамда, каршы алдым. Әкрен генә тукталышка барып, сигезенче трамвайга утырдык.

Барабыз. Сара апага сирәк-мирәк күз салам. Аны танып белмәгән кеше (хәер, андыйлар Казанда булдымы икән?) уйлагандыр: менә бәләкәй генә бер карчык, башын иеп, үзалдына нидер уйланып бара. Кая бара икән ул? Кемгә бара икән? Мөгаен, балалары янынадыр, аерым яшәүче оныкларын күреп кайтасы килгәндер. Кыскасы, күп гомер кичергән, шактый дөнья нужасы татыган бер әби, трамвайга кушылып, җай гына тирбәлеп бара. Үзем аңа карыйм һәм, ничектер, үземә үк уңайсыз булып китә. Өлкән кешене борчыйсым калмаган икән. Атап чакырганнар иде шул.

Тукай исемендәге кинотеатр яныннан кузгалып киткән трамвай шактый озак барды. Кирәкле тукталышта төшеп, тулай торакка юнәлдек. Кызлар аны ишек төбендә үк каршы алдылар. «Сара апа, Сара апа», – дип өтәләнеп торалар, куанычлары эчләренә сыймый. Тәрбияче бүлмәсендә алдан ук чәй дә хәстәрләгәннәр иде.

...Безне залга дәштеләр. Иң алдан, өстенә озын алсу ефәк күлмәк, аягына биек үкчәле туфли кигән, башына укалы калфагын кыңгыр салган Сара апа атлый. Ул залга килеп керү белән, кызларегетләр дәррәү кул чаба башлады. Сара апаның йөзе яктырып китте, аяк атлавы ныгыды, ул, яшьләргә карый-карый, башын ия-ия аларны сәламләп, сәхнәгә таба бара. Бу инде бөтенләй икенче кеше иде. Йөгереп үк булмаса да, җитез генә, минем сузылган кулыма таяныр-таянмас кына сәхнәгә менде ул. Ә инде бераздан, тәрбияче аның чыгышын игълан итеп, зал янә гөр килеп кул чаба башлагач, мин бөтенләй хәйран калдым: Сара апаны алыштырып куйдылармыни!

Чү, мин сәхнәдә кемне күрәм?! Бу соң трамвайда йокымсырап килгән, өлкән яшьтәге теге «әбиме», әллә дәрте ташып торган берәр яшь артисткамы?! Сәхнәдә – урта яшьләрдәге, сылу гәүдәле, чибәр артистка иде. Бу – актриса. Бөтен гомерен сәхнәдә үткәргән, сәхнәгә багышлаган, башаягы белән сәхнә тормышына чумган актриса иде: йөзеннән елмаю китми, көләч, нурлы. Сәхнә стихиясе аны үз агымына бөтереп алып кереп китте! Пианино артына утырып, нәзек көчле бармакларын җитез хәрәкәтләндереп уйнаган көйгә, калфаклы башын кыңгыр салып, җырлап та җибәргәч, зал тын калды һәм әллә ни зур булмаган кызыл почмакны тутырып, аның моңлы, әле дә чисталыгын югалтмаган югары аһәңле тавышы яңгырады. Чыгышы тәмам булганчы, ул үзенең актриса икәнен онытмады...

Чәйләр эчеп, тукталышка хәтле озата килгән кызлар белән саубуллашып, трамвайга утыргач, янә мин бәләкәй генә

гәүдәле, мөлаем кыяфәтле, күңелебезгә якын татар әбисен күрдем. Ләкин аның рух күтәренкелеге сүрелмәгән, тамашачы белән очрашудан алган тәэссораты әле бетмәгән иде. Ул аның кулындагы роза чәчәкләренә баккан күзләрендә, алсуланып киткән илһамлы йөзендә чагыла иде...

Артист һәм тамашачы.

Җырчы һәм тыңлаучы.

Композитор һәм халык.

Алар арасында була торган фикер берлеге, үзара аңлашуның гаять әһәмиятле, кирәкле әйбер икәнен мин шунда аңладым. Менә ни өчен сәхнәдән иртә киткән артистлар тиз картаялар да, гомерләренең соңгы көннәренә кадәр сәхнәне ташламаганнары озак яшиләр, халкыннан аерылмаган иҗат әһелләре үзләренең иҗади эшчәнлекләрен ахыргача саклап калалар икән.

Сара Садыйкова – йөзләгән җырлар авторы. Хәтта җыр текстларының да соавторы, дияр идем мин аны. Ул озак еллар Язучылар союзының партия оешмасында исәптә торды. Безнең һәр җыелышка килә, теге яки бу шагыйрьнең иҗатын тикшергәндә (ә андый тикшерүләр элек еш була иде) Сара апа ялкынланып чыгыш ясый, дөрләп-кабынып бәхәсләшә, үзенең төпле киңәшләрен бирә: ул шигъриятне тирәнтен аңлый иде. Алың бөтен гомере иҗатка, фәкать иҗатка гына багышланган иде, дисәм, һич хата булмастыр. Әүвәл – җырчы, аннары – композитор. Хәер, болар гомере буена икесе бергә үрелеп барды шикелле. Моң чишмәсе соңгы көннәренә хәтле кайнап, ургып торды Сара апаның, ул чишмәне ком күмеп китмәде.

Кайбер сәләтле генә кызларыбыз, матур-матур шигырьләр язып, бер-ике китап чыгаралар да сүреләләр, пыскып кына яналар һәм... бөтенләй сүнәләр. Андыйлар композиторлар арасында да юк түгелдер. Әйе, кем әйтмешли, сәнгать – корбаннар таләп итә. Фәкать көн саен, сәгать саен барлык көчеңне туплап, төн йокыларыңны җәлләмичә, зур җаваплылык тоеп, бөтен күңелеңне ихластан иҗатка бирсәң генә чын мәгънәсендә иҗади әсәрләр туарга мөмкин, күрәсең. Әйе, бу шулай.

Әлбәттә, Сара Садыйкова кебек «асылташ»лар (бу сүзне хәзер курыкмыйча әйтик) сирәк табыла.

Шулай да, дөнья мәшәкатьләренә чумып, аның вак-төягенә бөтен игътибарыңны юнәлтеп, яки шандәрәҗә артыннан куып, төп эшеңә айда – бер, кайда – бер генә кул тидерәсең икән, иҗат моны өнәми. Ул синең бөтен вөҗүдеңне биләп алырга тиеш. Ул синең көндәлек эшең булырга тиеш. Фәкать шулай яшәсәң генә – син чын иҗатчы, әдәбият-сәнгать дигән олы җиһанның тугрылыклы колы. Тик, билгеле тәгълиматтагыча, сәнгать – сәнгать өчен түгел, сәнгать – халык өчен булырга, ул аңа хезмәт итәргә тиеш. Үзең үлгәч тә иҗатың кала бит, халыкка хезмәткә... Еллар узган саен синең кемлегең ачыла бара. Үзе исән чакта дан-шөһрәт казанганнарның да еллар үтү белән бәһасе сукыр бер тиен дә тормаска мөмкин, ә дөньялыкта эт типкесендә йөргән кайберәүләрнең иҗаты, яңа бер күтәрелеш кичереп, тегеләрнекеннән бер баш өстен калкып, халык күңелен яулап алуы ихтимал.

Сара Садыйкова иҗаты һәм тормышы әле үзендә бик күп серләр саклыйдыр. Мин бары аның бер генә мизгелен, үзем күргән ягын, тамашачы алдында ничек әсәрләнеп китүен һәм аны ничек кабул итүләрен, аңа булган мөнәсәбәтне генә әйтеп бирергә тырыштым.

Редакциядән: *Күренекле прозаик РӘФКАТЬ КӘРАМИгә 18 февральдә 75 яшь тула. Аны гомер бәйрәме белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек һәм иҗат уңышлары теләп калабыз.* ■

Галимә Ибраһимова. 1940 нчы еллар

Табигатьнең сәхнәгә бүләге

Әлфия Минһаҗева,
Мамадыш шәһәре беренче гомуми урта белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Галимә Ибраһимова 1909 елда Мамадыш өязенең Түбән Шүләнгер авылында туа. Шунда үсә, шунда зифа буйлы үсмер кыз булып җитешә. Билгеле, кайчан да булса артисткага әверелермен, ил-көнемнең ихтирамын казанырмын, дигән уй башына да килми. Ләкин, күп вакыттагыча, монда да очраклы бер вакыйга аның язмышын көтелмәгән якка борып җибәрә.

Ул елны чикләвек бик уңа. Галимә иптәш кызлары белән җәй буе Түбән Шүләнгер урманнарында әвәрә килә. Озакламый, көзләр узып, йорт эшләре җиңеләйгәч, җыйган чикләвеген сатып аз-маз акча юнәтер, бер уңайдан театр техникумында укучы Мәрьям апасын да күреп кайтыр, дип аны Казанга җибәрәләр. Кызый шәһәргә исән-сау килеп җитә, кирәкле тулай торакны эзләп таба һәм шунда айдан артык кунак булып ята: апасына ияреп репетицияләргә йөри, татар театрында барган спектакльләрне карый. Шулай йөри торгач бервакыт аны актер, режиссер Зәйни Солтан күреп ала. Мәшһүр артист чикләвек сатарга килгән авыл кызының ике якка үреп салган калын чәч толымнарына, тал чыбыктай буй-сынына сокланып карап тора да:

– Мәрьям, бу сеңелең – табигатьнең сәхнәгә дигән бүләге ләбаса! Син аны артистка ит, – ди.

Шул вакыйгадан соң күпмедер вакыт узгач, Галимә Казан театр техникумында укый башлый. Техникумны тәмамлауга, аны Мәскәү эшче театрына җибәрәләр. 1929 елда әлеге театр белән ул Урал, Себер якларында гастрольләрдә йөреп кайта. Татар һәм урыс драматургларының әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә катнаша, төрлесе төрле характердагы байтак рольләр башкара. Иптәшләре яшь кызның сәләтен күрәләр, киләчәктә аңардан яхшы артист чыгар дип өметләнәләр, укуын дәвам итәргә киңәш бирәләр. Аларның сүзен тыңлап, ул Мәскәү Үзәк театр сәнгате техникумына (шул замандагы югары уку йорты) укырга керә. Биредә күренекле профессорларның лекцияләрен тыңлый, атаклы педагоглардан дәресләр ала, башкала театрларында күрсәтелгән спектакльләргә йөри.

Мәскәүдә югары белем алгач, Галимә Ибраһимова яңадан Казанга кайта. Аның шуннан соңгы бөтен иҗат гомере Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә үтә. Ул бик күп образлар иҗат итә. Билгеле, аларның барысына да тукталу, һәркайсына бәя бирү мөмкин түгел. Шулай да, аеруча характерлы образларның кайберләрен искә төшереп үтәсе килә.

Галимә Ибраһимова – асылда лирик табигатьле артистка. Яшь һәм сөйкемле булуын искә алып, күрәсең, режиссерлар аңа күбрәк кызлар яки яшь хатыннар ролен бирәләр. Артистканың иҗат йөзе дә нәкь әнә шундый образларда тулырак ачыла.

Фридрих Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт» трагедиясендәге Луиза – Галимә Ибраһимованың академия театры сәхнәсендә башкарган беренче роле. Дөнья драматургиясенең иң гүзәл казанышыннан саналган әсәр каһарманын тәҗрибәсез актриса никадәр тулы-төгәл гәүдәләндерә алгандыр, ул турыда хәзер фикер йөртү шактый кыен. Табигый матурлыгы һәм яшьлеге бу эшне җиңел башкарып чыгарга ярдәм иткән, күрәсең. Җәмәгатьчелек Галимәнең беренче уенын җылы каршылый. Әлеге уеннан соң аның һәр чыгышын алкышлар белән каршылау гадәткә керә. Шул елларда театрда труппа мөдире булып эшләгән Мәрьям апа Чанышеваның: «Бик күпләр театрга Галимә өчен генә килә иде. Бүген уйнамаса, ичмасам, сәхнәгә генә чыгарып бастырыгыз, дип ялваручыларның исәбе-саны булмый торган иде», – дип сөйләгәне булды.

«Мәкер һәм мәхәббәт»тән соң театр Уильям Шекспирның «Отелло» трагедиясен әзерли башлый. Отелло ролен мәшһүр трагик Мохтар Мутинга, Дездемонаны Галимә Ибраһимовага бирәләр. М.Мутинның кайнар табигатьле, гаярь артист булуы мәгълүм. Үзенә тапшырылган рольләрне ул шулкадәр мавыгып, бирелеп уйный ки, еш кына хәтта «уенчы» икәнлеген онытып та җибәргәли. Табигый, аның Отеллосы да ифрат кызу канлы, дуамал һәм куркыныч кеше була. Мондый партнер белән уйнау җиңелләрдән түгел. Кан баскан бәбәкле, куркыныч кыяфәтле Отелло-Мохтарны күрүгә Дездемона-Галимә

«Отелло» спектакленнән күренеш. Камал III, Галимә Ибраһимова. 1953 ел

«Күзге ачы җилләрдә» спектакленнән күренеш. Хөсәен Уразиков, Галимә Ибраһимова. 1960 нчы еллар

калтырап төшә, чытырдап күзләрен йома, сүзләрен әйтә алмый җәфалана.

Гомумән, актриса күңеленә Мохтар Мутин ифрат таләпчән, туры сүзле һәм принципиаль сәнгатькяр булып кереп калган. Шулай бервакыт «Отелло» спектакленнән өзек рәвешендә берничә фото төшереп алырга ниятлиләр. Галимәгә дә килергә, киенеп-әзерләнеп торырга кушыла. Кушканнар икән, килми чараң юк. Вәләкин М.Мутин кызны бик коры тота:

– Бар әле, сеңелем, буталып йөрмә. Сара Бернар булгач минем янда төшәрсең, – ди.

Аның бу сүзләрендә тәҗрибәсез артистканы санга сукмау, кимсетүдән бигрәк, аны Сара Бернар дәрәҗәсендәге атаклы партнер итеп күрәсе килү теләге көчлерәк кебек.

Театрда Отеллолар алмашына тора, ә Дездемона һаман Ибраһимовада кала. Мутиннан соң Отеллоны Шакир Шамильский уйный башлый. Аның Отеллосы уйлап эш итәргә ярата, салмаграк та, басынкырак та була. Бусыннан инде Галимә дә артык курыкмый, үзен иркенрәк тота, образны тирәнрәк, тулырак ачуга ирешә. Дездемона белән Луизадан тыш, ул Виктор Гюгоның «Анджело» драмасындагы Катарина, Уильям Шекспирның «Король Лир» трагедиясендәге Корделия, Александр Островскийның «Яшенле яңгыр» драмасындагы Катерина, төрек язучысы Назыйм Хикмәтнең «Мәхәббәт хикәясе»ндәге Ширин рольләрен башкара. Артистка тудырган бу образларның һәркайсы турында озаклап сөйләргә мөмкин булыр иде. Шунысына гына басым ясыйсы килә: Галимә Ибраһимованың артистлык осталыгы спектакльдән спектакльгә үсә бара, ул үзе башкарган һәр рольнең үзенчәлекле якларын тотып алырга өйрәнә, сәхнәдә тулы канлы, тормышчан образлар тудыру югарылыгына күтәрелә.

Галимә Ибраһимова иҗат иткән

образлар арасында үзебезнең татар драматургиясе каһарманнары да байтак очрый. Нәкый Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» комедиясендәге Сәлви образы – шуларның иң характерлысы. Муса Җәлилнең әлеге спектакль турында язып калдырган рецензиясендә мондый юллар бар: *«Рольләрне аеруча матур башкаручылардан Аксак Тимер ролендәге Гайнуллинны, Сәлви ролендәге Г.Ибраһимованы күрсәтергә була. Бу иптәшләрнең уеннарында җанлы характер, образ тудырырга тырышу – уенны спектакльнең эчтәлеге белән органик бәйләп, тигез алып бару, һәр хәрәкәтне һәм сүзне җентекләп эшләү күзгә бәреләэ»*. Каһарман-шагыйребезнең фикерләренә өстәп, шуны әйтергә мөмкин: Сәлви ролен Галимә Ибраһимова озак еллар уйный, аны һаман баета, тирәнәйтә тора. Комедия татар халкының яраткан спектакленә әйләнеп, дистә еллар дәвамында берөзлексез уйналып килгән икән, монда, башкалар белән бергә, һичшиксез, Галимә Ибраһимованың да өлеше зур.

Сәхнә әсәре – коллектив иҗат. Театрда эшләүчеләр бер җан, бер кан булып укмашканда гына спектакль уңыш казанырга мөмкин. Шулай да, спектакльнең төп «хуҗасы» – режиссер. Рольләргә артистларны ул сайлый, әсәрнең ничек сәхнәләштерелүе беренче чиратта аңа бәйле. Режиссер артистның иҗат мөмкинлекләрен яхшы белсә, аны мавыктыра, канатландыра алса, бу артистка да, режиссерга да куаныч-шатлык кына китерә. Галимә Ибраһимовага ул яктан да бәхет елмая. Татар дәүләт академия театрында аңа тәҗрибәле, игътибарлы сәнгать ияләре белән берлектә эшләргә насыйп була. Артистканың иҗади үсешенә аеруча күп көч куйган шундый затларның берсе – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Габдулла ага Йосыпов. Нинди рольләрдә, нинди спектакльләрдә генә сынап карамый ул аны! Илле яше тулып килгән көннәрдә Кәрим Тинчуринның «Беренче чәчәкләр» драмасындагы Сара исемле яшь кыз ролен бирә. Роле яхшы

«Әни килде» спектакленнән күренеш.
Галимә Ибраһимова, Айдар Хафиз. 1970 ел

да... ләкин, ни генә димә, яшь бара бит – Галимә Ибраһимова олыгаеп килә. Шул ук вакытта режиссерның гаҗәеп сөйкемле бу артистканы сәхнәдән читләштерәсе дә килми. Нишләргә? «Димәк, актрисаны олы яшьтәге хатыннар роленә кертергә вакыт җиткән», – дигән нәтиҗәгә килә ул.

Күп кенә талантлы артисткалар үзгә амплуага күчә алмыйча гаҗиз булалар, кайвакыт унар ел буе сәхнәдә күренмиләр яисә бөтенләй сәхнәне ташлыйлар. Мостай Кәримнең «Кыз урлау» комедиясен куйганда, Г.Йосыпов Г.Ибраһимовага урта яшьтәге тол хатын ролен тапшыра. Аю төсле салмак хәрәкәтле Дәүләтбай (артист Гали Надрюков) янында Галимәнең Туктабикәсе бик яшь күренә. Ләкин режиссер барыбер максатыннан чигенми, аны Аяз Гыйләҗев язган «Көзге ачы җилләрдә» драмасындагы Ак түти ролендә сынап карарга уйлый. Башта артистка үзенә бирелгән роль белән килешми. Репетицияләр киеренке шартларда

Безнең мирас №2 февраль 2017

уза. Мамыктан сырмалар тегеп киеп карый, әмма йөреше, үз-үзен тотышы, сөйләшүе белән һаман да яшь кыз булып кала. Авызын уймак кадәр генә ачып, гөнаһсыз сабыйдай күзгә карап торуларын күргәч, режиссер үзе дә шикләнә төшә. Әмма өметен өзми. Уйланырга, эзләнергә куша.

Башка иҗат кешеләренең – язучыларның, рәссамнарның, композиторларның – эш вакытындагы уйлануларын, тир түгүләрен, газаплануларын, ичмасам, язып-сызып ыргыткан тау-тау кагазь өемнәреннән чамалап була. Шиксез ки, артист та алардан ким иза чикми. Төннәр буе утырып, рольгә хас эчке һәм тышкы буяулар эзли, күпме дулкынлана, ачы күз яшьләре түгә! Тамашачы аны белми дә, сизми дә...

«Көзге ачы җилләр»дән соң артистка Чыңгыз Айтматовның мәгълүм повесте буенча эшләнгән «Гүзәлем Әсәл» спектаклендә катнаша. Бу юлы инде өлкән яшьтәге кыргыз хатынын ул шундый шәп итеп уйный ки, бер спектакльне дә калдырмыйча караган театр әһелләре дә югалып калып: «Әсәлнең анасын кем уйнады соң?» – дип сорарга мәҗбүр була.

Галимә Ибраһимованың соңгы еллардагы иң уңышлы роле – Шәриф Хөсәеновның «Әни килде» драмасындагы Ана образыдыр, мөгаен. Баштарак аңа бу роль дә җиңел бирелми. Рольне кулына алгач, ул шактый вакытлар фикер туплап, образның асылына төшенә алмыйча аптырап йөри. Ни өчен бу ана шундый коточкыч хәлдә кала соң әле? Гомер буе җиргә ябышып яткан, тамырланып беткән куллары беркайчан да ал-ял күрмәгән, авыр сугыш елларында, үзе ач торып булса да, балаларын туендырган, аларны киендергән ана нигә чит кеше бусагасында кала? Аны әнә шундый авыр сораулар борчый. Хәтта премьерадан, котлаулардан соң да ул һаман эзләнә, үзе башкарган образга яңа детальләр өсти...

Татарстанның илле еллыгы уңаеннан театр Мәскәүгә гастрольләргә баргач, бу спектакльне андагы тамашачылар да яратып карый. «Правда», «Известия», «Советская культура» газеталарында һәм «Театральная жизнь» журналы битләрендә «Әни килде» спектакленә багышланган рецензияләр басылып чыга. Ул рецензияләрдә ана ролен башкаручы Галимә Ибраһимовага карата да күп җылы сүзләр әйтелә. Әлеге спектакльдә иҗат иткән Ана образы аша ул үзенең иҗат мөмкинлекләре иксез-чиксез булуын тагын бер кат раслый.

...Татар театр сәнгатенең чишмә башында Тукайлар, Камаллар, Тинчуриннар торган. Бу игелекле сәхнәдән Зәйни Солтан, Нәгыймә Таждарова, Шакир Шамильский, Гөлсем Болгарская, Хөсәен Уразиковлар узган. Шушы данлы театрда Галимә Ибраһимованың да илле ел буе эшләве күп нәрсә турында сөйли. Ул аның сәхнәсендә татар, урыс һәм дөнья классикасы әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә күпсанлы гүзәл, хискә бай образлар иҗат итә. Хатын-кызның рухи көчен, характер ныклыгын, тыйнаклыгын, гаделлеген һәм намуслылыгын күрсәтә. Радио һәм телеспектакльләрдә дә истә калырлык образлар тудыра Галимә. Эшчеләр, авыл халкы, Совет Армиясе сугышчылары алдында чыгыш ясый, үзенең тәҗрибәсен яшь артистлар белән уртаклаша. Г.Ибраһимова образларны гадилек, күркәмлек белән, тирән фикер йөртеп иҗат итә. Табигать аңа чибәрлек, мөлаемлык, ефәктәй йомшак тавыш биргән. Бу – сәхнәдә ярты уңыш дигән сүз. Уңышның икенче яртысын тырышлык һәм иҗат газабы бирә, билгеле.

Галимә Ибраһимова – сәхнәдә дә, тормышта да бәхеткә ирешкән кеше. Хәләл җефете, танылган балетмейстер Гай Таһиров белән бергә алар озын, матур гомер кичерә.

Күренекле артистканың йөрәге 1984 елның 26 мартында тибүдән туктый.

Фотографияләр Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры архивыннан алынды. ■

Безнең мирас №2 февраль 2017

ТАЛАНТ, ИҖТИҺАД ҺӘМ ФИДАКЯРЛЕК ҮРНӘГЕ

(Мөнир Якупов тормышына һәм иҗатына бер караш)

Рәдиф Сәгъди

Мөнир Якупов Нәҗип Җиһановның «Алтынчәч» операсындагы Колухан ролендә

Үткән гасырның сиксәненче елларында Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрына Казан дәүләт консерваториясен тәмамлаган бер төркем талантлы яшьләр килә: Х.Бигичев, Р.Сәхәбиев, С.Раинбәков, М.Якупов, Р.Маликов, Р.Идрисов... Табигатьтән, нәсел-нәсәбеннән кадерле ядкяр итеп тапшырылган затлы тавышлары белән совет илен таң калдыра алар.

Шулар арасыннан Татарстанның халык артисты Мөнир Якупов шәхесенә аерым тукталып үтәсе килә.

...19 яшьлек үсмер Садрины патша хезмәтенә алалар. «Без авылны чыккан чакта күтәрелде томаннар, йә кайтырмын, йә кайтмамын, сау булыгыз, туганнар», – дип урам көйләрен җырлап, якыннарын сагыш-кайгыларда калдырып, чит төбәкләргә китеп югала ул. 25 ел буена сәлам хатлары гына килеп тора казна исәбенә яшәгән солдаттан. 25 ел! Күз алдыма китерсәм, тетрәнеп куям! Үзем Совет армиясендә ике генә ел хезмәт итсәм дә, туган җирләргә әйләнеп кайту вакытын көнләп саный идем. Монда 25 ел гомереңне алсыннар әле, туганнарыңны, авылыңны сагыну иксез-чиксез газап булгандыр. Якыннары бәхетенә, исән-сау әйләнеп кайта Садри солдат. Өйләнә, гаилә кора, кызы

Афифәгә гомер бирә. М.Якуповның Әтисе ягыннан бабасы Зәйнетдин исә мәдрәсәдә ныклы белем ала, соңыннан үзе укыган мәктәбендә хәлфәлек итә, мулла була. Мең ярым йорты булган Иске Атлаш халкы мөкиббән китеп тыңлый аның матур яңгырашлы моңсу тавышын, соңыннан ул моң, улы Әхәт аша, оныгы Мөниргә мирас булып күчкәндер! Бакый дөньяда бер генә үзгәлек тә буш урыннан калыкмый, ягъни юктан бар булмый! Җиде буынның берсендә яисә берничәсендә чагылыш таба ул... Димәк, Зәйнетдин мулланың илаһи тавышы Мөнир оныгында кабатлана...

1949 елның 25 мартында Ульян өлкәсе Иске Кулаткы районы Иске Атлаш авылында гомер кичерүче Әхәт абый белән Афифә апа гаиләсендә, Равил, Разия, Җиһанша, Камилдән соң, бишенче бала булып кечкенә Мөнир аваз сала. Дүрт елдан соң Әхәт абыйны Коробково хуторына урманчылык эшенә җибәрәләр. Бу «интернациональ сала»да, татардан тыш, урыс, мордва, чуашлар яши. Авыл үзе нибары унлап йорттан тора. Халкы урман карый, питомникта үсентеләр үстерә, агач яндырып күмер ясый. Әхәт абый хуҗалыкта тотарга унбиш ат тәрбияли. Шулай булмый ни, урман-чытырман арасына зур техника белән керү мөмкин түгел, аның каравы, бахбайлар бу эштә алыштыргысыз мал: агач та сөйри алар, утыртып та йөртә, печәнен дә ташый, утынын да!

Әхәт ага үзе белгәнчә җырлар да көйли... Монда, карурман эчендә, аерата үзенчәлекле яңгырый аның сагышлы тавышы. Урманның шомлы шаулавы, кошларның моңлы сайравы дөнья белән таныша гына башлаган сабый Мөниргә дә тәэсир итми калмый. Мең аһәңнәргә, мең төсләргә бай икән бу урман! Әкияткә охшаш – серле, тылсымлы икән! Ә авылдаш абый-апаларның төрле телләрдә башкарган җырларын бирелеп тыңласаңмы-ы! Эрепләр китәрлек...

Мөнир беренче сыйныфны урыс мәктәбендә укый. Икенче сыйныфка кергәндә әбиләре генә яшәп калган туган авылларына кайталар. Атлашта Мөнир, ниһаять, татарча – ана телендә белем алуга күчә. Каникул вакытында иптәшләре янына Коробковога су коенырга, балык тотарга ашыга. Урман эчендә үзәгеңә үтәрлек салкын сулы күлләр азмыни? Тиз генә чумасың да, салкын су өтеп алуга, ярга сикерәсең. Шуңа күңелең булып, тизрәк җылыныр өчен кире Атлашка чабасың, аягың җиргә тими!

Сигезенче сыйныфны тәмамлагач, булачак җырчы күрше авылга – Иске Мостякка йөреп укый әле. Ләкин бу рәвешле озак «йөдәргә» насыйп булмый аңа. Әхәт ага: «Камил белән икегезне дә йөртеп укыта алмыйм, Мөнир, сиңа авылда гына калырга туры килер», – дип, бу хәлгә чик куя. Гаиләнең матди хәлен аз гына булса да яхшыртыр өчен, үсмер егет туган авылындагы промбыткомбинатка эшкә урнаша. Төзелешкә китерелгән известьны «сүндерерү» өчен ат белән су ташый. Монда эш беткәч, биш чакрым ераклыктыгы урманнан пилорамага бүрәнә китерергә билгелиләр. Чандыр гына күренсә дә, табигатьтән бирелгән көч, ныклык, чыдамлык ундүрт яшьлек егеткә хезмәттә сынатмаска ярдәм итә. Кичке мәктәпкә йөреп тракторчы таныклыгы алганнан соң, бригадир соравы буенча, аны «За мир» колхозына механизатор итеп күчерәләр. Кышын салам эскерте тарттыра, җәйләрен арба тагып печән-үлән ташый, басу-кырлар сукалый. Беркадәр вакытта соң Мөнир колхоз рәисенә кереп белешмә (паспорт урынына) сорарга батырчылык итә. Новоульяновск шәһәренең һөнәри училищесына укырга керер өчен шул язу да ярап куя. Биредә үсмерне мәҗбүриләп диярлек хорга язалар. Баянчы баштарак: «Нишләп болай кычкырып җырлыйсың?» – дип бәйләнсә дә, соңыннан аны башлап җырлаучы итеп билгели.

Шуннан китә инде булачак опера җырчысының киң колачлы иҗаты...

Училищеда бер ел укыганнан соң, җәйге каникул вакытында район үзәгенә

Остазлар белән бергә. Утырганнар (уңнан) – Фәхри Насретдинов, Мөнир Якупов, Сара Садыйкова; басканнар – Әхмәт Кәримов, Зөһрә Сәхәбиева, Миңгол Галиев. 1979 ел

барып, ниһаять, паспорт алуга ирешә (уналты яше тула). Яшь һөнәрине шәһәрдән җибәрергә теләмиләр. Монда ул төрле фестивальләрдә катнаша башлый. Шуларның берсендә күреп, «Волгасантехмонтаж» идарәсенең комсомол секретаре Якуповны үзәк идарәгә эшкә чакыра. Анда күчкәч, егет көндез станокта тимер кыра, тимер бөгә, кичләрен Мәдәният сараена – үзешчән сәнгать түгәрәгенә җырларга йөри.

Көннәрдән беркөнне шәһәр урамында аның күзенә ят афиша ташлана: Татарстанның һәм Россиянең халык ар-

тисты Венера Шәрипова белән Габделхак Шаһиев концерт куярга килә икән ләбаса! Мондый мөмкинлекне ычкындырырга ярыймы соң?! Мөнир концерттан рухи савыгып кайту белән генә чикләнми, чарага хәтле Венера ханымны эзләп таба, аннан үзенең җырлавын тыңлап каравын үтенә. Ризалык алгач, татар халкының «Көзге ачы җилләрдә» һәм шагыйрь Юрий Полухин сүзләренә композитор Серафим Туликов язган «Родина» җырын башкара. Күренекле җырчы аңа: «Тавышың әйбәт, сиңа, энекәш, Казанга күчәргә кирәк», – ди. Шунда ук җыр һәм бию ансамбле җитәкчесе Александр Ключарев исеменә тәкъдимнамә дә язып бирә.

Мөнир, тәвәккәлләп, 1968 елның 3 гыйнварында Казанга килә. Аны ансамбльнең хормейстеры Ж.Котдусов, Тукай исемендәге филармониянең сәнгать җитәкчесе М.Нигъмәтҗанов тыңлап карый. Сынау беткәч, егеткә чыгып торырга кушалар, ун минут киңәшкәннән соң, кире чакырып алалар һәм җырчы буларак хор төркеменә кушылырга тәкъдим итәләр. Александр Ключарев исә:

– Төзелештә күпме ала идең соң, энем? – дип сорый.

– 120-125 тәңкә, – дигән җавап ишетә.

– Без алай ук түли алмыйбыз шул, энекәш. 75 сумга риза булсаң, рәхим ит...

Казан хәтле Казанга кил дә... риза булмыйча кая барасың инде?! Репетиция башлануга бер ай да үтми, Мөнир Якупов кырык биш көнлек тәүге гастроленә чыгып китә. Ансамбль Нижгар, Ленинград, Нарва, Рига, Калининград кебек шәһәрләрдә чыгыш ясый, Казанга кайтышлый Мәскәүдә ике концерт куя. Егеткә бу вакытта нибары унсигез яшь була. Унтугызынчы туган көнен Рига шәһәрендә каршылый ул. Гастрольдән кайтуга, җырчыны уч төбе кадәр «сөенче хаты» көтеп тора: хәрби комиссариат егеткә ватан алдындагы бурычы турында искә төшерүне кирәк таба. Егерме икенче майда армия сафлары тагын бер талантлы солдатка байый...

Тиешле вакытын күн итек таптап үткәргәч, Мөнир Якупов яңадан җыр һәм бию ансамбленә әйләнеп кайта. Яшьлек дәрте ташып торган «гөрнәдирне» сәнгать әхрамында җылы каршылыйлар, кабаттан элекке эшенә билгелиләр. Озакламый Җәвит Котдусов аны үзенә чакыртып ала:

– Сиңа, энекәш, укырга кирәк, – дип, консерваториягә юллама бирә. Ул вакытка имтиханның беренче туры Якуповтан башка гына үткән була инде. Кабул итү комиссиясе рәисенә мөрәҗәгать итеп карарга уйлыйлар. Аларның үтенечен тыңлагач, Нәҗип Җиһанов:

– Әйдә, энекәш, җырлап кара инде, алайса, – дип, яшь җырчыны икенче турда катнаштыра. Егетнең башлангыч музыкаль белеме булмавы ачыклангач, күренекле композитор аңа әзерлек курсларында укырга киңәш итә. Ике ел сизелми дә үтеп китә һәм, ниһаять, өметле артистны консерваториягә кабул итәләр. 1978 елда әлеге уку йортын тәмамлаганнан соң, Мөнир Якупов М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрына эшкә чакырыла. Бу вакытта, алда искәртелгәнчә, элитар сәнгатькә берсеннән-берсе талантлырак яшьләр килә. Нәҗип ага Җиһанов һәм Нияз ага Даутовның тырышлыгы аркасында театр чын-чынлап үсеш-күтәрелеш чорын кичерә.

Мөнир Якуповның бирсдәге беренче роле Ш.Гонуның «Фауст» операсында Валентин партиясе була. Катлаулы эчке кичерешләр тулы бу образны яшь җырчы сокландыргыч рәвештә ачып бирә. Югыйсә, монда, арияләр башкарудан гайре, драма артисты да булырга кирәк бит әле! Театрда эшли башлау чорында аның репертуарында «Князь Игорь» операсыннан (А.Бородин) Игорь партиясе барлыкка килә (урыс классик операсында бу партия иң катлаулылардан санала). Яңа гына консерватория тәмамлаган белгечкә мондый җаваплы роль тапшыру – талантны тану, егеттән киләчәктә зур җырчы чыгачагына ышану билгесеседер, мөгаен.

Мөнир Якупов, хактан да, һәм мөгаллимнәренең, һәм остазларының өметен аклый, бер-бер артлы А.Римский-Корсаковның «Царская невеста»сында – Грязной, П.Чайковскийның «Пиковая дама»сында – Граф Томский, Д.Пуччининың «Богема»сында – Шонар, «Тоска»сында – Скарпиа, Ж.Бизеның «Кармен»ында – Борис, Д.Вердиның «Риголетто»сында – Риголетто, «Травиата»да – Барон һәм башка бик күп образлар тудыра. Таланты һәм тырышлыгы аркасында үз чорының сәхнә йолдызлары булган Венера Шәрипова, Фәхри Насретдинов, Сара Садыйкова кебек остазлары белән бергә иҗат итү бәхетенә ирешә.

Мөнир Якуповның милли сәнгатьне үстерүгә керткән өлеше гаять зур. Ул барлык татар операларында да катнаша диярлек: С.Сәйдәшевнең «Наемщик» музыкаль драмасында – мулла, Н.Җиһановның «Алтынчәч»ендә – Хан, «Муса Җәлил»ендә – Ишназаров образларын сәхнәгә чыгара. Җырчының соңгы елларда башкарган рольләре арасында Фатих Әмирхан партиясен (Резеда Әхиярова «Шагыйрь мәхәббәте») аерым атап узарга кирәктер.

Янә куандырганы шул: җырчыны элеккеге СССР илләрендә генә түгел, бөтен дөньяда беләләр. Узган гасырның туксанынчы елларыннан башлап опера һәм балет театры һәрдаим Дания, Бельгия, Һолландия, Португалия, Франция, Австрия тамашачыларының күңелен яулап кайта. Мондый гастрольләрдән, билгеле, Мөнир Якупов та читтә калмый.

Бу җәһәттән 1998 ел күренекле сәнгатькяребез өчен бигрәк тә истәлекле. Көнбатыш Аурупа илләре тамашачысын тетрәндереп кайтуга, АКШта эшләп килгән татар җәмгыяте чакыруы буенча, театр җырчылары Нью-Йорк шәһәрендә дүрт концерт бирә. Анда милли операларыбыздан арияләр һәм борынгы җырлар яңгырый. Океан артында гомер кичергән кан кардәшләребез Мөнир Якуповның көчле, моңлы тавышына таң кала. Аларның күңелләрендә соклану һәм горурлану хисләре ныгый. Җырчыны чәчәкләргә күмәләр, зурлап кунак итәләр. Америкадан кайтырга өлгерми, Төркия операсының 75 еллыгына багышланган фестивальгә чакыру килә, анда да Зилә Сөнгатуллина белән Мөнир Якупов юл тота. Биредә Н.Җиһановның «Алтынчәч» операсыннан арияләр һәм дуэтлар башкарыла. Озакламый Кипр утравында үткәрелгән «Турсай» төрки халыклар опера фестивалендә катнашырга насыйп була. Бу юлы Татарстанның атказанган артисты Разия Үзбәкова белән гала-концертта чыгыш ясыйлар. Татар артистлары, һәрвакыттагыча, алкышларга күмелә...

...Артка борылып карасаң, күпме еллар, күпме юллар үтелгәнен күреп исең китә. Казан-Кулаткы арасында гына да күпме йөрелгән икән, әй?! Чит илләрне, чит шәһәрләрне айкау – кичә генә булган кебек, югыйсә!

Юк шул, күпме гомер узган...

Татарстанның халык артисты Мөнир Әхәт улы Якупов, 2000 елдан башлап, үзе тәмамлаган Казан дәүләт консерваториясендә (бүген ул лаеклы рәвештә Н.Җиһанов исемен йөртә) мөгаллимлек кыла, тормыш юлында мулдан туплаган тәҗрибәсен, гыйлемен яшь буынга тапшыра. Шәкертләр белән эш иткәндә тырышлык кына җитми, чиксез сабырлык та сорала: һәрберсенең күңелен аңлый, аңа җайлаша белергә кирәк. Һичкемне тупас рәвештә ачуланырга, кимсетергә ярамый, киресенчә, һәркемне мөмкин кадәр үсендерү, өметләндерү, үз-үзенә ышандыру зарур.

Мөнир Якупов студентларына бер сайлаган юлдан тайпылмаска киңәш итә, кеше гомерен яраткан хезмәтенә (бу очракта – иҗатка) багышлаганда гына бәхетле була, дип аңлата.

Мөгаен, ул хаклыдыр.

Һәрхәлдә, шәхси үрнәге нәкъ шуны раслый кебек. ■

Безнең мирас №2 февраль 2017

ИЛЧЕ КҮЧТӘНӘЧЕ

Равил Вәли

Салих Сәйдәшев

Балыкчы балыкчыны ерактан таныр, дигәндәй, Сәйдәш тә сәер агай янынннан тыныч кына үтеп китә алмады:

– Җыр тыңлатып балык тотучылар бер мин генәме дисәм?..

– Ә мин күптән шулай тотам инде.

– Эләгәме соң?

– Ничек кенә әле! Аеруча менә шушындый озын, моңсу көйләрне яраталар. Көен инде әйткән дә юк – бер ишетүдә йөрәкләргә кереп урнаша. Сүзләре дә ничек гадиләр, ничек тирән мәгънәле дә үзләре! Безнең дә тиздән туган авыллар белән хушлашып китәселәр булганга шулай кадерледер инде мондый хушлашу хисләре...

Көй тыңлатып балык тотучы сәер агай моңсу тавыш белән «Хуш, авылым!» җырының соңгы юлларын кабатлап куйды:

...Исән булсам, бер кайтырмын
Язлар кебек әйләнеп.

– Әйе, тиздән без дә авылыбыз белән су басачак бу яклардан Лаеш тарафларына күчеп китәчәкбез. Тик бер киткәч, җырда әйтелгәнчә, язлар кебек әйләнеп кайтып булмас шул инде...

Ул Сәйдәшнең халык сүзләренә язылган тагын бер җырын көйли башлады:

Сайрый тургай, сайрый тургай,
Баласын җуйган бугай.
Баласын җуйган тургайдай,
Ник моңаям мин болай?

Бусы да шул «Күзләр» пьесасыннан Рәйсәнең икенче җыры иде. «Тургай» исемле бу җырның сүзләрен да пьеса авторы Хәбибулла Фәтхуллин язарга тиеш иде. Ләкин, чит илдә яшәгәч, ул соңга калган булып чыкты. Чөнки башта спектакльдә Рәйсәнең беренче җырын гына яңгыратырга уйлаганнар иде. Ләкин «Хуш, авылым!» шундый уңыш казангач, Рәйсәдән икенче өр-яңа көйне дә җырлатырга кирәк табылды. Ә илче Хәбиб чит илдәге җәһәннәм тишегендә консуллык итә. Аның тиз кайтырына өметләнеп булмагач, әлеге галәмәт ашыгыч эшкә спектакль режиссеры Кәшифә Тумашева үзе алынды. Бу чибәр һәм үтә булдыклы ханымның Казан сәхнәсендәге беренче җитди эше иде. Шунлыктан, «Күзләр» спектакле уңышлы килеп чыксын өчен, ул бөтен көчен, бөтен сәләтен бирде.

Һәм үз язмышына да аваздаш халык сүзләрен тиз арада табып та китерде. Бу юллар булачак «Тургай» көенең авторы Салих Сәйдәшевкә дә бик ошады:

Кыйгак-кыйгак каз кычкыра,
Нинди моңлы каз икән?
Җырласам, елыйсым килә,
Әллә гомерем аз микән?!

Бу җырның язмышы да бик бәхетле булып чыкты. Аның шулай ук ифрат гади,

---

Башы журналның 1 нче санында (2017).

ләкин тирән мәгънәле сүзләрен дә, шундый ук киң сулышлы көен дә халык бик тиз отып, күтәреп алды.

Тик илче Хәбибнең генә читтә торып калуы менә... Әлбәттә, бу үкенечле хәл белән килешү аңа җиңел булмагандыр...

Сәйдәш Идел яры читеннән тегеләй дә болай атлады. Ләкин кайчандыр япь-яшь иҗатташы булган илче Хәбиб турындагы уйларыннан бик озак аерыла алмады. Дөресрәге, теләмәде. Аңа татарның чит илләрдә аерылып яшәргә тиеш булган бу талантлы һәм булдыклы улы хакында уйлау бик рәхәт вә шул ук вакытта шактый ук газаплы да иде.

Көндезләрен медицина институтында укып, кичләрен исә кочегаркада эшләп йөргән, алай гына да түгел, шул кичке шарт та шорт янган кочегарка уты яктысында менә дигән «Күзләр» пьесасын һәм «Хуш, авылым!» җырының гади дә, аһәңле дә сүзләрен иҗат иткән бу Казан арты егетен Сәйдәш беренче күрүдә үк бик ошаткан иде. Үзе үтә чибәр, үзе кунадай киң җилкәле, таза, Казан арты кешеләренең күбесенә хас булганча, аз сөйләшә, ләкин күп эшли. Мондый кеше тормышның кайсы гына өлкәсендә хемәт итсә дә текә үрләргә менә алачагы аермачык иде. һәм ул нәкъ менә шулай булып чыкты да! Хәзер Хәбибулла Фәтхуллин СССРның Алжирдагы генераль консулы! Казанга кайтканда, Салих агасын күреп, хәлләрне гел белешеп тора. Шул яклардан алып кайткан илче күчтәнәчләреннән – кызгылт мандариннар белән саргылт әфлисуннар, сап-сары лимоннардан да өзелеп торган юк. Сәйдәш кебек ашказаны борчыган кешеләргә, табиблар әйтүенчә, болары да бик кирәк, бик файдалы.

Илчелек йомышлары белән Мәскәүгә кайткан чакларында, әгәр Казанга сугылырлык вакыты булмаса, ил башкаласындагы тимер юл вокзалына барып, Хәбибулла Фәтхуллин мондый күчтәнәчләрне очраклы туры килгән пассажирлар аша биреп җибәрә.

Ә табиблар цитрус җимешләрен, эзләп табу яки сатып алулар бигүк җиңел булмаса да, Сәйдәшкә еш ашарга кушалар иде. Чөнки аңарда ашказаны чире таптылар. Кайчандыр үзе дә төньяктагы рус-фин сугышында, аннары Кытайның татарлар күпләп яшәгән бер төбәгендә хәрби табиб булып хезмәт иткән Хәбибулла Фәтхуллин исә шуңа күрә авыру композиторның хәлен яхшы аңлый һәм, мөмкин булганча, аңа ярдәм итәргә тырыша иде...

Илче Хәбиб турындагы татлы да, рәхәт тә булган уйларыннан бүлдереп, менә ата балыкчы Сәйдәшнең колагына җиз кыңгырау чыңлавы килеп керде:

– Зең-зең...

Теге музыкаль балыкчының кармак җебенә бәйләнгән нәни кыңгырау телгә килгән икән! Уймак хәтле генә үзе. Ә тавышны ничек чыгара!

Кармак сабының очы кинәт көчле генә тартылып куйды да, әлеге балыкчы комлы яр читенә беләк буйлык симез бәртәсне тартып чыгарды һәм яңадан баягы «Хуш, авылым!» көен уйный башлады.

Сәйдәшкә бу шактый сәер тоелды:

– Ә Сез нигә бер үк көйне кат-кат уйныйсыз?

– Зерә дә халыкчан булгангамы, менә шушы көйгә балыклар шәбрәк чиртә...

Гади генә шушы җавaптан да Сәйдәшнең күңеле булды. Кармак кыңгыравына кушылып, аның да күңел кыллары зыңлап куйды.

Бераздан, музыкаль балыкчыга уңышлы чиртүләр теләп, Сәйдәш үз юлы белән китеп барды:

– Җырлар тыңлатып балык тота белгәнегез өчен, рәхмәт, бәгырь! Күңелем бик булды...

– Тыңлый һәм күрә белгәнегез өчен, үзегезгә дә рәхмәт, абзый кеше!

***

Тарихчы Хәйри Гыймади экспедиция барышында Сәйдәшкә үз фәне буенча гел файдалы киңәшләрен биреп, аны зур музыкаль әсәр язарга дәртләндереп торды. Идел ярында кармак салып утырган, инде күрәсен күргән, ишетәсен ишеткән балыкчылар да су астында калачак борынгы төбәкләр тарихыннан аңа байтак кына кызыклы һәм гыйбрәтле хәлләр сөйләделәр. Казанга әйләнеп кайтканда, булачак балетның төп эскизлары әзер иде инде. «Гөлнара» балетының биюләрен сәхнәгә куярга күренекле балетмейстер Гай Таһиров алынды. Либреттосын да ул язды. Ике зур иҗатчының таланты бер әсәрдә очрашкач, тагын «Зәңгәр шәл» мелодрамасындагы отышлы хәл килеп туды. «Гөлнара» балеты академия театрының худсоветы тарафыннан берсүзсез хупланды һәм сәхнәгә куярга тәкъдим ителде.

Ләкин Черек күлдәге «усал йорт» ияләре тырнак астыннан тагын кер эзләп таптылар. Кернең дә нинди шомлысын һәм зурысын әле!

Беркөнне кичкә кырын тышкы ишекне каты дөбердәттеләр. Ашыгып-каударланып, бикне ачарга Сәйдәш үзе барды:

– Кем бар анда?

– Ач, диләр сиңа, Тинчурин калдыгы!

Сәйдәш, шомланып, эчтән генә уйлап куйды: әһә-ә... Тинчуринны телгә алгач, тәгаен, теге йорттан килгәннәр инде болар!

Ишекне тагын, тагын кактылар. Нишләтәсең, бикне тәки ычкындырмый булмады.

Менә богылдай озын-таза гәүдәле ике кеше атылып керде дә, күз ачып йомганчы, Сәйдәшнең хәлсез беләкләренә тимер богау киертеп тә куйды:

– Ә хәзер марш безнең алдан машинага.

Сәйдәшне күптән күзәтеп йөргәнгәме, кара киемле бу шымчыларның йөзе, нишләптер, бик таныш тоелды. Китүләр шушымы икәнни?

Сәйдәш шулай да сорап куясы итте:

– Шәхси әйберләремнән нәрсәләрне алырга мөмкин?

– Пор... порти... – диде дә, теле төртелеп, беренче шымчы туктап калды.

Аңа икенче шымчы ярдәмгә килде:

– Партитура, диген!

Сәйдәш тә, ниһаять, нәрсә алырга кирәклеген аңлап алды:

– Ә-ә... Димәк, балет партитурасын!.. Ә кашык-сабын кебек әйберләр?

– Бүген үк кирәкмәстер, мөгаен.

Салкын гына әйтеп куелган соңгы сүзләрне ишеткәч, эчкә бераз җылы керде керүен.

Дегет төсле кара автомобильгә утыртып, Сәйдәшне каядыр алып киттеләр. Хәер, кая икәнлеге билгеле инде: бүген барлык юллар да шул Черек күл тарафларына илтә!

Либретто авторы Гай Таһиров та шушы ук машина эчендә, капкынга эләккән киектәй, калтыранып утыра. Аның да кулына тимер богау киерткәннәр.

Аларны ил иминлегенең Казан төбәгендәге баш сакчысы бүлмәсенә алып керделәр. Чиртсәң, кан чыгардай кызыл чырайлы, симез гәүдәле генералның талканы бик коры булып чыкты:

– Партия Үзәк Комитеты, татарларның ерак тарихын өйрәнү белән мавыкмау кирәклеген искәртеп, күптән түгел генә махсус карар чыгарды, – диде ул, үгезне мөгезеннән эләктереп. – Ә сез нишләп йөрдегез ул Идел Болгариясе якларында? Анда сезне кем җибәрде?

Сәйдәш бернче сораудан ук коелып төшмәде:

– Үз теләгем белән... Экспедиция составында...

– Композитор була торыпмы? – диде баш сакчы, ярсыганнан-ярсый барып. – Нәрсә?.. Андагы яр буйларында дулкыннар ничек шаулавын тыңлап йөрдегезме? Дәүләт акчасына...

– Булды инде азрак анысы да...

Ниһаять, генерал әфәнденең да сабырлыгы төкәнде:

– Йә, партия карарына каршы килеп, нинди корткыч әсәр язып кайттыгыз ул борынгы төбәктән? Ишетсен колагыгыз: бернинди ханнар тарихы да, Алтын Урда тарихы да юк татарлар өчен! Икегезнең дә бер аягы инде төрмәдә!.. Ә хәзер чыгарып салыгыз ул корткыч балетның текстын һәм, әлбәттә, авазларын менә шушы өстәлгә!

Йөрәктән яңа өзелеп төшкән һәм, өстәвенә, инде репетицияләр башланган иҗат җимеше булгач, балетның генерал әйткән «текстын һәм авазларын» гел үзләре белән йөртәләр иде:

– Рәхим итегез! Тик...

Усал йөзле генерал симез йодрыгы белән өстәлгә китереп сукты:

– Бернинди тикләрсез генә!

Генерал партитурадагы моңарчы үзенә бөтенләй таныш булмаган койрыклы һәм койрыксыз нота билгеләренә тиз генә күз төшерде дә, теше үтмәгәч, ачу белән аларны бер читкә алып куйды. Балет либреттосы да шундый ук язмышка дучар булды. Менә генерал артындагы тимер сейфның нәни ишеге кинәт шап итеп ачылды да, каты итеп ябылды. Әйтерсең, яңа туып килгән «Гөлнара» балетының партитурасын һәм либреттосын да мәңге чыкмаслык тимер зинданга бикләп куйдылар!

Ләкин Сәйдәш әйтә башлаган сүзеннән туктап калучылар исәбеннән түгел иде:

– Тик... балет тексты – либретто, ноталарга салынган музыкаль авазлары исә партитура дип йөртелә бит, иптәш генерал!

Үзенең наданлык бакчасына таш ыргытылуын аңлаган иминлек башлыгының бит-йөз тирәләре адәм каны төсенә керде. Биек аркалы утыргычыннан авыр гына күтәрелде дә, ул башта бүлмә ишеген төбенә хәтле ачып куйды. Ачык ишектән каты җәзалауга түзә алмаган тоткынның ачыргаланып кычкырган тавышы бәреп керде.

Кансыз генерал, бераз сүзсез торгач, янаулы тавыш белән әйтеп куйды:

– Ишеттегезме инде?!. Ә хәзер икенче аягыгыз да Тинчуриннар бет симерткән тарафларга атлый башламасын дисәгез, барыгыз – хәзер үк күземнән югалыгыз! – диде ул, алар артыннан ишекне каты ябып.

«Усал йорт»тан чыгып Черек күл буеннан бераз атлагач, Сәйдәш авыр уфтанып куйды:

– Их, Гай бәгырь! Күпме уртак хезмәтебез юкка чыкты бит, ә!..

Гай Таһиров исә иҗатташ дустын тынычландырырга ашыкты:

– Борчылмагыз, Салих Җамалетдиныч! Ярый әле, башыбыз исән котылды, диегез!

Һәм бераздан, Сәйдәшне бөтенләй тынычландырып, өстәп куйды:

– Ә мин, Салих ага, ишек төбенә килеп җиткән хәвеф-хәтәрне алдан сизенеп, балет партитурасы белән текстын амбар кенәгәсенә күчереп куйган идем...

– Шулаймы, бәгырь!.. Бир, бишне, алайса.

Ләкин шатланырга иртә иде әле. Черек күл буендагыларның кара исемлегенә эләккән «Гөлнара» балетын академия театры сәхнәсенә менгерергә, билгеле инде, берәү дә рөхсәт итмәде. Ул ерак Себер якларыннан әйләнеп кайта алмаган Кәрим Тинчурин язмышына дучар булды.

Ә «Зәңгәр шәл» мелодрамасы һәм башка әсәрләрендә татар халкының азатлык рухына дан җырлаган, партия тыйган ерак үткәнебезгә багышлап «Гөлнара» балетын иҗат иткән Салих Сәйдәшевкә җәзаның тагын да катысын кулландылар. Озак та үтмәде, штат кыскартабыз – академия театрында бернинди оркестр да, дирижер да булырга тиеш түгел, дигән сылтау белән, аны эштән азат иттеләр. Моңа өстәп, азмыкүпме гонорар да эшли алмасын өчен, Сәйдәшнең музыкаль иҗатын зур сәхнәгә менгерүне, радио эфирларыннан яңгыратуны катгый тыйдылар.

Ә кеше ничек яшәргә тиеш иде соң?! Аның бит гаиләсе, хатыны һәм газиз балалары бар...

Дәвамы бар ■

ИКЕ ЯКЛЫ ГӨСЛӘ

Гөслә – күп кыллы чиртмә музыка коралы. Идел-Урал төбәгендә яшәүче халыкларда (татар, чуваш, мари, удмурт) ул борынгы заманнардан ук кулланышта булган. Бүгенге көндә исә гөсләдә уйнау традициясе Казан арты керәшеннәрендә сакланган. Тик ул югалып бару дәрәҗәсенә җитте. Башкаручылар саны (аларның күпчелеге – өлкән яшьтәге хатын кызлар) елдан-ел кимеп бара. Әлеге уен коралын, анда уйнау традициясен тирәнтен өйрәнү, саклау һәм яңарту максатыннан, мин 2013 елдан бирле махсус экспедицияләргә чыга башладым. Балтач, Арча якларында халык арасында гөсләләр әлегә бар. Әмма 2015 ел табышлары – гадәттән тыш! Киров өлкәсе һәм Мари Иле Республикасында моңарчы татар фольклоры фәнендә яктыртылмаган гөсләләрнең яңа төрләре ачылды. Шуларның берсе – «ике яклы гөслә». Ошбу язмада аңа аерым тукталырбыз.

Келәт. Бередә кич утыруларда гөсләгә кушылып җырларга һәм биергә яратканнар. Келәт хәзер дә исән. Бүрәнәне ярып (однорезкадан) эшләнелгән. Иске Чепьядан күчергәннәр

Ике яклы гөсләдә уйнау рәвеше. Василий Иванов һәм Эльмира Каюмова

Автор фотолары.

Ике яклы гөслә (халык атамасы) ике кеше кара-каршы утырып уйнар өчен эшләнелгән. Аның озынлыгы – 97 см, киңлеге – 62,5 см, калынлыгы – 25 см. Чагыштыру өчен, гади үрнәкләрнең үлчәмнәре: 70-90 х 30-35 х 11-14 см чамасы. Димәк, бу – зур гөслә, башкалардан икеләтә киңрәк һәм калынрак. Өске ягы ике деканы (тактаны) кушып ясалган. Шуңа күрә, әлеге коралны «куш гөслә» дип атау да мөмкин. Һәр ягында тавышны көчәйтә торган өчәр түгәрәк тишек һәм 12 кыл бар. Кылларның саны барлыгы – 24. Шулай ук өске өлешендә уртадарак – тимер, ә кырыйдарак агач җайланмалар күренеп тора. Бирегә барабанны беркеткәннәрдер, мөгаен: гөслә кылларын чирткәндә, барабанны да сугып торганнар, дип сөйлиләр. Гөсләнең төбе төрле зурлыктагы дүрт кисәктән тора. Кырыйларына бик үзенчәлекле, сырлап ясалган бизәкләр ябыштырылган.

Икеяклы гөслә Мари Иленең Мари-Төрәк районы Носла Пүчинкәсендә табылды. Җыелган мәгълүматлар буенча, аны 1930-1940 еллар тирәсендә Михаил Алексеевич Алексеев үзенең кызларына ясаган булган. Ул XIX гасыр ахырында Иске Чипья авылында (хәзер Татарстанның Балтач районына керә) туган. Йортлары янып беткәч, Кече Нослага күченеп килгән. Урман сакчысы, каравылчы булып эшләгән. Хатыны да, дүрт кызы да гөсләдә уйнарга яраткан. Шуңа күрә, өендә тагын бер – яшен суккан агачтан җитештерелгән, «шлем рәвешендәге» 12 кыллы (ягъни керәшеннәрдә таралганча) гөслә дә булган. Ике яклы гөсләдә исә кызлары Дарья (1922 елгы) һәм Лиза (1924 елгы) парлап уйнап, үзләре җырлап утырганнар. Өй янындагы келәткә җыелып, җырлап-биеп, уйнап-көлеп, кул эшләрен дә алып килеп, яшьләр күңел ача торган булганнар.

Искиткеч матур һәм көчле тавышы авылдашларның хәтерендә калган: «Менә шулай ике яклап уйныйлар, шундый жаңграп ишетелә аның, микрофон да кирәкми аңар, шундый тавышы әйбәт чыга»; «Бик матур аның тавышы,

Гөсләнең арткы ягы

бик каты жаңгырап чыга». Уникаль гөсләне 1940–1960 елларда әле ишетергә мөмкин булса, 1980 елларда инде ул кулланыштан төшеп, тора-бара онытылып та беткән.

Фәнни сәяхәт вакытында гөслә уйнамый торган хәлендә иде. Василий Алексеевич Иванов (1954 елгы, Носла пүчинкәсендә яшәүче, гөсләләр ясаучы) кылларын һәм чөйләрен (боргычларын) алыштырырга тотынган иде. Төзәтү эшен Гәрәй Габдрахман улы Мәгъсүмьянов (Йошкар-Ола шәһәрендә урнашкан Татар мәдәни үзәге хезмәткәре) тәмамлап, төрле фестиваль һәм концертларда чыгышлар ясап, тарихи уен коралының сихри яңгырашын замандашларыбызга ишеттерде.

Музей экспонаты күк кадерләп саклланырлык кыйммәтле ядкяребез тузып-таушалып бетәр, дигән борчуымны җиткергәч, Гәрәй ага күптән түгел генә (2016 елның җәендә) өр-яңа куш гөслә ясап куйды. Традицион үлчәмнәр, ясау нечкәлекләре бик үк сакланмаса да, яңартылган үрнәк сәхнә өчен җайлырак: йөртергә дә җиңел, тимер чөйләр белән көйләргә дә уңайлырак.

Шул рәвешле, ике яклы гөсләнең «гомере» дәвам итә...

Эльмира Каюмова,
сәнгать фәннәре кандидаты,
Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәгенең фәнни хезмәткәре,
ЮНЕСКО каршындагы Халыкара Традицион Музыка Киңәшмәсе (ICTM) әгъзасы. ■

Безнең мирас №2 февраль 2017

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

СОМ *тар.* — Идел буе болгарларында көмеш коелма, акча берәмлеге (сум). 200 граммнарга тигез булган. «Идегәй» дастанына бирелгән бит асты искәрмәсендә *сум* яки *сом* – саф, катыштырылмаган дип аңлатылып, *сум акча* һәм *сум ит* сүзләре мисал итеп китерелә. «Словарь диалектов сибирских татар» китабында сом сүзенең, моннан башка, «тоташ, таза, нык» мәгънәләре дә күрсәтелгән. //*Сом алтын* – саф алтын.

СӨБИ БАШ *бор.төр.* — Долихоцефал, озынча башлы кеше. Аларда баш киңлегенең баш озынлыгына нисбәте процентларда 75,9дан кимрәк була. Бу термин «Древнетюркский словарь»га теркәлгән.

СӨЕМБИКӘ БОСТАНЫ (БАКЧАСЫ) – Халык риваятенә караганда, Урта Кабан күле буенда калкулыкта урнашкан булган. Калкулыкның мәйданы күл буе тигезлегеннән 25 метр тирәсе югары. Археологик тикшеренүләр биредә иске шәһәрлек булганын күрсәтте. Монда кабер ташлары да табылды (мәсәлән, Хәсән бәк, затлы кыз Алтын Бөртек каберләренә куелган ташлар).

СӨЕНЕЧ КАЛА – Габдрахман Гомәри язуынча, *Грозный* шәһәрен комыклар шулай атаган. Ә Сөенеч *Туган Батырның* атасының исеме икән. Руслар биргән атама белән төркичә атама арасындагы капма-каршылык күзгә ташлана.

СӨЙДЕРГЕЧ – Кемне дә булса үзеңә карата, гашыйк иттерә торган чара. *// – Сандугач канаты – сөйдергеч икән! ...Шуның белән егетнең берәр җирен сыйпасаң, ул егет кызны тәкатьсез булып ярата башлый икән. Г.Бәширов.*

Сөембикә бостаны, Әрхәрәй бакчасы дип тә йөртелә

*Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә.

Сөйдергеч дога. Сөйдергеч бөти. Сөйдергеч дару – хәзерге вакытта бер сөйдергеч дару виагра (сильденафил) исеме белән билгеле. Бу дару кан тамырларын йомшартучы матдә молекуласын тарката. Башта Pfizer фармакология компаниясе виагра ангина вакытында йөрәктәге кан тамырларының йомшаруы нәтиҗәсендә йөрәккә кан килүен көчәйтә алыр дип исәпләгән иде, чынлыкта исә бу дару җенес органына кан килүен арттыручы чара булып чыкты.

СӨЛӘЙМАН ПӘЙГАМБӘР – Коръәни һәм библияви шәхес, Дауд пәйгамбәрнең улы, Иудеянең һәм Израильнең борынгы патшасы, акыл һәм тылсым иясе. Русча Библиядәге *Соломонга* тәңгәл. Еврейләрдә – *Шломо* (Дауд белән Вирсавиянең улы, яңа эрага кадәр 1015-975 яки 961-922 елларда патшалык иткән, кайбер чыганакларда аның туган елы итеп милядига кадәр 993 ел, ә вафат булган елы итеп 953 ел күрсәтелә).

Сөләйман яшерен гыйлемнәрне белгән, хайваннар һәм кошлар телен аңлаган. Күктән сөрелгән *Һарут* һәм *Марут* фәрештәләрдән сихергә өйрәнергә тырышкан күпчелек замандашларыннан аермалы буларак, Сөләйман Аллаһыга иман китергән һәм тәкъва кеше булган. Аллаһы Тәгалә җилләрне һәм җеннәр белән шайтаннарны Сөләйман пәйгамбәргә буйсындырган. Алар аңа диңгез төпләреннән хәзинәләр табып китергән, гыйбадәтханәләр төзегән һ.б. Сөләйман пәйгамбәр сихернең хуп күрелә торган кануни төре *«әт-тарика әл-мәхмүдә»*не белгән, дип сөйлиләр. Кануни сихер белән шөгыльләнүчеләр үз ихтыярларын Аллаһыга буйсындырып, Аңа ярдәм сорап мөрәҗәгать итә. Сөләйман пәйгамбәрнең бер мәгъшукасы Сәба патшабикәсе Бәлкыйс булган (Библиядә *царица Савская*). Кайбер риваятьләргә караганда, Сөләйман пәйгамбәр Бәлкыйсне хатынлыкка ала, башка риваятьләрдә исә ул аны Йәмән патшасына кияүгә бирә.

Риваятьләрдә сөйләнгәнчә, Сөләйман пәйгамбәр үз тормышында гөнаһлар да кылган һәм моның өчен җәзасын күргән. Мәсәлән, яшьрәк чагында яхшы атлар белән мавыгып, ул Аллаһны зикер кылырга онытып җибәрә, аннары, тәүбәгә килеп, ошбу атларны корбанга чалырга куша. Икенче юлысында ул Аллаһка табынудан тайпылганы өчен тәхетеннән мәхрүм ителә, ләкин тәүбә иткәч, Аллаһ аңа тәхетен кайтара.

Риваятьләргә караганда, Сөләйман патшаның тәхете һәрвакыт су өстендә эленеп торган.

Татарда: «Сөләйман үлде – диюләр котылды» дигән мәкаль бар.

А.Мень Соломон яңа эрага кадәр 961-922 елларда патшалык иткән дип исәпли. Ф.Контның «Библиядәге пәйгамбәрләр һәм каһарманнар» дигән китабында 970-931 датасы күрсәтелә. Библиядә сөйләнгәнчә, Соломон төшендә Алланы күрә. Алла аның теләген үтәргә вәгъдә биргәч, яшь Соломон: «Мин әле бик яшьмен, чыгышымны да, керешемне дә белмимен... Колыңа гакыллы калеб бүләк ит, мин Синең халкыңны дөрес хөкем итәрлек булсын, нәрсәнең яман, нәрсәнең изге булуын аера алыйм», – дип җавап биргән.

«Күп гакылның михнәте дә күп булгай; әгәр берәү гыйлемне үстермәк теләсә, кайгы-хәсрәтне дә үрчетер» – бу сүзләр Соломон патшаныкы. «Күп белсәң, тиз картаерсың», – ди халык та.

Сөләйман пәйгамбәрнең мөһере – алты чатлы йолдыз, ул үзенең җен һәм шайтаннарга биргән әмерләренә шул мөһерне баса торган булган, имеш. Бу мөһернең сурәтен төрле биналарда, савыт-сабада, акчаларда күрергә мөмкин.

Коръәннән соңгы әдәбиятта Сөләйман пәйгамбәр шәхесенә яһүди әдәбиятта булмаган күп кенә сыйфатлар өстәп күрсәтелә.

// Бу вафасыз дөнья эчләрендә Локман хәким ләззәт тапмаган; Тәхетләргә баскан, күккә ашкан Сөләйман нәби дә калмаган. Халык җырыннан. *Билең нечкә, кысыйм, дисәм, Буең зифа, кочыйм, дисәм, Сиңа таба очыйм, дисәм, Кирәк баде Сөләймани.* Г.Кандалый. ■

Җир йөзендә исеме бар, халык өчен җисеме бар!

Гүзәлия Хаҗиева,
Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты

Кыз бала исеме йолдыз балкышына охшасын,
назлы гөлчәчәктәй нәфис булсын.
Ир-ат исеме кылычлар чыңлавын хәтерләтсен,
аның мәгънәсендә гакыл гәүдәләнсен!
Рәсүл Гамзатов

«Исеме җисеменә туры килсен!» дигән ният белән һәр ата-ана баласына матур исем кую теләге белән яна. Татар халкының исем кушу йола-гадәтләрендә исем кешенең җаны һәм инсаниятнең әхлакый төшенчәләре белән бәйләнешмөнәсәбәттә чагылыш таба. Орхон-енисей язмаларында ук инде исемгә, исем кушу йолаларына зур игътибар бирелә. Борынгы төрки бабаларыбыз бала дөньяга аваз салгач кушылган исемне ада атым, оглан атым дип йөртсәләр, үсмер чакта, батырлыклар күрсәткәннән соң бирелгән исемгә эр атым дигәннәр, гомернең соңгы көннәрендә бирелгән исем исә айаг атым дип күрсәтелгән. Борынгы орхон-енисей язмаларында кешенең иҗтимагый дәрәҗәсе үзгәрүе, югарырак баскычка күтәрелүе дә исемдә чагылыш тапкан.

Татарларның исем кушу йолагадәтләрендә ислам традицияләре һәм җирле культурага хас үзенчәлекләр чагылыш таба. Исем кушу атамасының татар әдәби телендә *исем бирү, ат бирү* дигән вариантлары да кулланыла. Татар диалектларында исем кушу, мисал итеп, түбән сөйләшендә – *ат атау*; тубыл сөйләшендә – *пәпә атату*; урта һәм мишәр, себер диалектларында – *ат кушу, ат кушма*; касыйм сөйләшендә – *ат ушу, атын атату*; әстерхан, хвалын сөйләшендә – *ат кычкырту*; чистай сөйләшендә – *ат кыцкырту, ат кычкыру*; нократ сөйләшендә – *ат салу, исем салу, исем кистерү*; пермь, ләмберә, сергач сөйләшендә – *исем атау, исем кушу*; минзәлә, түбән сөйләшендә – *исем кушу*; красноуфим сөйләшендә – *азанлашу*, азан әйтү кебек атамалар белән билгеләнә.

Исем кушу йоласында кендек әбисенең роле зур. Билгеле булганча, элек бала тудыру йортлары юк чорларда, акушерка ролен авылның иң мөхтәрәм, им-том сәләтенә ия кендек әбиләре үтәгән. Һәр авылда им-том серләрен белгән андый кендек әбисе берничә була. Алар, бала табучы хатыннарга бала тудыруда ярдәм итүдән тыш, биш көн буена яшь әнигә бала карарга, баланы мунча кертергә ярдәм иткәннәр. Татар диалектларында кендек әбисен – әби, әби булучы, бала түрәтүче әби, бәбәй әбисе, инәкә әби, кендекче әби, кендегәе, мама, мамай, инәкә мама; инәлек әби, олан әбисе; түти әби, бабка, әби тәтә; әбилек, кендергәц,

кенддергәч, кендергәч карчык; кендек әби; кендек абасы, кендек мамам, бахсы; кендек инә; кендекәй; кентек инә, кендекче, кентекче, инәлекче; аппай корткайак, инәлек корткайак, инәкә, оста корткайак, колака, колакам, колагинәм, инәлек нәнә һ.б. дип атаганнар. Бала тугач та, кендек әбисе аңа вакытлы исем бирә, әлеге исемне халыкта *кендек аты* дип атаганнар: *«Бала туа, исемсез тормасын, кендек аты кушалар. Мулла китерәләр дә йакшы ат кушалар. Мулла кушкан исем белән гомер итәләр. Бусы кендек иseme, ә бала йакшыргач, азанчы китереп исем бирә. Ике исем бирәләр»*. Баланы исемсез калдырырга ярамаган, чөнки, яман көчләр балага зыян салырга мөмкин, дигән ышану яшәгән халыкта. Мәсәлән, нократ татарларында *йорт әбисе мифик заты* баланы алыштырырга мөмкин, дип уйлаганнар. *«Бала тугач, зак тотасы дегел, әби алыштыра аны. Ат саласы тизерәк. Өч көндән артык тотасы дегел»*. Халык традицияләрендә үле туган балага да исем кушалар. Халык ышануларында, бала исемсез күмелгән очракта, бу бала шунда ук явыз мифик затка – *Атсызга* әверелә. Борынгылар, сүзнең тылсымлы көченә ышанып, яман көчләрне алдау, эздән яздыру максатында, Атсыз исемен ир балаларга кушканнар.

Ислам дине кабул ителгәч, татар исемиятенә мөселман исемнәре үтеп керә башлый. Мөселман традицияләре нигезендә аш, *бәби ашы* үткәрелә. Татар диалектларында *аткушар*, *аткушар туй*, *аткушар мәҗлес*, *исем ашы* дигән атамалар да очрый. Мәсәлән, әстерхан сөйләшендә, кунакларның санына карап, исем бирү йоласын *кече аткушар*, *зур аткушар* дип атап йөртәләр. Бары тик якын туганнар гына катнаша торган йола кече аткушар дип атала: *«Балага бөтен затларын китереп, туганнарын дәшеп, азан чакырттык»*. Кунаклар саны күп булып, зурлап үткәрелә торган йола *зур аткушар* дип атала: *«Зур аткушар йасадык соңында. Ирләр, ирләрдән соң катыннар чакырдык. Урамга кийемнәр китерәләр, кодагый киләде, киленнең анасы. Ул китергән кийемнәрне күрсәтәйәк булдылар»*. Татарда исемне бала туганнан соң, берничә көн үткәч кушалар. Мәсәлән, әстерхан, нократ татарларында исемне өч көннән соң бирәләр: *«Бәбә тугач, исем бирәләр бер йомадан (атнадан) сун»*. Баланы бер атнадан артык исемсез калдыру куркыныч санала, чөнки шәйтан исем кушса, бала авырып китәргә мөмкин дигән ышану яши. Әстерхан татарында балага озак вакыт исем бирмәсәң, бала елак, тынычсыз була дигән ышану яшәп килә: *«Мулланы чакыртып, ат кычкыртып алабыс. Атсыз йатса, бала йылый, диләр»*.

«Бала туа, исемсез тормасын, кендек аты кушалар. Мулла китерәләр дә йакшы ат кушалар. Мулла кушкан исем белән гомер итәләр. Бусы – кендек исеме, ә бала йакшыргач, азанчы китереп, исем бирә. Ике исем бирәләр».

Мөселман гадәтләре буенча исем кушканда, муллага баланы мендәргә салып китерәләр. Әстерхан татарларында исә баланың йөзен яулык белән каплау гадәте дә сакланган. Екатеринбург өлкәсендә яшәүче татарлар, исем кушканда, исем качмасын, шайтаннар өйгә кермәсен, дип, өйдәге бөтен тишек-тошыкларны, морҗаны, ишекләрне, тәрәзәләрне һ.б. ябып куялар: *«Исеме сыгып китмәсен, шайтаннар-нимәләр кермәсен, дип, бөтен нимәне йаба торганнар ыйы, мөрҗә-йүшкәләрне, капка-ишекләрне йабалар ыйы»*. Билгеле булганча, күп кенә халыкларның этнографиясендә мич, тау куышына охшаш булуы сәбәпле, саклау урыны, культ ролен үти. Шулай ук, йола хәрәкәтләрендә морҗа кеше һәм космосны бәйләп тора торган предмет буларак та катнаша.

Ислам традицияләре нигезендә

Безнең мирас №2 февраль 2017

мулла баланың аякларын кыйбла (Мәккә) тарафына юнәлдерә. Баланың иң беренче ишеткән сүзе «Аллаһ» сүзе булсын дип, баш очында азан әйтелә. Соңыннан сулга таба борылып, кулларын ике якка куеп, камәт әйтелә, мулла сабыйның колагына беренче тапкыр исемен пышылдый. Минзәлә татарларында исем кушуда шундый теләк сүзләре дә әйтелә: *«Аллаһы Тәгаләгә кол булсын, Пәйгамбәребезгә өммәт булсын»*. Пермь татарларында, исем кушканнан соң, муллага көмеш акча бүләк итәләр. Бу гадәт балага көмеш кебек ныклы сәламәтлек теләүгә тиң була: «Көмеш тәңкә кебек нык булсын!» Исем кушканда, бала еламайса, төрле тавышлар чыгара башласа, йола беткәч, йоклап та китсә, бу очракта исем балага килешкән булып санала.

Керәшен татарларында өч тапкыр тәрәзәдән бала сату турында хәбәр бирелгән. Баланың бик очсыз бәягә сатылуы әйтелгән. Тәрәзәнең сакраль чигендә сатып алу оештырыла. Кендек әбисе – сатучы, күршеләр сатып алучылар ролендә катнашкан. Сатучы һәм сатып алучы арасында символик диалог корылган: «– Сатам, аламсыз? – Алабыз. – Хакы ничә сум? – Биш сумнан сорыйбыз, күп сорамыйбыз».

Исем кешенең рухы, җаны белән тиңләштерелә, исем йөртүченең эшләгән эш-гамәлләрен, уй-тойгыларын да чагылдыру мөмкинлегенә, магик көчкә ия сүз санала. Исем кеше җанына тиң дигән фикергә бәйләнешле исем алыштыру, исем кушуның төрледән-төрле ырымнары, йола хәрәкәтләре яшәп килә. Исем алыштыру табу күренеше белән тыгыз бәйләнештә тора. Татар диалектларында исем алыштыру исем бозу, миң бозу дип атала. Әгәр бала бик нык авырса яки балага миң чыкса, исем алыштыралар. Баланың тәненә төрле тимгелләр, миң чыкса, исем кушканда, морҗадан кашык төшергәннәр һәм миң сүзе кергән исемнәр биргәннәр: *«Баланың миңе булса, җүшкәдән кашык төшереп исем кушалар ыйы. Миңнегөл, Миңнебай, Миңнекамал исемнәре кушалар ыйы баланың миңе булса»*.

Дөрес сайланмаган яки «бозылган» исем баланың кинәт авыруына китерә ала, дигән ышану яшәп килә. Шуңа күрә, күп кенә төрки халыкларның исем алыштыру йоласы халык медицинасы белән тыгыз бәйләнгән. Мәсәлән, Казан арты татарларында, әгәр бала авырып китсә, тары боткасы пешерәләр һәм аны мичкә куялар. Морҗадан кашык төшереп: «Исемен алыштырам, Миннегол булсын. Кашык төшердем, саулыгын бирсен», – дип әфсен укыйлар. Соңыннан тары боткасын кошларга бирәләр. Морҗа явыз көчләрнең өйгә керү юлы булып санала. Шуңа күрә, кешенең морҗага мөрәҗәгать итүе явыз көчләргә мөрәҗәгать итүе булып яңгырый. Морҗага мөрәҗәгать итү йоласы баланың тәненә миң чыккан очракларда да кулланыла. Әлеге йоланы башкарып, балага *миң, кал* компонентлы исемнәр бирелә. Татарда миң белән бәйләнелешле йоланы *«миң боздыру»* дип атыйлар. Миң төрки халыкларда бәхет символы, бәхетле язмыш күрсәткече булып санала. Казан арты татарларында миң боздыру йоласын башкарганда, морҗадан тары боткасына кашык төшергәннәр. Нократ татарларында баланың яңа исемен морҗадан кычкырганнар. Кендек әбисенә яңа кашык бүләк иткәннәр. Бу йоланы кар эреп бетмәгәндә яисә җәй җиткәнче үткәргәннәр. Миңсылу, Миңнәхмәт кебек миң компонентлы исемнәр кушканнар. Себер татарларында мич саклау ролен үтәгән. Авыру баланы яисә миңле баланы мичкә куйганнар һәм морҗадан яңа исем кычкырганнар.

Пермь татарларында елак баланың исемен алыштыру йоласы яши: *«Сыктак булса, әйтәләр, исеме килешми*

микән, диләр, исемен алыштырыйк, диләр». Нократ татарларында да исем алыштыру йоласы бар: *«Йылак олан булса, исемен алыштыралар. Минем малаем Шәйхулла, исемен алыштырып кашык төшерделәр морйадан Минкәт итеп. Гөлзәмингә Миңзифа дип исем салдырдым»*.

Себер татарларында миң сүзенең варианты кал сүзен дә исемнәргә кушып кулланалар: Калыстан, Калпикә, Калы, Миңкалыш һ.б. Миң чыккан урынга яңа гына суелган малның канын сөртү йоласы да яшәп килә. Себер авылларында яңа суелган әтәч канын сөртү йоласы була: *«Калы цыккан балага курасны суйып, аның канын сөрткәле кәрәг икән»*. Мал-туар каны саклау, көч бирү, җанлы һәм җансыз дөньяны бәйләү вазифасын үти дип санала. Кан җанны алмаштыру ролен үтәсә, исем үлгәннәрнең җаның яктыртучы булып тора.

Традицион татар мәдәниятендә, сүзнең магик көченә ышанып, баланы яман көчләрдән, авырулардан саклау максатында кушылган исемнәр очрый. Себер татарларында бала көчле, нык булсын дигән максат белән «тимер», «таш» компонентлы исемнәр бирелә: Тимергали, Тимербай, Тимерхан, Тимербәк; Таштимер, Ташпулат һ.б. Керәшен һәм минзәлә татарларында тимер компоненты балага озын гомер теләү мотивы белән кушыла: Тимергали, Тимершәех, Минтимер, Тимерүк һ.б.

Исем кушу, исем сайлау магиясе үлемне туктату исемнәрендә дә билгеләнә. Себер татарларында *тукта* сүзе нигезендә ясалган исемнәр (*Туктар, Туктарбикә, Туктасын* һ.б.) гаиләдә бер-бер артлы үлеп торган балалардан соң туган балага бирелгән. Шулай ук *Калсын, Үлмәс, Үлмәскол, Яшәр, Торсынбай, Торсынай* һ.б. кебек исемнәр гаиләдә балалар үлемен туктату максатында кушылган. Әстерхан татарларында *Сатыбал, Сөйөндөк, Кушандык, Туктар, Сатыбалды, Туктамыш, Тимерулат, Туктагол, Балтабай* һ.б. кебек исемнәр теркәлгәннәр. Рязань өлкәсе татарлары, әгәр гаиләдә бала үлеп торса, гарәп чыгышлы *Бакый, Бакыйа* исеме биргәннәр.

Бала сату йоласы гаиләдә балалар еш үле туган очракта, яман көчләрне бутау, алдау максатында үткәрелгән. Әлеге йоладан соң, сабыйга *Сатукай, Сатый, Сатыпал* кебек исемнәр кушылган. Керәшен татарларында өч тапкыр тәрәзәдән бала сату турында хәбәр бирелгән. Баланың бик очсыз бәягә сатылуы әйтелгән. Тәрәзәнең сакраль чигендә сатып алу оештырыла. Кендек әбисе – сатучы, күршеләр сатып алучылар ролендә катнашкан. Сатучы һәм сатып алучы арасында символик диалог корылган: *«– Сатам, аламсыз? – Алабыз. – Хакы ничә сум? – Биш сумнан сорыйбыз, күп сорамыйбыз»*. Бала үз гаиләсендә калса да, йола башкарганнан соң күршеләрнең баласы дип исәпләнелгән. Аның нигезендә, бу бала инде хәзер чит бала, шуңа күрә, ата-анага ачуланган яман көчләрне инде бала кызыксындырмый, дигән мәгънә яткан. Сабыйны тәрәзәдән чыгару исә яңа тормышка, яңалыклар процессына таба баруны аңлата. Шул рәвешле, сакраль тәрәзәдән чыгарылган бала явыз көчләргә каршы тору көченә ия булган балага әверелә.

Татар антропонимик системасында исем кушуга бәйле йола-традицияләр, ышанулар, йола хәрәкәтләре мөселман һәм төрки мифопоэтик традицияләр нигезендә үсеш алып, җирле үзенчәлекләрне дә берләштереп, татар халкы яшәгән төрле почмакларда, төрле вариантларда бүгенгәчә сакланып калганнар. Татар культурасында исемгә, исем кушуга бәйле йола-традицияләр ата-ананың, олы буынның теләкләрен яктырту, кешене табигать белән тиңләштерү, борынгыларның рухларын искә алу, дөньядагы уңай якларны күрсәтеп, үлемне алдау, язмышны яхшырту, олы буын белән яшь буын арасын бәйләү вазифасын үтиләр. ■

КЫЛЫЧ

*Татарстан Республикасы
Милли музее фондыннан*



Татарстан Республикасы Милли музееның корал коллекциясендә игътибарны җәлеп итәрлек әйберләр күп. Рус-япон сугышы белән бәйле кораллар да бар безнең хәзинәбездә. «Катана» һәм «тати» – япон кылычлары.

Кәкре кылычлар ике төрле металлдан ясалган: нык корычтан һәм тимердән. Әлеге материалларны бер-берсе белән күп тапкыр кушу, кою, эретеп ябыштыру ярдәмендә берничә катлам барлыкка килә. Кылычның суга торган өлеше генә зур температу-

ра астында тотылган. Әлеге технологик ысул кылычка сыгылмалылык һәм ныклык биргән. Соңыннан инде аларны шомартып, махсус ысул белән чыныктырганнар. Төрки бабаларыбыз андый кылычны «булат» дип йөрткән.

Гүзәлия Җәләлева әзерләде. ■

ТАССР 100 ЛЕТ ЕЛ

Празднование 100-летия Татарской АССР

Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү

КАЗАН ГУБЕРНА БАШКАРМА КОМИТЕТЫНЫҢ ВӘКАЛӘТЛӘРЕН ТАССР ВАКЫТЛЫ РЕВОЛЮЦИОН КОМИТЕТЫНА ТАПШЫРУ ТУРЫНДА АКТ

Татарстан Республикасы Дәүләт архивы фондыннан

Мәгълүм ки, Татарстан Республикасы Дәүләт архивы фондында бихисап уникаль документлар саклана. Алар арасында мәшһүребез Габдулла Тукайның фоторәсемнәре һәм Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяга багышланган «Ике кояш» шигыренең кульъязмасы, Мулланур Вахитовның әтисе белән үги әнисенә Казан губернасы төрмәсеннән язган хаты, Муса Җәлилнең автобиографиясе, шулай ук герой-шагыйрьнең ТАССР Президиумының Югары Совет рәисе Г.А.Динмөхәммәтовка һәм Татарстан Язучылар оешмасы җитәкчесе Т.М.Имаметдиновка язган хатлары бар. Болар белән бер исәптә торган янә бер үзенчәлекле документка – «Казан губерна башкарма комитетының вәкаләтләрен ТАССР вакытлы Революцион комитетына тапшыру турында акт»ына игътибар итик әле.

Акт хакимиятне Эшче, крестьян һәм Кызыл Армия депутатларының Казан губерна Советы башкарма комитетыннан Бөтенроссия Үзәк башкарма комитеты һәм Халык комиссарлары Советының 1920 елның 27 маендагы декреты белән төзелгән Автономияле Татарстан Совет Социалистик Республикасы вакытлы Революцион комитетына тапшыруны белдерә. Революцион комитетның хакимиятне кабул итү көнендә – 1920 елның 25 июнендә Татарстан Республикасы рәсми рәвештә игълан ителә һәм Казан губерна башкарма комитеты таратыла. Актта Бөтенроссия Үзәк башкарма комитеты президенты 1920 елның 10 июнендә раслаган Революцион комитет составы: рәис – Сәхибгәрәй Сәед-Галиев һәм әгъзалар – Исхак Казаков, Кәрим Хәкимов, Кашшаф Мохтаров, губерна башкарма комитеты рәисе И.Ходорковский һәм аның урынбасары А.Бочков, Запас армия штабы командующие Б.Гольдберг һәм аның урынбасары А.Жарко күрсәтелә.

Сәхибгәрәй Сәед-Галиев

Актта Казан губерна башкарма комитеты рәисе И.Ходорковский, президиум әгъзалары М.Ендаков, А.Бочков, И.Казаков, Гордеев, И.Гаврилов, сәркатип Гнатовский, Революцион комитет рәисе С.Сәед-Галиев, Революцион комитет әгъзалары И.Ходорковский, А.Жарко, А.Бочков, Б.Гольдберг, И.Казаков имзалары тора.

1920 елның 25 июне.
Татарстан Республикасы Милли архивы. Төп нөсхә. Документ Татарстан Республикасы Архив фондының Республика уникаль документлар реестрына кертелгән. ■

E-mail: prm.archive@tatar.ru
www.arhiv.tatarstan.ru

АКТ

ВСЕРОССИЙСКИЙ ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ И СОВЕТ НАРОДНЫХ КОМИССАРОВ 27 МАЯ 1920 ГОДА

ПОСТАНОВИЛИ:

I.

II.

III.

Председатель Всероссийского Центрального Исполнительного Комитета

Председатель Совета Народных Комиссаров В.УЛЬЯНОВ /ЛЕНИН/

Председатель Казанского Губисполкома

ЧЛЕНЫ Президиума

Секретарь

Полномочия от Казанского Губисполкома

Председатель Ревкома Тат. Соц. Сов. Респ.

ЧЛЕНЫ Ревкома

г. КАЗАНЬ 25 ИЮНЯ 1920 года

Безнең мирас №2 февраль 2017

ЯБЫНЧЫ – МӘРҖАНИНЕҢ ТУГАН АВЫЛЫ

2016 елның май аенда Әтнә районының Ябынчы авылында атаклы галим, тарихчы, этнограф, дин эшлеклесе Шиһабетдин Мәрҗанигә (1818-1889) багышланган мемориаль комплекс ачылды. Бу күркәм эш Татарстан Дәүләт Советы депутаты, «Таттелеком» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин җитәкчелегендә гамәлгә ашырылды.

Ябынчы (Япанчы) район үзәге Әтнәдән 16 километр ераклыкта урнашкан. Авылга Казан ханлыгы чорында нигез салынган. Егерменче гасыр башында анда мәчет, тимерче алачыгы, су һәм җил тегермәне булган. Авыл халкы нигездә игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнгән.

Ябынчы – Ш.Мәрҗанинең туган авылы. Ул монда 1818 елның 16 гыйнварында Баһаветдин мулла гаиләсендә дөньяга килә.

Мәрҗани утыздан артык гыйльми хезмәт яза, шулар арасыннан унөче аерым китап булып басыла. Боларның күп өлеше – гарәпчә язылган дини-фәлсәфи әсәрләр.

Мемориаль комплексны ачу вакыты. Уртада – Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин

«Тарихчының вазифасы – үзе хәбәрдар булган вә игътибарга лаеклы сүз һәм хәбәрләрне арттырмый һәм киметми, ничек бар шулай китерү, эчтәлегенең төп өлешен төшереп калдырмыйча һәм бирәүнең файдасына яки зарарына тарафдар булмыйча аңлатып бирү. Булганны – яхшымы ул, яманмы – ничек бар, шулай бәян итә».

Шиһабетдин Мәрҗани

Тарихи, биографик характердагы хезмәте – **«Вафийәт әл-әслаф...»**. Ул – Көнчыгыш дөньясындагы галимнәр һәм аларның хезмәтләре турында биобиблиографик әсәр. Гарәпчә язылган бу хезмәтнең кулъязмасы Казан дәүләт университеты китапханәсендә саклана (барысы 6 том, күләме 4500 бит чамасы). Автор бу әсәрен кулъязма нөсхәләрдә чит илләрдәге кайбер китапханәләргә дә җибәргән.

Мәрҗанине дөньяга танытькан икенче хезмәте – **«Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар»**.

«Рихләтел-Мәрҗани» – Ш.Мәрҗанинең чит илләргә сәяхәте турында. Ул 1897 елда Казанда басыла. ■

Ш.Мәрҗани туган йорт урыны

Безнең мирас №2 февраль 2017

«АШКАЗАР»

Мостай Кәрим
(1919-2005)

Озын гомер эчендә йөрәкне тетрәтер вакыйгаларга, күңелне арбар кешеләргә байтак тап киленгәндер. Эш вакыйгаларның эре һәм шаулы, кешеләрнең атаклы һәм дәрәҗәле булуында түгел. Хикмәт шунда: алар хәтергә сеңеп калалар да, бар өметеңне юып, хәсрәткә батканыңда яки, бар дөньяңны онытып, тантана иткәнеңдә калкып чыгалар. Чыгалар да асылыңны барлыйлар. Харап булдым, дип, артык өзгәләнмисеңме, мәртәбәгә мендем дип, артык масаймыйсыңмы – шуны искәртәләр.

...Янә җыр. Гомер буе җыр минем җанымны тетрәтте, зиһенемне дәвалады. Дәртләремә, сагышларыма үлчәү булды. Хәер, үзем шушы көнгә тикле эчемдәге моңны, җыр итеп, тышка чыгарганым юк. Тәңре миңа көй дә, тавыш та бирмәгән, әмма күңелемне саңгырау итмәгән. Ишетә ул.

Тормыш белән аралар бозылган чакларда, көн яктысы күзгә күренмәс булганда, капыл исемә төшә: дөньяда җыр бар бит әле! Димәк, инанырга, сабыр итәргә, яшәргә кирәк. Соңгы кабым икмәгем, соңгы йотым суым белән бергә соңгы тапкыр ишетер җырым булса, үкенечкә калмас, дип юанам.

Күз күрә, колак ишетә башлаганнан бирле җыр байтак тыңланды. Гармун тартып урамда йөргәндә – егетләр, тула басканда – кызлар, бал эчкәндә – атаемнар, киез әвәләгәндә җиңгәйләр, апайлар җырлый. Ләкин күңелне айкаган җырны хәтерләмим. Күрәсең, алар әле миңа тәгаенләнгәне булмаган.

Минем өчен җыр менә кайчан башланды. Өршәк буеннан безгә утырмага бер кыз килде, Зөбәрҗәт кодача. Кашавай чана җигеп, Мортаза агаем барып алды. Ул – күз явын алырлык чибәр. Кыйгач кара кашлары гына ни тора! «Керфегеннән нурлар тама» дигән җыр, мөгаен, шул Зөбәрҗәт турысындадыр. Ишектән кергәч тә ул бүтәннәр белән куш куллап күреште, «кече кодам», дип, мине кочаклап алды. «Бәләкәч», димәде, «кече», диде. Сигез яшьлек кеше нишләп бәләкәч булсын ди. Азактан аңлавымча, кодачага әүвәл үк агаемның күзе төшкән икән, тегенең дә күңеле тарткан булыр, тартмаса, җир аягы – җир башы җиргә утырмага килмәс иде. Ә мин исәр, икенче көндә үк Зөбәрҗәткә, сөмсезләнеп, үзем гашыйк булдым. Күзләремне йөзләреннән аерып ала алмыйм. Җитмәсә, ул, туры килгән саен, Акманай камышы төсле матур, озын бармаклары белән йә минем битемнән сөя, йә башымнан сыйпый. «Бөдрә бәрәчкәем...» – ди. Кыш көне минем чәчемне кырып изаламыйлар. Шуңа күрә бөдрәм бармак тыккысыз. «Бәрәчкәй» дигәне миңа ошап җитми дә, тик яраткан кешең әйткәч күнәсең инде.

«И, бөдрә бәрәчкәй! – дим мин хәзер үземә. – Теге чакта Зөбәрҗәт бит, сине сөеп, уенда агаемны иркәләгән. Ул да бөдрә».

Кунак килеп ике-өч көн үтүгә, атаемнар Каранелгага кунакка китте. Аулак өйгә күз-колак булырга саңгырау Миңзифа инәебезне калдырдылар. Ул каты түгел, тыймый. Теләсәң нәрсә кылан. Аулак өйдә кич утырырга кызлар җыелды, соңрак агаемның яшьтәш егетләре дә килде. Уен, җыр китте.

– Туктагыз әле, кызлар, – диде Гөлҗамал апаем, – без гел үз ягыбыз җырларын гына җырлыйбыз. Өршәк якларында нинди җырлар бар икән? Җырлап күрсәт әле, Зөбәрҗәт!

– Кодача җырласын! – дип кушылды егетләр.

Зөбәрҗәт инәлтмәде. Матур иреннәрен чак кына бөрештереп торды да:

– Җырлап карыйм алайса. Тын җитсә, – диде.

Күзләреннән нур сирпеп, агаем аша миңа әйләнеп карады. Мин утырган почмагыма тагын да ныграк сыендым.

Җырын башлавы булды, мин бу дөньядан ваз кичтем. Моң, сузылган саен мине бетмәс-төкәнмәс сагышларга батырып, йөрәгемне арбый барды. Җанымны әллә һаваларга ашырды, әллә упкыннарга атты, моннан ары ничек итеп яшәрмен, белмим. Мин җырчының йөзен күрмим. Ул миңа кырын утырган. Ничек еламый чыдый икән? Мөгаен, ике күзе тулы яшьтер. Ир булып, мин әле чак түзеп утырам.

Җанкай-җанаш китте, ай, сунарга,
Ашказаркай буе чәшкегә,
Чәшкеләргә китеп вафат булды,
Башкынаем калды яшь көйгә.

Озын сузып, озак җырлады Зөбәрҗәт. Әйткәнемчә, мин үз-үземне оныттым, шулай да килеп-килеп шомланып куям, җыр бетәр, дип куркам. Ул бетсә, ни кала? Бушлык.

Җыр да тынды. Сулышым да өзелде. Бүтәннәр дә озак шымып калды.

Юк, вафат булмас җанкай-җанаш. Бары адашкан гынадыр. Шушы җырны ишетеп, кайтыр юлын табар ул.

Шул кичтән башлап рухыма җыр сеңде. Гөлҗамал апаем белән ахирәт булышып, Зөбәрҗәт кодача бездә айга якын торды, чигү чикте, каю каеды. Кайтам, дип сөйләнә башлагач та, өчдүрт көн җибәрми тордык. Аксалны кашавайга җигеп, ерактагы кечкенә авылга Зөбәрҗәтне агаем белән икәү илттек. Мине атаемнар тагып җибәрде булыр. Кашавайга түшәлгән йомшак печән өстендә егет белән кыз уртасында рәхәткә чумып барам. Ат җиле күтәргән сыек буран бит очларын чеметеп ала. Мамык шәл очы белән Зөбәрҗәт минем битемне каплый. Рәхәт өстенә рәхәт! Хәзер инде мин аңа гашыйк кына түгелмен, гашыйктан да артыграк. Туган апаем яки туган җиңгәм кебек үк. Агаем белән кавышсыннар да теге үзәк өзгеч җырны бервакытта да җырламасын иде Зөбәрҗәт.

Кодалар безне ике көн кунак итте. Агаемны да, мине дә кайда утыртырга, кайда яткырырга белмәделәр. Безне ныгытып ошаттылар булыр.

Кайтыр юлда агаем үтә боек күренде. Мин беләм инде, аерылышу шулай бәндәне сагышка сала. Үзем дә ямансулыйм.

Өйгә кайткач, өлкәннәрнең хәстәрле сүзләре еш кына колакка чалына башлады. Алдагы көзгә кызның унсигезе тула икән, артык озакка сузмыйча, яучылар җибәрербез ахрысы. Алдан ярәштереп кую хәерлерәк булыр.

...Ерганаклар тулып, кар сулары аккан мәлдә кодалардан үтә яман хәбәр килде. Чибәр кодачабыз, минем булачак җиңгәм, асылташ исемен йөрткән Зөбәрҗәт бәкедән су алып чыккан чагында, боз ишелеп, Өршәк төбенә киткән. Су өстендә көянтәсе генә торып калган.

Үзе китте, җыры гомер буе миндә яши. Мин аны күптән үзем чыгарган сүзләргә әле дә тавышсыз гына, эчемнән генә җырлыйм. Үтә яшьләй дөнья куйган Мортаза агаем булып җырлыйм.

Җанкай-җанаш, җырларыңны тыңлап,
Мин терелеп кайттым сунардан.
Җанкай-җанаш, килче кочагыма,
Калкып кына чык та сулардан...

Үзе чыкмас инде, ә җыры хәтта тарих дәрьяларында батмый яшәр һәм иңрәр... ■

«Кояш» газетасында **«Казан хәбәрләре»:** 1917 елның февраль ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Мөселман каберстанына җир

Мөселман каберстанын зурайту өчен бик озын вакытлар үтенечләр соңында, шәһәр йиреннән ике мөрәббәгъ [квадрат] сажень кадәр урын бирелгәнлеге мәгълүм. Менә шушы йирнең бер читендә Крестовниковлар милке булган бер урын да бар иде. Закон буенча, каберстан янында мәгълүм микъдарда ачыклык калдырырга кирәк булганлыктан, Крестовниковларның әлеге урынына – йортына чиктәш булган урында каберлеккә дигән урыннан бик күп микъдардан әрәмгә ачык калдырырга тугры киләчәк иде. Мөселманнар, шушы урынны әрәм итмәс өчен, Крестовниковлардан әлеге сузылып торган җирләрен мөселманнарга бирергә яки сатарга сораганнар иде. Крестовниковлар, милекне кулдан чыгармаска карар биргәнлектән, ул йирне сата вә яхуд бушлай бирә алмыйбыз, әмма алмаштырырга теләгәндә урынына карап килешү мөмкин булыр, дип җавап биргән иде. Шушы хәлне игътибарга алып, каберстан мөтәвәллилеге, мөселман җәмәгасе шәһәр управасына мөрәҗәгать кыйлып, Крестовниковларга үзләренең заводлары артыннан, күл яныннан йир бирергә вә аның урынына мөселман каберстаны янындагы урынны алып, каберстанга тоташтырырга сораган иде. Инде хәзер шәһәрнең малия [финанс] комиссиясе шушы мәсьәләне карагач, мөселманнар белән алмашу шарты белән, Крестовниковларга күл кырыеннан бирергә мөмкин, дигән карар кабул иткән.

Кояш. – 1917. – №1083. – 21 фев.

Шәрык кичәсе

23 нче гыйнварда «Новый клуб» бинасында Казанның мөселман студентлары тарафыннан Шәрык кичәсе ясалды. Бәгъзе бер сәбәпләр аркасында бу кичә бик ашыгыч бер арада гына ясалып алынса да, кызык һәм җанлы гына үтте. «Летучка»ларның кичәдән бер генә көн элек таратылуларына, кичә хакындагы хәбәр һәм игъланнарның шул көндәге бер гәзитәдә – «Кояш»та гына чыгуына карамыйча, халык күп булып килгән иде. Халыкның хөсне тәвәҗҗеһе [яхшы теләге], кичәне ясаучыларның тырышлыклары аркасында шәрык кичәсе зур бер матди муаффәкыять [уңыш] белән үтте. Шәрык кичәсеннән 3 мең кадәр гомуми ысбур [керем] булды һәм 1900 сум кадәр халис [саф] файда калу ихтималы сөйләнде.

Шулай ук кичәнең мәгънәви җәһәте дә яхшы гына үтте. Кичәнең програмы төрле һәм кызык иде. Аның програмына җанлы ләүхәләр [картина], музыка, җыру, бию, декламация кертелгән иде. Халык кичәдә иштиракь иткән [катнашкан] кешеләрнең барысын да бик җылы каршы алды. Укучы туташлар вә егетләрдән төзелгән зур хор һәм оркестр, Болгарская белән Әхмәдова тарафыннан иҗраэ ителгән [башкарылган] бию, Н.Ә. әфәнденең флейтада уйнавы халыкның хушына бигрәк киттеләр һәм бик нык алкышландылар.

* Даталар иске стиль белән бирелә.

Җанлы картиналар тиешле тәэсир бирә алмадылар. «Уку»лар да муаффәкыятьсезрәк чыкты. Тукаевның «Тормыш» дигән шигырен декламировать иткән Ләтыйф әфәнденең кәләпүше вә укый торган шигырен яхшы гына ятламаган булуы тәэсиренең төгәллегенә шактый зарар итте. Дәрдемәнднең «Бүзләрем мана алмадым»ын Гакәс әфәнденең[1] укуы бик яхшы булган хәлдә, сайлавы бик начар иде. Шөбһә юк ки, фарсы вә гарәп сүзләреннән җыелган бер нәрсә эксәрият [күпчелек] өчен бер дә аңланырлык түгел иде. Халык өчен бу матур, ләкин мәгънәсез аваз булып чыкты...

«Сәйяр» труппасы тарафыннан башкарылган «Әдәп дәресе» кызык кына үтте. З.Н.

Ильская бенефисы

24 нче февральдә «Большой театр» бинасында Фатыйма ханым Ильскаяның бенефисы булды. Шуннан элек Шәрык кичәсе булуына карамыйча, театр залы шыгрым тулы иде. Фатыйма Ильская бенефисына «Трильби»[2] дигән русчадан тәрҗемә 5 пәрдәле бер пьеса куелды. «Трильби» – хыял белән хакыйкатьтән торган, ләкин саф хыял да, саф хакыйкать тә булмаган, матур, сәхнәдә куяр өчен уңайлы итеп эшләнгән, шуның белән бергә буш һәм хасилсез пьеса, русча әйтсәк, «милый пустячок»тыр.

Иң авыр, зур рольләрне Кариев белән Ильская яхшы уйнадылар. Ильскаяның да бик күп көч сарыф итеп әзерләнүе күренеп тора иде. Бенефис сәхибенә [иясенә] кыйммәтле һәдияләр [бүләкләр] бирелде. З.Н.

Кояш. – 1917. – №1085. – 26 фев.

Фәкыйрьләргә утын

Шәһәр управасы утынга саклык итеп, күп алып калган кешеләрнең утыннарын мәсадәрә кыйлырга [көчләп алырга] керешмәс борын, аларга үз ихтыярлары белән бу утыннарын мохтаҗларга сатып бирергә яхуд управага тапшырырга гарыз кыйлгач, управага йиде мең сажень кадәр утын җыелган. Бу утыннар мәйданнарыннан ярлы кешеләргә яртышар сажень итеп, ярлыклар белән биреләчәктер. Управада моңа язылулар башланган инде.

Балаларга күмәч

«Тиен тәңкәне саклый» җәмгыятенең главный магазинында һәм дә Ягодныйдагы шөгъбәсендә [бүлегендә] җәмгыять әгъзаларының балаларына карточка буенча күмәч биреләдер. Карточка район попечительләреннән алынган булмаса, паспорт яхуд метрический свидетельство кебек шәһадәтнамәләр буенча карточка биреләдер. Карточкалар 10 яшькә кадәр булган балалар өчен биреләчәктер. Күмәч, балалар өчен көненә ярты кадактан хисапланып, шәһәр управасыннан игълям [хәбәр] булгач та бирелә башлаячактыр. Җәмгыять идарәсе әгъзаларына хәзердән үк мондый карточкаларны алып калырга мәслихәт күреләдер.

Кояш – 1917. – №1086. – 28 фев. ■

[1] Гакәс әфәнде – университет студенты, һәвәскәр артист һәм тәрҗемәче Газиз Сәйфелмөлековның сәхнә псевдонимы.

[2] «Трильби» – француз язучысы Дж.Дюморьен романы буенча Гр.Ге тәрҗемәсе.

Безнең мирас №2 февраль 2017

Вак-вак ләтыйфәләр һәм хикәя кисәкләре



Австриянең сугыш игълан итүе (сулда – Германия, уртада – Австрия, уңда (аю) – Русия)

Русия вә Германия сугышы

Германия вә Бельгия сугышы (сулда – Германия, уңда – Бельгия)

Ялт-йолт. – 1914. – №78. – Б.8

ПОЖАРДА

– Әфәндем, син нәрсәгә утның нәкъ уртасына кереп барасың, әллә хатының, балаң калдымы?

– Юк, шырпының кыйммәт вакыты булганлыктан, уттан файдаланып, тәмәке кабызмакчы идем.

ИЛҺАМ

Мәхбүбә:

– Әйт, җаным, сиңа кайчан илһам иңә?

Шагыйрь:

– Иреңнең зур йодрыкларыннан котылгач.

ШӨҺРӘТ АЛГАН

– Иптәш, хәзер инде мин мәшһүр кеше.

– Ни эшләп, әллә халыкка берәр файдаң тидеме?

– Юк, өченче көн динатур эчеп арестныйга кергән идем, шуны газетага язып чыгарганнар.

УРЫНЛЫ ҖАВАП

Судья:

– Мәгъюб* әфәнде, сез ни өчен ул пәлтәне урладыгыз?

Карак:

– Сезнең хозурыңызга яңа пәлтәдән килер өчен.

ҖИҢЕЛ КӘСЕП

– Иптәш, минем калушым тишелгән, ни эшләргә?

– Җомга көн мәсҗедкә бар.

«Ялт-йолт» журналы – 1916. – №111. – Б.15

Русия вә Германия сугышы: өстә – Русиягә һөҗүм; аста – «Мә, иснәп кара әле, моннан ни исе килә икән?» (сулда – Германия, уңда – Русия)

Ялт-йолт. – 1914. – №78. – Б.9

* Мәгъюб – гаепләнүче.

Текстны һәм искәрмәләрне басмага ***Рәйсә Шәрәфиева*** *әзерләде.* ■

Башкалабыз Казандагы Б.Урманче музее

«Безнең мирас» ельязмасы / февраль

• 645 ел элек (1372)

Мамай мирза Рязань кенәзлегенә олуг кенәз итеп Олег Ивановичны билгели.

• 405 ел элек (1612)

Лейпцигта беренче татар басма китабы дөнья күрә.

• 235 ел элек (1782)

Шагыйрь, дин һәм җәмәгать эшлеклесе Әбелмәних Каргалый (Әбелмәних Әбелфәиз Габдессәламов) дөньяга килә.

• 120 ел элек (1897)

23 февральдә күренекле рәссам, сынчы, график һәм педагог Бакый (Габделбакый) Идрис улы Урманче (1897-1990) дөньяга килә.

• 95 ел элек (1922)

Новониколаевскида (Новосибирск) себер татар һәм казакъ яшьләре өчен гыйльми, иҗтимагый һәм сәяси «Алмашка» журналы чыга башлый.

• 90 ел элек (1927)

Һади Такташ «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасын тәмамлый. Әсәр «Безнең юл» журналының февраль санында дөнья күрә.

28 февральдә татар театрына нигез салучыларның берсе, актёр һәм режиссёр, Хезмәт Батыры Нури (Нуретдин) Нәбиулла улы Сакаев (1885-1927) вафат була.

• 70 ел элек (1947)

19 февральдә, күренекле шагыйрь Фатих Кәримнең яу кырында һәлак булуына 2 ел тулу уңаеннан, Тукай клубында искә алу кичәсе уздырыла.

• 15 ел элек (2002)

Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллинны кабул итә. Бүгенге әдәбиятның торышы һәм аны үстерү, язучыларның матди хәлен һәм көнкүрешен яхшырту мәсьәләләре тикшерелә.

Шул ук көнне Татарстан премьер-министры Рөстәм Миңнеханов та Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллинны кабул итә. Анда сүз Республика Президентының әдәбиятны үстерү мәсьәләләре турындагы күрсәтмәләрен үтәү чаралары хакында бара. Аерым алганда, Васильевода язучылар өчен иҗат йортын төзеп бетерү турында сөйләшенә. Әлеге очрашуда төзелеш һәм коммуналь хуҗалык министры Марат Хөснуллин, Финанс министрлыгының җитәкче хезмәткәрләре катнаша. ■

Мирасворд

Гурий Тавлин трилогиясе

Мәдинә Маликова романы

... Әбҗәлилов

... -д’Ивуар (Африкадагы ил)

Гаяз Исхакый чыгарган газета

... -баба йоласы

Кытай шашкасы

Мавритания акчасы

Көн акча янчыгы (иск.)

Язучы ... Вәлиев

Тәрҗемәче ... Ибраһимова

... Биишева

Совет йөк автомобиле

Кәҗә мамыгын чистарта торган тарак

Иске документлар саклана торган оешма

Күчмә халыкларның түгәрәк киез торагы

Җеп эрләү өчен йон, мамыкны беркетә торган тараклы такта

Александр Македонский полководецы

Кирәй ... (башкорт язучысы, фольклорчы)

Борынгы үзбәк

Тарихчы ... Таһиров

Мөнәсәбәтле (иск.)

XVIII йөз француз архитекторы

Төрки календарь буенча апрель ае

«... кыры» повесте (Чыңгыз Айтматов)

Зөянең сул кушылдыгы

Чигү чиккәндә тукыманы тарттырып куя торган җайланма

... Аалто (фин архитекторы)

Гали, Шәриф

... Гамзатов

Борынгы Спарта сәясәтчесе, законнар чыгаручы

Шагыйрь Мөхәммәт ...

... Галилей

Геологик пласт

Академик ... Салихов

... кыпчак

Совет астрономы

Урта гасыр төрки дәүләтләрдә хан мөһере

Тәүлекнең бер өлеше

Итле аш өстенә чыккан май

Эдуард ... (инглиз шагыйре)

... Гыйззәт

1 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Судан уңга: кич, Вәдүт, әләк, Хәсән, тиле, Тотыш, Этна, киле, баск, ванадий, «Хәят», инәк, ми, «Саз», балкар, дунән, алъяпкыч, нус, Кашшаф, арка, Нани.
Өстән аска: әтәмби, кули, маил, әл, Эсхил, «Чикерткә», Клячкин, яса, байтар, Кашан, Шри, Вахит, ди, дучмак, Окан, фал, дисәтинә, нун, ылак, Тенишев, Юныс.

Рәис Габдулла төзеде.

СОДЕРЖАНИЕ

Историческое наследие: «Булгар. Речной порт»; «Странники» А.Мухаммадиев; «Вам от меня светлые пожелания ...» М.Файзи; «Родная наша история в эпиграфике!» Р.Марданов, И.Хадиев; «Путешествие в Чуфут-Кале» С.Шамси.

Татарский мир: «Шайхелислам» Х.Миннегулов.

Тюркский мир: «Мои кони – мои крылья!» А.Галимзянов.

Духовное наследие: «Исламский мир» Г.Ибрагимов; «Религиозные праздники и памятные даты в 2017 году».

Литературное наследие: «Кутадгу билик» («Благодатное знание».) Ю.Баласагуни; «Белое облако Чингизхана» Ч.Айтматов; «Поучительные рассказы».

Культурное наследие: «Сара Садыкова» Р.Карами; «Подарок сцене от природы» А.Мингазова; «Образец таланта, старательности и самоотверженности» Р.Сагди.

Слово – украшение языка: «Словарь национальных терминов» А.Тимергалин; «На свете есть имя его, для народа есть его суть!» Г.Хазиева.

Татарская песня: «Ашказар» М.Карим.

100 лет назад..: «Казанские вести» в газете «Кояш»: февраль 1917 года».

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT

Historic heritage: «Bulgar. River harbor»; «The pilgrims» by A.Mukhammadiev; «The bright wishes from me to you...» by M.Fayzi; «Our native history is in the epigraphy!» by R.Mardanov, I.Khadiev; «The trip to the Chefet kala» by S.Shamsi.

The Tatar world: «Shaikhelislam» by Kh. Minnegulov.

The Turkic world: «My horse is my wings» by A. Galimzyanov.

Spiritual heritage: «Islamic world» by G.Ibragimov; «The religious holidays and remarkable dates of 2017».

Literary heritage: «Kutadgu bilik» («The blessed knowledge») by U. Balasaguni. «The white cloud of Genghis Khan» by Ch. Aytmatov; «Didactic stories».

Creative heritage: «Sara Sadykova» by R.Karami; «The gift to the scene from the nature» by A.Mingazova; «The example of talent, endeavor and fidelity» by R.Sagdi.

Word is a language's decoration: «Dictionary of national terms» by A.Timergalin; «There is a name of it in the world, there is a matter of it for people!» by G.Khazieva.

Tatar song: «Ashkazar» by M.Karim.

100 years ago...: «Kazan news» is in the «Koyash» newspaper: February of 1917.

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation life.

ИСКӘНДӘР РӘФЫЙКОВ

Искәндәр Вәлиулла улы Рәфыйков 1929 елның 5 октябрендә Казанда дөньяга килә. 1949 елда Казан сәнгать училищесын, 1956 елда Казан сәнгать академиясен тәмамлый. Ул – СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы, Татарстанның һәм Россиянең халык рәссамы.

Искәндәр Рәфыйков портрет, пейзаж һәм натюрморт жанрларында иҗат итә. Аның әсәрләре Россия, Финляндия, АКШ һәм Япониянең дәүләти һәм шәхси тупланмаларында саклана.

«Кызлар». Киндер, майлы буяу

«Ханбикә». Киндер, майлы буяу. 1999 ел

4 612750 670172

www.beznenmiras.ru

ИНДЕКС:

ТАТАРСТАНДА – 54132 (П-2343)

РОССИЯДӘ – 70275